УДК 371.512 395
ББК 74.03
Ә

Научные руководители:
Миннегулов Хатип Юсупович, Хисматова Лилия Котдусовна

Фәнни җитәкчеләр:
Хатыйп Йосыф улы Миннегулов, Лилия Котдүс кызы Хисмәтова

За содержание и фактическую достоверность материалов отвечает автор и научный руководитель.

Материалның эчтәлеге, фактларның дөреслеге өчен авторлар һәм фәнни җитәкчеләр җавап бирә.

Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, язучы Мәдинә Маликованың 85 яшьлек юбилеена багышланган III республикакүләм «Шушы яктан, шушы туфрактан без» фәнни-гамәли конференциясе материаллары (Мөгаллим һәм тәрбиячеләрнең эш тәҗрибәсеннән)

Материалы круглого стола III республиканской научно-практической конференции «Шушы яктан, шушы туфрактан без», посвященной 85-летию писательницы, заслуженного работника культуры Татарстана и России, лауреата Государственной премии имени Г.Тукая Мадины Маликовой

**Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы,**
**Татарстан Республикасы Язучылар берлеге,**
**Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты,**
**Яр Чаллы дәүләт педагогия университеты,**
**Сарман муниципаль районы Башкарма комитеты,**
**Сарман муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге,**
**республика «Ак калфак» иҗтимагый оешмасының район бүлекчәсе**

# ҖЫРЛЫ САРМАННЫҢ ЗЫЯЛЫ ЯЗУЧЫСЫ

Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, язучы Мәдинә Маликованың 85 яшьлек юбилеена багышланган III Республикакүләм «Шушы яктан, шушы туфрактан без» фәнни-гамәли конференциясе материаллары

28 нче февраль 2020 нче ел

Җәлил бистәсе

# СЦЕНАРИЙ КВН, ПОСВЯЩЕННЫЙ ЖИЗНИ И ТВОРЧЕСТВУ МАДИНЫ МАЛИКОВОЙ

Абдрахимова Рушания Шакирзяновна
учитель родного языка и литературы СОШ №3, г.Бугульма

**Ход мероприятия**

1. Вступительное слово учителя: Сегодня в форме КВН у нас пройдѐт мероприятие, посвящѐнное жизни и творчеству М.Маликовой. Мадина Маликова – известный татарский писатель, публицист, общественный деятель, член Союза писателей Республики Татарстан. В этом году писательнице исполняется 85 лет. И мы сегодня вспомним основные события ее жизни, особенности ее творчества, главных героев ее произведений.

Итак, пришло время участникам представиться.

2. Команды, участвующие в КВНе (задание было дано заранее) представляют себя: название, эмблему, девиз. (Наибольшее количество баллов 3.)

3. Учитель: И у нас первый конкурс — «Разминка».

Зиннур Хуснияр, характеризуя творчество М.Маликовой, сказал: «Мәдинә Маликова үзе тасвирлаган ....... җанының иң матур, гүзәл сыйфатларын тотып ала белә. Язучы реаль ..... белән шигъриятне бергә куша, синтезлый. Мәдинә Маликова каләменә бер үзенчәлек хас: язучы сурәтләргә теләгән панорамасын турыдан-туры күрсәтми, бәлки аны икенче герой карашыннан чыгып чагылдыра, бәяли. Моның сәбәбе нидә соң? Минемчә, автор иҗат иткән шул икенче ..... тулылыгы һәм тирәнлегендә». Вставьте пропущенные в высказывании слова. (Учащиеся должны вставить слова «кешеләр, тормыш, образның» ).За каждый правильный ответ 1 балл.

Всего за «Разминку» каждая команда может набрать 3 балла.

4.Следующее задание посвящено биографии и творчеству писательницы:

1. В каком районе Татарстана родилась писательница? (Сармановском)
2. Где получила высшее образование? (в Казанском педагогическом институте).
3.С чего началась творческая деятельность писательницы? (с журналистики)
4.В каком журнале работала корректором? (Чаян)
5.Вкаком журнале былы заведующей отделом а в последствии ответственным секретарем? (Азат хатын)
6. Как назывался первый роман М.Маликовой? (Милосердие)
7.Создателем кого благотворительного общества была? (Красный полумесяц).
8. Назовите наиболее популярные романы? («Милосердие», «Вихрь», «Очарование», «Красный цветок», «Вкус ржи»). За каждое название команда получает 1 балл
9. Какой из своих роман лично перевела на русский язык? (Красный цветок)
10.В каком из Казанских театров по ее пьесам были поставлены спектакли? (в Татарском государственном академическом театре им. Г.Камала)

Подводятся итоги данного конкурса

5. Учитель: Пришло время показать своѐ домашнее задание: инсценировку эпизода из любого произведения М.Маликовой. За это задание максимальный балл 5. (Команды представляют свои домашние заготовки: учитывается оригинальность постановки, точность воспроизведения текста, актѐрское мастерство)

6. Учитель: Следующее задание такое: данные вам 10 предложений из романа «Красный цветок» надо расположить так, чтобы получился связный текст. (Каждой команде выдаѐтся набор из 10 предложений. Учитываются быстрота и правильность выполнения). Максимальное количество баллов 3.

Образец задания: отрывок из романа «Красный цветок»

2)На закате солнце заливало ласковым светом многоэтажные дома, прямые улицы. 4) Она ведѐт к дверям магазина, расположенного на первом этаже девятиэтажки. 5)Место людное – в выходной день после полудня и стар и млад толкутся во дворах и на улице.

8)А на лице – морщины от довольной улыбки.

6)В дверях магазина показался невзрачный старичок.

1)Был ясный, тихий день раннего лета.

7) Судя по облику, жизнь изрядно его потрепала: узкие плечи опущены, распахнутый на пузе коричневый в полоску пиджачок изношен и помят, криво посаженная некогда белая бейсболка грязно-серого цвета.

9) Чёрный пластиковый пакет в правой руке топорщится от покупок, из него выглядывает горлышко коричневой пивной бутылки.

10) По всему видать: сегодня дедуле принесли пенсию.

3) Одна из них протянулась вдоль низкого, пологого склона так, что дома на одной стороне кажутся ниже, с противоположной же стороны от высоких зданий к тротуару спускается подстриженный газон, который пересекает широкая лестница.

Подводят итоги конкурса, объявляют результаты.

7. Учитель: Заключительное задание может определить победителя, а состоит оно в следующем: напишите эссе о месте Мадины Маликовой в татарской литературе. Максимальный балл 5

8. Определяют команду-победительницу.

9.Учитель: Вот и подошѐл наш КВН к концу. Давайте поделимся впечатлениями от данного мероприятия. (Рефлексия.) Учитель о своих впечатлениях говорит последним.

## МӘДИНӘ МАЛИКОВАНЫҢ «ОҖМАХ БАЛАЛАРЫ» ФАНТАСТИК ТРАГИКОМЕДИЯСЕ БУЕНЧА ТЕСТ

Адлер Эльвира Демьян кызы, Заһитова Ләйлә Әзһәр кызы,
беренче санлы Актүбә урта гомумбелем бирү мәктәбе,
Азнакай районы

**Максат:** Мәдинә Маликова әсәрләренә кызыксыну уяту, укучыларның белемнәрен тикшерү һәм бәяләү, ата-анага, гаиләгә, өлкәннәргә хөрмәт, кешеләрдә уңай сыйфатлар тәрбияләү.

**Кулланган әдәбият:** Мәдинә Маликова, «Алтын ятьмә» китабы, Казан, “Матбугат йорты” нәшрияты, 2001 ел.

**Биремнәр.**

1. Бу әсәрдә ничәнче сыйныф укучылары катнаша ?

а) 3 ә) 4 б) 8

2.Вакыйга кайда бара?

а) мәктәптә ә) интернатта б) балалар бакчасында

3. Әсәрдәге укучы кызның исеме ничек?

а) Диана ә) Дездемонаб) Дәлия

4. Әсәрдәге укучы егетнең исеме ничек?

а) Фингал ә) Фонарь б) Финаил

5. Тәүфикъ кем булып эшли?

а) шофёр ә) директор б) милиционер

6. Мәгърифә ханым кем булып эшли?

а) директор ә) табиб б) укытучы

7. Роботның исеме ничек?

а) Эшбатыр ә) Эшбикә б) Эшлебикә

8) Роботның номеры нинди?

а) 867 ә) 768 б) 687

9. Бәхтия нәрсә ул?

а) Җир шарыннан 40 миллион километр читтәге ясалма планета....

ә) Җир шарыннан 20 миллион километр читтәге ясалма планета....

б) Җир шарыннан 20 миллиард метр читтәге ясалма планета....

10. Дездемонаның иң олы сере?

а) аяклы булу ә) авылга кунакка бару б) матур күлмәкләр кию

11. Бу әсәрдә нинди мөнәсәбәтләр өстенлек итә?

а) табигать һәм кешеләр мөнәсәбәтеә) ата-ана һәм укытучылар мөнәсәбәтеб) ата-ана һәм бала мөнәсәбәте

12. Бу әсәрнең төп фикере нинди?

а) бала гаиләдә тәрбияләнергә тиешә) бала коллективта тәрбияләнергә тиеш

б) бала үзе теләгән җирдә тәрбияләнергә тиеш

13. Тәрбияче Гөлнур һәм робот Эшбикә җирдә нинди тормышка тап булалар?

а) кешеләр арасында торган саен көчәя барган тупаслыкка, шәфкатьсезлеккә, инструкцияләр буенча гына яшәүгә корылган тормышка тап булалар.

ә) кешеләр арасында торган саен көчәя барган игелеклелеккә, шәфкатьлелеккә, инструкцияләр буенча гына яшәүгә корылган тормышка тап булалар.

б) кешеләр һәм табигать арасында, килешеп яшәүгә корылган тормышка тап булалар.

## НАРКОМАНИЯ АФӘТЕНӘ КАРШЫ – ЯҢА ТЕХНОЛОГИЯЛӘР

(Осталык дәресе)

Афзалова Луиза Әкрам кызы, Шәйдуллина Ландыш Камил кызы,
икенче санлы Җәлил урта мәктәбе укытучылары, Сарман районы

Һәр дәрес укучы файдасына эшләргә тиеш. Киләчәк кешесе әхлаклы, кешелекле, хезмәт итәргә сәләтле, эшлекле шәхес булырга тиеш. Яңалыкны кабул итү, аны тормышка ашыру бервакытта да җиңел генә бармый, әлбәттә. Ләкин бүгенге мәктәп инновацион педагогик технологияләргә йөз белән борылырга тиеш, бу – заман таләбе. Туган тел мөгаллимнәренә тагын да кыенрак. Яңа шартларда без, беренче чиратта, укучының актив эшчәнлегенә – төркемнәрдә, парларда эшләүгә, проблемалы һәм проектлы укыту методларына юнәлтелгән эшчәнлекле төрдәге заманча белем бирү технологияләрен куллану кирәклеген аңларга һәм шул юнәлештә җиң сызганып эшкә тотынырга кирәк. Дәресләребез мавыктыргыч, кызыклы булганда гына, без укучылар, әти-әниләр белән уртак тел таба алачакбыз.

Бүгенге көн дәресенең яңалыгы нәрсәдә соң? Бу дәресләр укытучы һәм укучы арасында үзара хезмәттәшлеккә нигезләнә. Укучыларны эшкә этәрү, кызыксындыру максатыннан эш күбрәк төркемнәрдә оештырыла. Төркемдәге һәр бала үз фикерен әйтә, башкалар фикерен ишетә ала. Дәресләрнең уңай ягы шунда: дәрестә барлык бала да сөйләшә, төркемдәге балаларга үз фикерен җиткерә. Балалар бер-берсен тыңларга, бергәләп карар кабул итәргә өйрәнәләр.

Укучыларга туган телгә мәхәббәт һәм кызыксынуны ничек уятырга соң? Бу мәсьәләне, укытуның нәтиҗәле алымнарын кулланып, гадәти булмаган дәресләр, укучыларны үзлекләреннән белем алырга өйрәтү аша ирешергә мөмкин. Дәрестә һәр укучыны кызыксындыра белергә һәм эшләргә өйрәтергә кирәк. Дәрес укучы өчен артык катлаулы булмаска, аны эзләнүгә этәрергә тиеш. Монда миңа “РАФТ-технология” алымы ярдәмгә килә. “РАФТ-технология” алымы –билгеле бер тематикага корылган иҗади эш төрләренең берсе.

Түбәндәге таблицада РАФТ алымының аббривиатурасы бирелгән.

| Роль | Аудитория | Форма | Тема |
|---|---|---|---|
| Бирелгән теманың кем тарафыннан | Кемгә текстның багышланганын | Жанрны, форманы сайлау | Тематиканы, төп фикерләрне билгеләү |

| | | | |
|---|---|---|---|
| ачылуын билгеләү | билгеләү | | |
| КЫСКАЧА | | | |
| Р(оль) – бу эш кем исеменнән | А(удитория) – бу эш кемгә адресланган | Ф(орма) – хат,брошюра, интервью, эссе, буклет, альбом стенгазета, һ.б. | Т(ема) – текст нәрсә турында |

**Максаты:** Төркемнең һәр катнашучысын кызыксындырып актив эшчәнлеккә тарту, мотивлаштыру; иҗади сәләтне үстерү, һәр укучының үз фикерен белдерүе өчен шартлар тудыру. Эшнең методикасы мондый:

Укучыларга кызыклы, мөһим, актуаль булган теманы сайлыйбыз. Укучылар бу теманы бик төптән, тирән үзләштергән булырга тиеш. Шулай ук фантазиягә бай булу, иҗадилык, креативлык таләп ителә.

Дәрес алдыннан укучылар өчен шушы форматлы таблица әзерләнеп куярга кирәк. Барлык фикерләрне без шул таблица графаларына аңлаешлы итеп яза барачакбыз.

Дәрескә күп санлы дидактик күрсәтмә материал әзерләү яхшы. Алар укучыларга теманы истә калдырырга, аңа эмоциональ якын килергә ярдәм итәчәкләр.

РАФТ алымы укучыны темага тагын да якынрак тирәнрәк килергә, иҗади фикерләүне үстерергә, үзеңне төрле яктан ачарга, импровизацияләргә, куелган шартларны анализларга, үз фикереңне белдерергә ярдәм итә.

Хәзер бу алымның конкрет дәрестә куллану мисалын карыйк.

9 нчы сыйныфта Мәдинә Маликованың «Чәчкә балы» повестеннан өзек өйрәнелә. Өзекләрне өйрәнеп бетергәннән соң, йомгаклау дәресе үткәрелә. Гадәттә, дәрестә геройларга характеристика бирелә, әсәргә анализ ясала. Шул эшләрне төгәлләгәннән соң без әлеге алымны бик уңышлы куллана алабыз.

Төркемнәрдә роль бүлешәбез. Әсәрдә ике гаилә Сәгъдия белән Гамил гаиләсе һәм Геннадий белән Эльза гаиләсе. Аларның гаиләләрендә балалар бар. Җәмилнең, Макарның, Газимнең тормышларын иркенләп чагыштырып була. Җәмил белән Макарның язмышы аеруча гыйбрәтле. Моңа бит кешеләр гаепле. Шушылардан чыгып, укучылар үзләре төрле төрле социаль төркемнәрне тәкъдим итәләр. Төркемнәр санынча рольләр җыелу кирәк.

Аннан таблицаның икенче баганасына хезмәтне кабул итәрлек аудитория булырдай төрле өлкәләрдәге кешеләр, оешмалар һ.б. языла куела. Шәфкать туташларына, табибларга, әти-әниләргә, сатучыларга, наркотикка үрелүче яшүсмерләргә адресланган буклетлар ясарга була.

Өченче баганага бирелгән социаль рольләргә туры килгән төрле жанрлар сайлана. Без буклет чыгаруны кулай күрәбез.

4 нче графага төп фикерләр, идеяләр языла. Монда инде без бала тәрбияләүнең бик зур җаваплылык, ялгышларның һәлакәткә алып баруын, эчкечелек, наркоманиянең коточкыч афәт булуын, баланы җинаяткә этәрүче факторлар турындагы фикерләрне язабыз. Наркомания афәтенең нинди куркыныч булуын искәртәбез.

Укучылар төркемнәрдә үзләренә туры килгән рольдән чыгып буклет ясыйлар. Аннан шул эшләре белән таныштыралар. Бу очракта бер үк төрле идея төрле яклап ачыла һәм үтемлерәк аңлашыла. Дәреснең нәтиҗәлелеге дә югарырак була.

## ОХРАНА ОКРУЖАЮЩЕЙ СРЕДЫ НА ПРИМЕРЕ ПРОИЗВЕДЕНИЯ М. МАЛИКОВОЙ «ТАЛЫЕ ВОДЫ»

Ахметгалеева Ландыш Зиннуровна. учитель Джалильской СОШ №2,
Замаева Луиза Назировна, учитель Джалильской гимназии, Сармановский район

**Цель:** развивать познавательный интерес к живой природе, наблюдательность, учить детей делать элементарные выводы, побудить школьников к самостоятельному размышлению о важности воды для жизни планеты в настоящем и, главное, в будущем.

**Вступительное слово:** Добрый день, дорогие ребята. 22 марта – Всемирный день водных ресурсов. Этот день является уникальной возможностью напомнить человечеству о важности воды для окружающей среды и развития общества, для поддержания жизни на нашей планете.

Мы каждый день сталкиваемся с водой, но задумываемся ли мы о ней?Можем ли мы прожить без чистой воды хотя бы день?Бережно ли мы используем ценный природный ресурс?

На эти и другие вопросы нам предстоит ответить в ходе нашего мероприятия.

В одном из произведений М.Маликовой талая вода вынесена даже в заглавие. Речь идет о рассказе «Талые воды». Давайте послушаем начало этого рассказа.

“...Я иду за талой водой.

Я стараюсь прямо вступать, как в детстве. Возле тропы на поверхности снега красивые узоры. Снег не слепит глаза как зимой, не блестит уже как драгоценные камни. Оказывается, даже снег стареет. Правильно, он не грязный как в городе, но утонченный и тяжелый. Он еще крепко лежит на земле, но солнце уже прогнало его с гор и течёт ручьем вниз со скребками...”

Рассказы учащихся о талой воде. Полезные и лечебные свойства талой воды для организма.Споры о пользе талой воды продолжаются уже не первый год. Сторонники такой жидкости готовы выдвинуть «за» множество доводов. Значение для животных

Послушаем биографию Мадины Маликовой.

А сейчас, ребята, вам предстоит побывать в роли исследователей, узнать какими свойствами обладает вода. Работа в группах (проводят опыты):

1 группа Определяют прозрачность воды.

2 группа Вода – растворитель.

3 группа Определяют текучесть воды.

4 группа Вода не имеет запаха. Она бесцветна.

Спикеры каждой группы рассказывают о своих наблюдениях в других группах. На доске в центре разместить каплю воды от нее в стороны идут капли с названием свойств.

Физкультминутка

Сейчас, мы проведем конкурс загадок о воде. Отгадав загадки, вы ответите на вопрос, в каких агрегатных состояниях и какие же формы может принять вода? (Отгадывают загадки)

5 ученик. Вода – в океанах и морях, реках и озерах, под землей и в почве. На высоких горах, в Арктике, Антарктиде вода находится в виде снега и льда. Это вода в твердом состоянии. Лед можно видеть у нас на реках и озерах. Много воды в атмосфере: это облака, туман, пар, дождь, снег. На поверхности суши находится далеко не вся вода, имеющаяся на Земле. И твердый лед, и легкий, как газ, пар – тоже вода. Таково ее свойство: она бывает жидкой, твердой и газообразной.

О воде есть немало пословиц, сейчас вам предстоит поработать в паре (работают сильный, слабый ученик). Нужно правильно подобрать слова, чтобы получилась пословица.

Обсуждение пословиц.

Итак, вернемся к названию произведения: «Талые воды». Талая вода – это жидкость, которая была заморожена, а после вернулась в свое состояние обратно. В естественных природных условиях она образуется благодаря таянию льдов, снега. На сегодняшний день не так-то просто найти снег, который превратится после таяния в чистую, полезную для здоровья, воду.Особенно подвергается загрязнению снег, который расположен в промышленных зонах рядом с шоссе, дорогами.

Загрязнение снежного покрова происходит в 2 этапа. Во-первых, это загрязнение снежинок, во время их образования в облаке и выпадения на местность –влажное выпадение загрязняющих веществ со снегом.

Во-вторых, это загрязнение уже выпавшего снега, в результате выпадения загрязняющих веществ из атмосферы, а также их поступления из подстилающих почв и горных пород.

Итак, проведем органолептический анализ талой воды. Для этого мы отобрали снег, находящийся на территории и за территорией школы, возле дороги.

| № | Образец | Внешний вид | Запах | Прозрачность | Углеводородная плёнка |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Обычная вода | | | | |
| 2 | Талая вода – школьный двор | | | | |
| 3 | Талая вода – возле дороги | | | | |

Вывод: разделиться на группы, провести опыт, заполнить таблицу и сделать выводы.

1 группа (№3), 2 группа ( №4),3 группа (№1),4группа ( №2)

Общий вывод: Не надо загрязнять водоемы и окружающую среду. От загрязнения воды страдает все живое.

Решение экологических задач. Ребята, внесите свои предложения, как сберечь чистую воду в природных ее источниках?

Экологические эксперименты.

Учащиеся проводят опыты с водой, наглядно демонстрируя необходимость охранять воду.

Рефлексия Синквейн «Вода»

В решении экологических проблем каждый может и должен принять участие, все зависит от экологической культуры, поведения каждого гражданина. Все очень просто. Перед нами ставятся вопросы: «когда вы моете руки, будете ли вы пытаться закрывать кран, видя, что вода ещё капает или равнодушно пойдете дальше? Это тоже проявление вашей гражданской позиции по отношению к природе и обществу. А ведь гораздо легче сохранить, чем воссоздавать, вовремя уберечь, вместо того чтобы потом восстанавливать».

**Список использованной литературы**

М.Г.Маликова «Саф сөю турында кыйссалар: хикәяләр, повестьлар», Казан: Татар.кит.нәшр., 2010

Арабаджи В.И. «Загадки пресной воды» М.: Знание., 1973

Зарубин Г.П. «Окружающая среда и здоровье» М.: Знание., 1977

«Берегите эти земли, эти воды» М.: Знание., 1988

## МӘДИНӘ МАЛИКОВА ТОРМЫШЫ ҺӘМ ИҖАТЫ

(Мәктәпкәчә әзерлек төкремеөчен шөгыль конспекты)

Әндәрҗанова Эльмира Рифгат кызы,
«Фиалка» 116 нчы балалар бакчасы, Яр Чаллы шәһәре

**Максат:** мәктәпкәчә яшьтәге балаларны Мәдинә Маликованың тормышындагы кызыклы вакыйгалар һәм әсәрләре белән таныштыру.

**Бурычлар:** Балаларда язучы иҗатына карата кызыксыну теләге уяту. Балаларның фикерләү сәләтен, диалогик сөйләмнәрен үстерү. Балаларның әдәби багажын Мәдинә апа Маликованың әсәрләре белән тулыландыру.

**Ысуллар һәм алымнар:**әңгәмә, уен.

**Эшчәнлек барышы:**

**1.Оештыру моменты.**

Балалар түгәрәккә басалар:
Кулларга без тотындык,
Бер-беребезгә елмайдык.
Җылы күчте кулларга,
Рәхәт булды дусларга.

- Исәнмесез, балалар! Бүген без хатын-кыз язучылар белән танышырбыз. Бездә кунакта Айгөл апа Әхмәтгалиева булган иде. Ә бүген мин сезне Мәдинә Маликова белән таныштырам.

**2. Кереш өлеш.**

- Тактага күз салыгыз әле.Кемне күрәсез?
- Әйе гармунда уйнаучы кыз. Әйдәгез әле танышып китик, кем икән ул?
- Илһам Шакиров кебек күренекле шәхесләргә бай Сарман районыннан ул. Мортыш Тамагы дигән авылда дөньяга килгән.

**3.Төп өлеш.**

- Кемнәрнеңдер әби-бабайлары да бар бу авылда, шулаймы? Бу авыл турында безгә Рамазан сөйләп китсен әле.
- Әйе, шушы авылның табигате дә аңа илһам биргәндер. Сугыш башлангач, әтисе сугышка китә, яраланып кайта. Бу вакытта Мәдинә мәктәптә белем ала. Ул бик тә укырга ярата, күп укый. Әнисе дә шигъри җанлы була. Мәктәптә ул редактор да була.Ә кем соң ул редактор?
- Зур булмаган күләмдә стенага эләр өчен, мәктәп яңалыклары белән газета чыгаралар иде. Шуңа материаллар, шигырьләр язучы, эзләүче кешене редактор диләр. Басма газеталарның да хуҗаларын редактор диләр.Ул бу газета өчен җаваплы кеше.

Мәктәпне тәмамлагач, хәзерге Минзәлә көллиятендә белем ала. Менә карагыз әле, нинди күркәм уку йорты. Мин дә шунда белем алдым.

- Аннары Казанда белем ала.Анда ул шахмат түгәрәгенә йөри.Хәтта парашют түгәрәгенә йөри һәм сикерә. Газетада мәкаләләре басыла, гонорар ала. Нәрсә дип уйлыйсыз гонорарны?
- Әлбәттә, акча. Мәкалә, әсәрең басылып чыкса, хезмәтең өчен түлиләр. Шул гонорар дип атала. 25 сум акча ала. Ул акчага Мәдинә апа бер атна ашханәдә ашый ала ул вакытта. Аннан соң, укуын тәмамлагач, «Чаян» журналында эшли. Тагы бик күп газеталарда эшли.

**Физкультминут.**

- Ял иттек, танышуны дәвам итик. Алга Таба Мәдинә апа әсәрләр яза башлый, китаплар чыгара.
- Сез ничек уйлыйсыз, Мәдинә апаның балалары бар микән?
- Әлбәттә,аның 2 улы бар. Алар зурлар микән? Әйе, алар инде зур кешеләр. Ильяс Канадада, ә Искәндәр - Казанда. Программист булып эшлиләр.
- Бик күп әсәрләр язган дидек.Ул аларны тормыштан, чын булган хәлләрдән чыгып язган. Балалар,сез җәй көнениләр эшләргә яратасыз?

-Менә Мәдинә апа зур булса да,сезнең кебек икән әле ул. Бүгенге көндә дә яза. Су керергә,бакчада эшләргә ярата икән.«Кар сулары», «Сары тюльпаннар», «Көндәшләр», «Ай сүрелгән чак иде», «Шәфкать», «Хөкем» , «Адашканга юл кайда?», «Кояш күпере», «Казан каласы — таш кала», «Янартаулар яктысында» исемле әсәрләре бар.

**4.Ныгыту.**

- Без бүген нинди язучы белән таныштык?
- Әлеге сурәтләр буенча (рәсемнәрне яңадан күрсәтү) ниләр исегездә калды?
- Әлбәттә,балалар,сез сорауларга дөрес җавап бирдегез.Сезнең дә язучы буласыгыз киләме? Кемнәр тели, мин сезгә өйдә эшләргә бирем бирәм. Әти-әниләрегезгә Мәдинә Маликова турында сөйләрсез дип ышанам. Ял көннәрендә китапханәгә барып, аның китапларын ала аласыз һәм үзегез дә әкият язып алып килегез әле. Без аны шәһәребездә чыгып килүче «Көмеш кыңгырау» гәҗитенә җибәрербез.

**5.Йомгаклау.**

- Сезгә бүгенге шөгыльдә ниләр ошады, нәрсә исегездә калды? (Балаларның җаваплары тыңланыла)

- Шуның белән бүгенге шөгылебез тәмамланды.Алдагы көннәрдә тагы дәвам итәрбез.

## МӘДИНӘ МАЛИКОВА ИҖАТЫ

Әсәдуллина Әлфия Мансур кызы, Муртазина Альбина Николай кызы,
Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче Җәлил беренче урта гомуми белем бирү мәктәбе,
Сарман районы

Мәдинә Маликова – иҗат эшчәнлегенең буеннан-буена каләмен детектив әсәрләр жанрында чагылдырган язучы. Флүс Латыйфи «2002 ел прозасына бер караш» мәкаләсендә болай яза: “Былтыр әдәбиятыбыз сигез романга баеды”. Әлеге романнарга ул 80 нче еллар ахыры 90 нчы еллар башында барган вакыйгаларны сурәтләнүче М.Маликованың «Өермә» романын кертеп карый. “Романда төп ике герой бар: берсе Җәүһәрия Бикбулова, ә икенчесе – Харис Әхмәтнуров. «Өермә» Бикбулованың үтерелүе белән башланып китсә дә, ул һәм Әхмәтнуров романның үзәгенә куелган” (Галиуллин). Романда ике төп сюжет бар. Беренчесе – аны детектив сюжет дип атыйк. Җәүһәриянең үтерелүе һәм гаеплене табу тарихы, ягъни традицион детектив сюжет. Икенчесе – хәйрия җәмгыяте төзү, нигезләү тарихы, аны башкалар мәнфәгатьләрен кайгыртучылар һәм үз мәнфәгатьләрен кайгыртучылар конфликты оештыра, хасил итү. М.Маликованың Бөтентатар Кызыл ай җәмгыятенең президенты икәнен искә төшерсәк, бу темага язучының мөрәҗәгать итүе нигезсез түгеллеген аңлыйбыз.

Җәүһәрия белән Харис исә әлеге җәмгыятькә, аның кануннарына буйсынмыйлар, елганың агымына каршы баралар дисәк тә була. Алар үз чорының “ак каргалар”, үз җәмгыятьләрендә чит кешеләр.

Романның темасына килсәк, төп сюжет сызыгындагы каршылык җәмгыятьтә көчеш чорында үз мәнфәгатьләрен һәм башкаларны кайгыртучылар бәрелеше кебек конкретлаша. Автор Даниф персонажы мисалында үз мәнфәгатьләрен кайгырткан кешенең бәхеткә ирешә алмавы идеясен алга сөрә.

М. Маликованың «Өермә» романын сюжет-композициясе һәм сурәтләнгән дәнья ноктасыннан анализлап, түбәндәге нәтиҗәгә килдек:

1 Әсәр тулысынча детектив жанр таләпләрен жавап бирә. Беренче төп сюжет сызыгы – үтерүчене эзләү тарихы – аның үзәген тәшкил итә. Җәүһүрия Бикбулованың үтерү Харисның үтерүчене – Данифны фаш итүе белән төгәлләнә. Икенче сюжет сызыгы – хәйрия җәмгыятен төзү тарихы, жәмгыятькә бәя бирүче сюжет. Җәмгыятьнең икегә, кеше мәнфәгатьләрен һәм үз мәнфәгатьләрен кайгыртучыларга бүленүен сурәтләүче сюжет сызыгы.

2. Традицион төстә өч герой: корбан, жинаятьче, аны ачучы аерылып чыга.

3. Икенче төп сюжет сызыгы кешеләрне икегә аерып куя. Әсәрдәге башка геройлар үз яки башкалар мәнфәгатен кайгыртулары ягыннан бәяләнә.

4. Язучы әсәрдә күптөрле проблемалар куя һәм аларны чишә дә: фәкыйрь, яшәү урыны булмаган кешеләр проблемасы; кеше язмышына битарафлылык проблемасы; милләт язмышы проблемасы: катнаш никахлар, татар балаларының урыслашулары; яшь буын вәкилләреннең әхлак-тәрбия кануннарын югалта бару проблемасы; жинаятьчел төркемнәр проблемасы; кеше тормышының кыйммәте, матди ихтыяжлар янында югалу проблемасы; жәмгытьтә рухи кыйммәтләрнең түбән төшүе, әдәби-культура зәвыгының югалу проблемасы.

**Кулланылган әдәбият:**

1.Галиуллин Р.Р. Татар әдәиятында детектив эволюциясе.-Казан:Школа 2007-161 бит.

2.Латыйфи Ф 2002 ел прозасына бер караш. Язучыларның “Әдәби ел йомгаклары” җыентыгыннан / Казан утлары – 2003-№5-Б. 135-140.

3.Хантимерова Г. Төсләр балкышы. Мәдинә Маликова иҗат портретына штрихлар/ Г.Хантимерова/ Казан утлары -1981 -№8-Б.132-134.

## БӘХЕТЛЕ ОЧРАК

( интеллектуаль уен)

Бәдриева Фәридә Рәис кызы,
икенче санлы Җәлил урта мәктәбенең башлангыч сыйныф укытучысы,
Сарман районы

- Исәнмесез! Хәерле көн, хөрмәтле кунаклар, укытучылар, укучылар.

Бүгенге “Бәхетле очрак” исемле интеллектуаль уеныбызны башлап җибәрәбез. Уеныбызның темасы: “Мәдинә Маликова, аның иҗаты”, ягъни үзебезнең интеллектуаль мөмкинлекләребезне сынап караячакбыз. Хөрмәтле кунаклар, тамашачылар, командалар! Жюри әгъзалары белән танышып узыйк. (Жюри әгъзалары белән таныштыру).

Уеныбызда катнашучылар 4 нчы “а” сыйныфы укучылары – “Зирәкләр” командасы һәм – “Тапкырлар” командасы. Командалар үзегез белән таныштырыгыз әле. (командалар үз девизларын әйтәләр).

**Тапкырлар.**

Девиз: Тапкыр җиңәр оттырмас,
Сездән куып тоттырмас.

**Зирәкләр.**

Девиз: Зирәк һәр җирдә кирәк,
Тик чын зирәк бик сирәк!

Уеныбызны башлыйбыз һәм сүз **“Тапкырлар”** командасына бирелә.

1.Мәдинә Маликованың туган авылы (Мортыш Тамак авылы)
2.Язучының нинди әсәре медицина дөньясын яктырта? («Шәфкать»)
3.Мәдинә Маликова "Чаян" журналы белән ничек бәйле?(Корректор булып эшләгән)
4. Мәдинә Габделхаковнаның беренче гонорары (25 сум)
5. Гаиләдә ничәнче бала булып туган?(Беренче)
6. Әнисенең исеме (Һәдия)
7. Тормыш иптәше (шагыйрь Әхмәт Рәшитов)
8. Балалары (Ильяс һәм Искәндәр)
9. Ничә романы нәшер ителгән?(9 романы)

**"Зирәкләр"** командасына сораулар.

1.Беренче романы («Юлдашлар»)
2. Интеллигенция тормышына багышланган әсәре («Тылсым»)
3.Әсәрнең исеме кешене куркуга сала торган табигать күренеше белән бәйле әсәре («Өермә»)
4. Селекторлар белән киңәшкәннән соң язылган әсәр («Арыш тәме»)
5. 1993 елдан бирле нинди оешманың президенты итеп билгеләнгән? (Бөтентатар "Кызыл Ай" җәмгыятенең президенты)
6. 1980 елда бирелгән премия? (Хөсәен Ямашев премиясе)
7. «Арыш тәме» китабы өчен бирелгән исем (Тукай премиясе)
8. Ничәнче елны СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы булган? (1972 елда)
9. 1985 елда бирелгән мактаулы исем? («Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре»)

**Уен “Шушы яктан, шушы туфрактан без” җыры белән тәмамлана.**

Жюри әгъзалары тулаем уен нәтиҗәләрен, ягъни кайсы команда күпме очко җыйганын саный. Һәм нинди команда алга чыкканын игълан итә.

Бүләкләү.

## ЯКТАШЛАР ИҖАТЫН ӨЙРӘНӘБЕЗ

Вафина Рузилә Мөдәрис кызы, Төхбатуллина Роза Марат кызы,
5нче санлы "Әкият" балалар бакчасы, Җәлил бистәсе

**Проект темасы«Сарман төбәге язучылары иҗатын пропагандалау»**

**Проект эшенең максаты** –балалар белән районыбызда туып үскән язучыларның, шагыйрьләрнең тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнү; әти-әниләргә якташ язучыларыбызның республика әдәби-мәдәни дөньясында тоткан урынын күрсәтү, кызыксынуларын үстерү, занятиеләрдә милли-төбәк компонентын кулланыну системага салу.

**Проект эшенең бурычлары**:Балалар бакчасы базасында туган як әдәбияты, аның үткәне, бүгенгесе турындагы материаллар тупланмасы булдыру. Якташ язучылар, шагыйрьләр иҗатының гомумтатар әдәбияты тарихында тоткан урынын билгеләү, алар турында сөйләүче күрсәтмә әсбаплар әзерләү. Туган якка мәхәббәт, милли үзаң тәрбияләү.

**Проектның проблемасы:**Ата-аналарның,балаларның китаплар белән аз кызыксынуы.Балаларның китапларга саксыз карашы.Ата-аналарның һәм балаларның якташ язучыларыбыз,шагыйрьләребез иҗаты белән кызыксынмавы,аз белүе.

**Проектның идеясе**:.Балаларның язучылар,шагыйрьләр турындагы белемнәрен иҗади куллану..Язучылар,шагыйрьләр иҗатына кызыксыну уяту. Балалар,ата-аналар белән иҗади-мөстәкыйль эшләү өчен шартлар тудыру.

**Гамәлгә ашыру вакыты:** 2019-2021еллар

**Проект планы**

| Проект этаплары | Эшчәнлек төре | Хронологик кысалар |
|---|---|---|
| **Проектны башлап җибәрү** | | |
| Проект эше проблемасына төшенү, бурычларны конкретлаштыруһәм аларны чишү юлларын эзләү. | | Сентябрь, 2019 ел |
| **Эшчәнлекне оештыру** | | |
| Проект эшендә катнашучыларны сайлау, билгеләү, эш планын тәкъдим итү, эш юнәлешләрен билгеләү. | | Сентябрь, 2019 ел |
| **Эшчәнлекне чынга ашыру юнәлешләре** | | |
| 1) Китапханәләр белән эшчәнлек. Китапханәләрдән якташ язучыларыбызның балалар өчен булган китапларын барлау, аларның картотекасын, сканвариантларын булдыру, юбиляр якташ язучылар турында мәгълүматлар булдыру. | | Октябрь, 2019 ел |
| 2) Музей белән эшчәнлек. Якташ шагыйрьләр иҗаты буенча булган материаллар белән танышу, аларны куллану юлларын билгеләү. Бистә, район күләмендә үткәреләчәк чаралар планы белән танышу, катнашу мөмкинлекләрен ачыклау. | | Октябрь, 2019 ел |
| Әти-әниләр белән эшчәнлек.Аерым,күмәк әңгәмәләр үткәрү аша, әти-әниләрнең бу проблемага мөнәсәбәтен, хәбәрдар булу дәрәҗәсен ачыклау. Өй китапхаләренең торышы, балалар әдәбияты белән тәмин ителешне билгеләү | | Октябрь, 2018 ел |

| Эшчәнлек (нәниләр белән) | |
|---|---|
| Матур әдәбият уку.<br>Әсәрләр эчтәлеге буенча кисеп ябыштыру.<br>Әсәрләр эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү, сөйләм оештыру<br>Әсәрләрне сәхнәләштерү.<br>Рәсем конкурслары үткәрү. | Даими |
| **Эшчәнлек (өлкәннәр белән)** | |
| Әдәбият исемлеге белән таныштыру.<br>Бәйрәм тантаналары өчен шигырь, монологлар әзерләүдә ярдәм итү.<br>Театраль тамашалар бәйгесе оештыру.<br>Ата-аналар арасында әдәби конкурслар үткәрү.<br>Бергәләп китапханәләргә экскурсияләр оештыру.<br>Шагыйрьләр белән очрашуларда катнашу. | Даими |
| **Эшчәнлек (тәрбиячеләр)** | |
| Төркем бүлмәсе өчен якташ язучылар иҗаты буенча әдәби тупланмалар булдыру.<br>Китап сөючеләр почмагы булдыру, якташ язучылар турында мәгълүматлар урнаштыру.<br>Матур әдәбиятны пропагандалау буенча эш алып бару (очрашулар, әңгәмәләр, реклама аша)<br>Якташ язучылар иҗаты белән бәйле рәвештә районыбызның авыллары турында да мәгълүмат бирүне оештыру | Даими |
| **Нәтиҗә** | |
| Эшчәнлекнең нәтиҗәләрен гомумиләштерү һәм йомгак ясау | Май, 2021 ел |

**Көтелгән нәтиҗә:**

1. Балаларның иҗади сәләтләрен төрле эшчәнлекләр аша ачу.
2. Балаларны һәм эти-әниләрне иҗади эшчәнлек аша аралаштыру, балалар бакчасы белән гаиләнең элемтәсен ныгыту.

## МӘДИНӘ МАЛИКОВА ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ҺӨНӘРЧЕЛЕК СҮЗЛӘРЕ

Вилданова Лилия Равил кызы,
Мусабай-Завод уртагомуми белем мәктәбе,Тукай районы

Һөнәрчелек лексикасы телнең сүзлек байлыгында шактый зур урынны алып торган катламнарның берсе. Профессиональ сүзләргә багышланган хезмәтләр XIX гасыр ахырында пәйда була башлый. Әлеге төр сүзләрне өйрәнүдә Р. Рәхимованың өлеше зур. Аның 1983 елда басылган «Татар теленең һөнәрчелек лексикасы» китабы һәм татар һөнәрчеләре телендәге сүзлек составын өйрәнгән, анализлаган күпсанлы мәкаләләре бар. Шулай ук Р. Рәхимованың «Профессиональная лексика татарского языка, относящаяся к ткачеству, одежде, обуви и головным уборам» (1975), «Из древнетюркского пласта кожевенной лексики татарского языка» (1986), «О татарской отраслевой терминологии» (1988) һәм башка мәкаләләре дә һөнәрчелек лексикасына караган хезмәтләрдән санала. Һөнәрчелеккә кагылышлы сүзләр башка төр лексиканы өйрәнүгә багышланган фәнни хезмәтләрдә дә фәнни дәрәҗәдә шактый җентекле тикшерелә. Мисал өчен, Ф. Гаффарованың «Татар телендә җир эшкәртү лексикасы» (2000), Д. Рамазанованың «Названия одежды и украшений в татарском языке в ареальном аспекте» (2002), З. Садыйкованың «Названия хозяйственных

построек и инвентаря в татарском языке» (2003), А. Сәгыйтованың «Татар телендә агач архитектурасы лексикасы» (2004) һ.б..

Эшнең актуальлеге – М. Маликова әсәрләрендә кулланылган һөнәрчелек сүзләренең бүгенге көнгә кадәр өйрәнелмәве.Тикшерү объекты – татар телендәге һөнәрчелек лексикасы. Тикшерү предметы – һөнәрчелек лексикасының әдәбиятта кулланылу үзенчәлекләре. Эшнең максаты: М. Маликова әсәрләрендә кулланылган һөнәрчелек сүзләрен өйрәнү. Анализ өчен без язучының «Янар таулар яктысында» һәм «Казан каласы – таш кала» повестьларын алдык.

Тематик яктан төркемләүгә килгәндә, ике әсәрдә дә рәссамнар, музыкантлар һәм диңгезчеләр куллана торган һөнәри сүзләр бар. Ә «Казан каласы – таш кала» әсәрендә архитекторлар сөйләмендә кулланыла торган профессиональ лексика да урын алган. Рәссамнар куллана торган профессиональ лексикадан автор, аеручы яратып, “акварель”, “портрет”, “автопортрет”, “пейзаж”, “натюрморт”, “пумала” сүзләрен куллана. Әлеге сүзләрне рәсем ясау белән шөгыльләнгән кешеләрнең сүзлек составында еш очратырга була. Шулай ук “жанровый рәсемнәр”, “этюд”, “этюдник”, “фломастер”, “иллюстрация”, “репродукция”, “гравюра”, “майлы буяу”, “сюжет”, “мозаика”, “мольберт”, , “каләм сурәте”, “планшет”, “палитра”, “полотно”, “рам”, “төсләр гаммасы”, “композиция” сүзләрен дә язучы берничә җирдә оста файдалана. Әлеге сүзләр күп очракта автор сөйләмендә кулланыла.

Шушы ук әсәрдә М. Маликова музыкантлар сөйләмендә кулланыла торган һөнәрчелек сүзләрен дә куллана. “Концертмейстер”, “баритон”, “оркестр”, “оркестрант”, “аккордеонист”, “камертон”, “фокстрот”, “ария”, “опера”, “симфоник музыка” кебек сүзләрне еш очратырга мөмкин. Бу сүзләр шулай ук укучыны әлеге һөнәр ияләренең тормыш-көнкүрешенә, яшәешенә алып кереп китәргә ярдәм итәләр.

Диңгезчеләр һөнәри лексикасына килгәндә, “причал”, “палуба”, “трюм”, “плашкоут”, “траулер”, “флот” кебек сүзләрне бик еш куллана. Шулай ук “путина”, “плавбаза”, “гейзер”, “шарлавык”, “култык”, “баржа”, “сопка”, “катер”, “рубка”, “янтык”, “якорь”, “эпидиаскоп”, “вулкан бомбалары”, “метрдотель”, “ишкәк”, “дамба”, “китель”, “рупор” кебек профессиональ сүзләрне дә очратырга мөмкин.

Архитекторлар сөйләмендә кулланыла торган һөнәри сүзләр “Казан каласы – таш кала” әсәрендә күзәтелде. Әлеге повестьта күзәтелгән профессиональ сүзләр түбәндәгеләр: “мастерской”, “кульман”, “проектлау”, “смежник”, “эскиз”, “макет”, “смета”, “маляр”, “конструктор”, “конструкция”, “арматура”, “сызым”, “типовой проект”, “бетон”, “плитә”, “сграффито”, “обелиск”, “калька”, “реконструкция”, “вестибюль”, “интерьер”, “фасад”, “смальта”, “витраж”, “кульман”, “готика”, “барокко”.

Югарыда күрсәтелгән һөнәрчелек сүзләрен этимологик яктан тикшерсәк, түбәндәге нәтиҗәләргә килергә мөмкин: нигездә, күпчелек профессионализмнар рус теле аша европа телләреннән кергән сүзләр (“акварель”, “портрет”, “автопортрет”, “пейзаж”, “натюрморт”, “этюд”, “этюдник”, “фломастер”,” иллюстрация”, “репродукция”, “гравюра”, “концертмейстер”, “баритон”, “оркестр”, “оркестрант”, “трюм”, “плашкоут”, “траулер”, “флот”, “баржа”, “катер”, “метрдотель”, “рубка”, “якорь”, “сюжет”, “мозаика”, “эскиз”, “планшет”, “палитра” һ.б.). Шул ук рәткә “плитә” сүзен дә кертеп карарга мөмкин. Ул рус теленә европа телләре аша “плита” сүзе булып килеп кергән һәм фонетик яктан татар теленә яраклаштырылган.

Рус теленнән кергән һөнәрчелек сүзләре дә бар: “причал”, “палуба”, “путина”, “сопка”. Шулай ук “пумала” сүзе рус телендәге “помело” сүзеннән барлыкка килгән, әмма ул фонетик яктан татар теленә яраклашкан. Татар теленең үз сүзләре составында каралган һөнәри сүзләр дә бар. Мисал өчен, “буяу”, “шарлавык”, “култык”, “сызым”. Гомумән, һөнәрчелек сүзләре күпчелек европа теле аша рус теленнән кергән сүзләр. Ике әсәрдә барлыгы 85 һөнәрчелек сүзе кулланылган. Шул профессионализмнар арасыннан 69 сүз рус теле аша европа телләреннән кергән сүзләр. 8 һөнәрчелек сүзе рус теленнән кергән булса, 8 сүз татар теленең үз сүзлек составында булган сүзләр. Әлеге нәтиҗәләрне диаграммада күрергә мөмкин (1 нче кушымта). Ясалышы ягыннан исә, күпчелек һөнәрчелек сүзләре тамыр сүзләр, шулай да сүз ясагыч кушымча ялганып ясалган сүзләр (“аккордеонист”, “шарлавык”, “оркестрант”), тезмә

(“жанровый рәсемнәр”, “майлы буяу”, “вулкан бомбалары”, “типовой проект”, “каләм сурәте”), кушма (“автопортрет”, “концертмейстер”) һөнәри сүзләр дә очрады.

Гомумән алганда, М. Маликова әсәрләрендә һөнәри лексика зур урынны алып тора. Һәрбер профессиональ сүз укучыга якынаю, әсәрне реаль чынбарлыкка якынайту максатыннан кулланыла. Авторның әсәрләрендә кулланылган һөнәрчелек сүзләрен анализлаганнан соң түбәндәге нәтиҗәләргә килдек: тематик яктан рәссамнар, диңгезчеләр, музыкантлар һәм архитекторлар куллана торган профессиональ сүзләр бар. Этимологик анализ күрсәткәнчә, әлеге һөнәри сүзләр күбесенчә алынма сүзләр, татар теленең үз сүзлек составында кулланылган сүзләр дә бар. Ясалышы ягыннан күпчелек тамыр сүзләр булса да, тезмә, кушма, ясалма профессиональ сүзләр дә очрады.

Киләчәктә М. Маликова әсәрләрендә кулланылган һөнәри лексиканы фәнни яктан өйрәнүгә зур урын бирелер дип ышанып калабыз.

**Кулланылган әдәбият:**


1. Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге. Казан: Мәгариф- Вакыт, 2015.
2. Галиуллина Г.Р. Татар лексикологиясе. Казан: ИЯЛИ, 2016
3. Маликова М.Саф сөю турында кыйссалар.Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2010
4. Маликова М. Янар таулар яктысында. Казан, татарстан китап нәшрияты, 1980
5. Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле.Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2002


## МӘДИНӘ МАЛИКОВАНЫҢ ИҖАТЫНДА ӘХЛАК ПРОБЛЕМАЛАРЫНЫҢ ЧАГЫЛЫШЫ


Габдулхакова Инсия Зөфәр кызы, 25 нче санлы Әлмәт урта мәктәбе,
Җәмилова Гөлнур Рәис кызы, икенче санлы Җәлил урта мәктәбе,
Сарман районы


Мәдинә Маликованың иҗаты тематик төрлелеге, көкүреш проблемаларыннан иҗтимагый-сәяси, милли мәсьәләләргә күтәрелү потенциалы, мавыктыргыч сюжетлар һәм истә калырлык образларның тәрбияви мөмкинлеген беренче планга чыгаруы ягыннан үзенчәлекле. Маҗаралык һәм тормышны детальләргә тергезү, геройларга карата психологик алымнар куллану осталыгы язучы иҗатында көчле әхлакый башлангыч белән табигый үрелеп китә. Дүрт дистә ел дәвамында әдибәнең иҗаты киң катлам укучыга заман таләбе белән тәкъдим ителә. Аның әсәрләре рухи кыйммәтләребезне, үткәнебезне һәм бүгенгебезне кабул итүгә, үзебездә булган уңай һәм тискәре якларны анализларга, кимчелекләрдән арынырга ярдәм итә. Язучылар аның иҗатын югары бәяли. Әйтик, Зиннур Хөснияр язучы турында түбәндәге фикердә: "Мәдинә Маликова үзе тасвирлаган кешеләр җанының иң матур, гүзәл сыйфатларын тотып ала белә. Язучы реаль тормыш белән шигъриятне бергә куша, синтезлый". Мансур Вәлиев исә, бөтен повестьларының игътибар үзәгендә ике төрле яшәү рәвеше тора, дигән бәя бирә.

Татар әдәбияты бай һәм үзенчәлекле, һәр язучының үз аһәңе, үз стиле, язу манерасы, китаплары бар. Алар арасында Мәдинә Маликова әсәрләре аерым урын-ниша алып торалар. Мәдинә Маликова иҗатына колачлылык, масштаблылык, киң планлылык хас.

М. Маликова – драматургия өлкәсендә дә язган автор. Аның «Оҗмах балалары» исемле драмасы Г.Камал исемендәге академия театры сәхнәсендә куелды (1990), «Йөрәк ничек түзсен», «Моңнар төште башыма», «Синең өчен үзем үләрмен» исемле драма әсәрләре узган гасырның туксанынчы елларында Минзәлә һәм Әлмәт театры сәхнәләрендә уңыш белән барды.М.Маликованың дөньяга киң карашлы булуы, иҗтимагый һәм рухи актив тормыш белән яшәве бөтен иҗатына тирән эз сала. Ул, язучы буларак, чорның актуаль мәсьәләләрен, өлгергән проблемаларын таба, мавыктыргыч сюжетһәм истә калырлык образлар ярдәмендә җәмәгатьчелекнең игътибарын шуларга юнәлтә белә. Бу иҗат образларның бай галереясы,

кеше-мохит-чор бәйләнеше, стиленең төрле сурәтләү чараларына бай булуы белән дә, әдәбиятыбызның кыйммәтле бер өлеше булып тора.

### ҺӘР ӘСӘРЕ – ТӘРБИЯ ДӘРЕСЕ

Газизова Рәмзия Асфан кызы, Әсәдуллина Әлфия Мансур кызы,
Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче Җәлил беренче урта гомуми белем бирү мәктәбе,
Сарман районы

Татар әдәбиятында романнар иҗат иткән хатын-кыз язучылар бармак белән генә санарлык: XX гасыр башында иҗат иткән Дәрҗия Аппакова,бүгенге көндә бер-бер артлы күләмле әсәрләр тудыручы Фәүзия Бәйрәмова һәм Мәдинә Маликова. Өч шәхес, өч төрле иҗат.

Мәдинә Маликова – киң кырлы талант иясе. Аны без журналист, публицист, актив җәмәгать эшлеклесе һәм язучы дип беләбез. Аның повесть-хикәяләре дә, драмалары да байтак. Һәрвакыт талантлы прозаик-драматург, ә драматург-прозаик була алмый. М.Маликова иҗаты белән танышкач, аның әлеге ике жанрда да уңышлы эшләвен аңлыйсың. Аның драма әсәрләре катлаулы сюжетка корылмаганга, тискәре һәм уңай персонажларны билгеләве авырлык тудырмый. Аларның уй-кичерешләре укучы-тамашачыны әсирлектә тота.

«Йөрәк ничек түзсен?» исемле ике пәрдәле фаҗига-риваятендә, тарихи вакыйгаларга мөрәҗәгать итсә, «Синең өчен үзем үләрмен» исемле драмасында гаилә проблемалары күтәрелә.

М.Маликованың драма жанрына гына түгел, комедия жанры үсешенә дә керткән өлеше игътибарга лаек. «Ал,Сәкинә, Әмирикәне!» исемле комедия аның иҗат үзенчәлекләрен дә билгели кебек. Әсәрнең төп персонажлары - бүгенге җәмгыятебездәге хатын-кызлар. Бу – унтугыз яшьлек студент кыз Сәкинә. Аның әнисе Бәдига - гомерен кара эштә эшләп үткәргән илле яшьлек хатын. Бәдиганың кардәше - эшмәкәрлек белән шөгыльләнүче кырык яшьлек Нәсихә һәм Бәдиганың күршесеТравиата. Нәсихә белән Әлфис образлары игътибар үзәгендә. Аларның авантюристлыгы, матур тормышка кызыгучы романтик яшь кызларыбызны чит илләргә сатып җибәрүе, киләчәгебезнең нигезен тәшкил итәргә тиеш кешеләребезне кара эшчеләр, фахишәләргә әйләндерүе – чорыбызның зур фаҗигасе. Комедиядә көлү түгел, елардай моментлар шактый. ”Биш”легә генә укып килгән Сәкинәнең бу кармакка кабуы зур уйлануларга этәрә. III курс студенты Мөдәррис тә Сорос бүләгенә үткәрелгән бәйгедә җиңеп, шул ук Америкага җыена.

Шулай да М.Маликова оптимистик карашка өстенлек бирә. Моны без Мөдәрриснең бүлмәдәше Әдһәм, шулай ук Руфия образлары аша җиңел генә билгелибез.

Эшебезнең нәтиҗәсе:

1.Драматургия өлкәсендә М.Маликова, беренче чиратта, үзенең фаҗигале драмалары белән таныш.Аларның төп конфликты дәүләт, бурыч, закон һәм күңел, хис каршылыклары нигезендә төзелә.

2.М.Маликова драматургиясе – тормышка якын.Аның геройлары шактый ук типик. Ләкин алар үзләренең романтик күңелләрен җәмгыятьнең миһербансызлык, икейөзлелек кебек сыйфатларына каршы куярга һәрвакыт әзер.

3.Аның бөтен пьесаларында да капма-каршы куелган уңай һәм тискәре геройлар бар. Әлбәттә, күп геройлары, типик персонажлар буларак, аклы-каралы буяулар белән генә бирелми. Шунысы әһәмиятле: М.Маликованың драмалары сюжет җыйнаклыгы һәм еш кына персонажларның йә уңай, йә тискәре генә булуы белән аерылып тора.

Әсәрләрендә М.Маликова һәрдаим уңай хатын-кыз образына мөрәҗәгать итә. Бу аның иҗатында төп үзенчәлекләрнең берсе булып тора. Бүгенге яшьләрне тәрбияләгәндә, аларны

олы тормыш юлына чыгарып җибәргәндә авторның иҗат җимешләре үз бәһасен һич тә югалтмаячак.

**Кулланылган әдәбият:**

1.Борханова Г.Д. Рухи байлык– хезмәт җимеше, - Актаныш, 2007

2.Заһидуллина Д.Ф. Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы., - Казан:Мәгариф, 2004

3.Л.Хисмәтова, Р.Ханнанов.Тәрбия дәресләре.Мәгърифәт.14.04.2007 ел

## М. МАЛИКОВАНЫҢ «ЕГЕТЛЕККӘ БЕР АДЫМ» ПОВЕСТЕН ӨЙРӘНҮ

Галиева Ләйсән Әнвәр кызы, Җәмилова Гөлнур Рәис кызы,
икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирүмәктәбе, Сарман районы

**Дәрес максатлары:** Укучыларны язучының тормышы һәм иҗаты белән таныштыру; әсәрләре турында күзаллау булдыру. «Егетлеккә бер адым» әсәренә күзәтү ясау; эзләнү һәм чагыштыру ярдәмендә укучыларның фикерләү сәләтен үстерү. Ата – ана, ата – ул мөнәсәбәтләре турында уйлану, кешелеклелек сыйфатлары тәрбияләү.

**Көтелгән нәтиҗә:**

- предмет нәтиҗәләре: әсәрнең әһәмиятен һәм кыйммәтен ачу; дәресне тормыш белән бәйләү;

- шәхси нәтиҗәләр: геройларның гамәлләренә гомумкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирә белү; башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык, кеше кадерен белү кебек хисләр формалашу;

- метапредмет нәтиҗәләре: коммуникацион технологияләр аша тапшырыла торган мәгълүмат чаралары белән эшләү тәҗрибәсен ныгыту.

Универсаль уку гамәлләре:

- танып белү УУГ: укучыларның сорау куя белү, нәтиҗә ясый белү кебек фикерләү сәләтләрен үстерү, үз фикерләрен дөрес итеп әйтүләренә ирешүне булдыру;

- регулятив УУГ: эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү; ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сыйфатларга ия булуга ирешү;

- коммуникатив УУГ: төркемдә эшли белү; мәгълүматны туплау өчен күмәк эшчәнлектә катнашу.

Дәрес барышы.

Оештыру.Уңай психологик халәт тудыру.

II. Үткән дәрес темасын актуальләштерү. 1)Мәдинә Маликова турында ниләр беләсез? (Укучылар чыгышы). Мәдинә Маликованың биографиясен сөйләү (презентация)

2)Аның нинди әсәрләрен беләсез? (Укучылар чыгышы)

3) Сез өйдә укып килгән «Егетлеккә бер адым» повестен өйдә укып бетердегезме? Әсәр сезгә ошадымы?

III.Әйдәгез, хәзер әсәргә анализ ясыйк.

Кластер төзү. Әсәрдә төп герой – Бикташ исемле малай.Аның атасы Сәетҗан, анасы Салиха. Бер сюжет сызыгы атасының яңа гаиләсендә “бөтерелсә”, ә икенчесе – малайның әнисе белән бәйләнгән. М.Маликованың бу әсәрендәге геройларны төрлечә системага салырга мөмкин.Башта бу геройларны укучылар түбәндәгечә тәкъдим иттеләр:

Тагын уңай, яки тискәре геройларны аерым группага урнаштырып та эшләделәр:

Уңай: Салиха, Фая түтәй, Васька, Әхсән, ...

Тискәре геройлар: Сәетҗан, Бәһиҗә, Илдар, ...

2. “Фишбоун”

Укучылар “балык башын” бик тиз  әйттеләр, әсәрдә проблема – атаның үз улын шәһәргә алып китүе(фатир кирәк булганга).  Ә темасы, исеменнән күренгәнчә, Бикташның беркатлылыгы.




3.Тагын бер  алым – синквейн.

| | | |
|---|---|---|
| Бикташ | | |
| Беркатлы | Ышанучан | |
| ышана | китә | аңлый |
| Егетлеккә бер адым | | |
| Ә кайберәүләрдән тормыш  кинәт җитлегүне таләп итә | | |

Рефлексия: Һәр кеше үз язмышына үзе хуҗа була ала.

Йомгаклау. Төп геройның төрле хәлләрдә үзен төрлечә тотуы, әмма ахырда, үзенең дөрес эшләмәвен тануы – безгә сабак бирә.

Өй эше. Әсәрдәге берәр геройга  характеристика бирү.

## БАЛАЛАРГА ӘХЛАК ТӘРБИЯСЕ БИРҮДӘ М.МАЛИКОВА ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ РОЛЕ

Галиева Ләйсән Әнвәр кызы, Садыйкова Илмира Зөфәр кызы,
икенче санлы Җәлил урта мәктәбе, Сарман районы

Хикәяче, романчы, драматург, публицист Мәдинә Маликова иң беренче басылып чыккан «Юлдашлар» (1967) исемле беренче җыентыгында ук тирән әхлакый мәсьәләләрне җитди итеп куярга омтылуы белән аерылып тора. Аның беренче хикәяләре үк моның ачык мисалы була. Язучының «Егетлеккә бер адым» повесте 1976 нчы елда языла. Әсәрнең төп герое булып, Бикташ исемле малай  тора, аның әнисе Салиха, шулай ук вакыйгалар җебен ялгауда булышучы персонаж.  Үсмер малай гына булуга карамастан, җитди проблемалар туган очракта олыларча чишәргә омтылуы, үз әнисенә ярдәмгә килүе, бу әсәр аша  балаларда гомумкешелек кыйммәтләрен тәрбияләүдә мөһим әсәр булып тора.

Әсәр нигә повесть дип атала соң? Повесть ул – төп герой тормышындагы берничә охшаш вакыйганы сурәтләгән, берничә сюжет сызыгын бер үзәккә туплаган эпик жанр. Без моның белән килешәбез, чөнки  Бикташ исемле малайның тормышы белән беррәттән, аның әтисенең тормышы да яктыртыла. М.Маликова төрле сюжет сызыкларын оста итеп бәйли алган.

Әсәр «Егетлеккә бер адым» дип атала. Әле егет булып җитешеп кенә килүче малай, шәһәргә барып, андагы тормышның барлык якларын күрә, каты бәгырьле кешеләргә очрап, кимсетелүләргә тарый, алай гына да түгел, үз якыннарының үзен кимсетүләрен башыннан кичерә. Һәр геройның бу малайга карата нинди дә булса мөнәсәбәте ачыклана: кемдер аңа ярдәмгә ашыкса, икенчеләре мәкерле планын әсәр башында ук корып куя. Әсәргә илһам өстәүче Бикташның әнисе – Салиха. Ул әсәрдә үз-үзен тотышы, күрше-күлән белән тыйнак аралашуы, гади генә тормыштан тәм табып яшәве белән безне уйланырга мәҗбүр итә. Халык теле белән әйткәндә, гап-гади авыл хатыны. Аның эчке дөньясы  башкачарак, бик үк гади дип әйтеп булмас иде. Автор язганча, Салиханы  Сәетҗанга димлиләр. Алар икесе ике мохит кешеләре, берсе – тормышта җигелеп яшәүче, ә икенчесе – тормышка бармак аша караучы кешеләр.

Без башта авыл җирлегендәге вакыйгалар чолганышында булабыз, табигатьнең матурлыгына сокланабыз, әсәрдәге мөнәсәбәтләрне үз җаебызга көйләргә тырышабыз. Автор безне әкрен генә шәһәр тормышына алып кереп китә. Төп герой матур гына тормыш итеп яткан җиреннән, үзе дә башына китермәгән хәлләрдә кала. Ул авыл тормышына күнеккән, үги ата белән яшәп, “тормыш мәктәбе”н үткән, әнисен, сеңлесен, дус-ишләрен хөрмәт итеп яшәргә өйрәнгән. Үз атасы кайтып, шәһәргә китәргә өндәгән малайга башка юл юк. Атасының күңел “каралыгы”н да тоймыйча, әнисенең ялварулы күзләренә карамый гына китеп баруы, укучыны аптырата. Ата-ананы сайлап булмый, диләр. Атасының “караңгы” уйлары булуын Бикташ кайдан белсен? Аны әнисе чын кеше булсын дип тәрбияли бит, үскәч чын ир-егет булсын, ди. Үз атасы кебек, акча эшләргә киткән җиреннән әйләнеп кайтмаган, куркак җан итеп тәрбияләми аны Салиха. Шуңа күрә, малайны атасы белән җибәрәсе дә килми.

М. Маликованың бу повестенда кабатланып килүче мотивлар – мәхәббәт, югалту, иман. Ана мәхәббәте, аның көче, баланың күнелендә мәңге онытылмас хис. Һәрбер ана үз баласына яхшылыклар гына тели, баласы өчен утка да, суга да керергә әзер. Ананың алдан уйлап әйтелгән сүзләре яки әйтәсе килеп тә әйтелми калганнары да була. Күп очракта, ананың фикере дөрес булса да, үз баласына уйланырга җирлек бирә. Соңыннан, төп герой үз хатасын аңлый, авылына кайта. Кешеләр, тормышның төрле якларын, үзләре хата ясап кына, аңлауларын таныркга мәҗбүр булалар.

**Кулланылган әдәбият**


1. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге.- Казан: Мәгариф, 2007.
2. Заһидуллина, Д.Ф., Әдәби әсәргә анализ ясау/ Д.Ф. Заһидуллина, М.И.Ибраһимов.- Казан, Мәгариф, 2005.
3. Заһидуллина Д.Ф., Татар әдәбияты:Теория.Тарих/ Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов, Т.Ш. Гыйләҗев. Казан: Мәгариф, 2004.


## МӘДИНӘ МАЛИКОВАНЫҢ ӘСӘРЛӘРЕ БУЕНЧА ПРОЕКТ ЭШЕ


Галимова Разиля Ринат кызы, 3 нче санлы гомуми урта белем бирү мәктәбе, Бөгелмә шәһәре


Татар әдәбияты бай һәм үзенчәлекле, һәр язучының үз аһәңе, үз стиле, язу манерасы, китаплары бар. Алар арасында Мәдинә Маликова әсәрләре аерым урын-ниша алып торалар. Аның иҗатын без мәктәптә сыйныфтан тыш дәресләрдә аерым бер кызыксыну белән укыйбыз, проектлар төзибез. Класстан тыш дәресләрдә куллану өчен, укучыларны китап укуга җәлеп итүнең тагын бер ысулы – китапнамәгә аерым тукталып узасым килә.

Соңгы елларда китапнамәләр ясау актив кулланылышка кереп китте. Китапнамә – кыска итеп әсәр эчтәлеге турында ясалган видеоролик. Аның төп бурычы – укучыны китап белән кызыксындыру, китап укуга җәлеп итү.

Китапны аңлап укучы кеше укылган тексттан иң әһәмиятле фикерләрне аера, аларны анализлый һәм үз фикерен расларга өйрәнә. Кызганычка каршы, мондыйлар бүген бармак белән генә санарлык. Шуннан чыгып, 9-10 нчы сыйныфлар арасында Мәдинә Маликова иҗатын өйрәнәселәре килүен ачыклап, аңа багышлап проект, китапнамәләр ясау бурычы йөкләнде.

**Проект: “Мәдинә Маликова иҗаты буенча сәяхәт”**

**Проект дәвамлылыгы**: 2 атна

**Максат:** Мәдинә Маликова иҗаты белән таныштыруның әһәмиятен үстерү.

**“Мәдинә Маликова иҗаты буенча сәяхәт” проектының мөһимлеге:** бу проект барышында укытучыларның ата-аналар белән тыгыз элемтәдә эшләве нәтиҗәсендә балаларда Маликованың иҗатына кызыксынучанлык арта.

**Көтелгән нәтиҗәләр:**

- проектта катнашучылар кино һәм реклама эшләргә өйрәнергә мөмкинлек алачак, әзер сәнгать әсәрләре аша, китаплар уку һәм аның киноверсиясен карау белән кызыксыначаклар, шуның белән укучыларның рухи һәм әхлакый шәхес буларак формалашуында кино һәм китапларның роле тагын да артачак.

**Укучылар презентация, проект, әсәрләренә буктрейлер ясап якладылар.**

**Проектның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре.**

Буктрейлерлар мәктәп, район буенча төрле юнәлештәге чаралар үткәргәндә кулланыла ала:

1. Дәрестә һәм дәрестән тыш чаралар, конкурслар үткәргәндә куллану мөмкинлеге.
2. Проектны гамәлгә ашыруда алынган продуктлар турында Интернет глобаль челтәрендә мәкаләләр чыгару мөмкинлеге.
3. Буктрейлерлар төзүгә балалар һәм педагогларны җәлеп итү, педагогларның үзбелемен күтәрү курсларын оештыру мөмкинлеге.
4. Уку елы дәвамында үткәрелә торган Интернет-конкурсларда, Интернет-проектларда катнашучылар командасы формалаштыру мөмкинлеге.
5. Бу чараларга ата-аналарны да җәлеп итү мөмкинлеге.

**Йомгак**

Бу проект балаларның уртак эшчәнлеге нәтиҗәсе буларак, үзләренең идеяләре һәм аны чишү вариантларын таба белү, алган белем һәм күнекмәләрен практикада куллана белү, иҗади сәләтләрен тормышка ашыру, командада эшли белүне формалаштыра.

## ЛИТЕРАТУРНАЯ ГОСТИНАЯ С МАДИНОЙ МАЛИКОВОЙ

Галияхметова Гульнара Илшатовна, Гиниятуллина Танзиля Язкаровна
Юшкова Ирина Николаевна, учителя Джалильской СОШ №2, Сармановский район

**Цель:**познакомить обучающихся с жизнью и творчеством татарской писательницы Мадины Маликовой.

**Задачи:** пробудить интерес к личности и творчеству Мадины Маликовой; показать гениальность и внутреннюю силу писателя; воспитывать любовь к чтению и книге.

**Материалы и оборудования:** портрет и книги Мадины Маликовой, презентация, портреты других татарских писателей, листы формата А3, цветные карандаши, краски.

**Ход мероприятия:**

**Вступительное слово учителя.**

Здравствуйте, дорогие ребята! Сегодняшний наш классный час – встреча в литературной гостиной. Посмотрите на портреты писателей. Все ли они хорошо знакомы вам? Нет ли среди них пока малоизвестных для вас? (обучающиеся называют писателей и выделяют портрет Мадины Маликовой). Мадина Габдулхаковна Маликова – кто она? **Первая женщина-романистка в татарской литературе, инициатор и основатель благотворительной общественной организации «Кызыл ай», благодаря которой немало людей получили помощь и поддержку в постперестроечные годы, заслуженный работник культуры Татарстана и России, а также** наша землячка.

**Жизнь и творчество писателя.** (Сообщения с использованием презентации, подготовленные обучающимися).

**Обучающийся 1:** Мадина Маликова – известный татарский писатель, публицист, общественный деятель; автор многочисленных романов, повестей, рассказов, пьес на

татарском языке. Родилась 5 августа 1935 года в селе Муртыш-Тамак Сармановского района Татарской АССР. Закончила Мензелинское педагогическое училище и историко-филологический факультет Казанского педагогического института с красным дипломом.

**Обучающийся 2:** Личность Мадины Маликовой как раз совпадает с ее творчеством. Всегда была на защите родного языка и литературы. Мадина Маликова проработала 23 года в журнале «Азат хатын». Мадина-апа – автор девяти романов, издала 24 книги, 4 из них были изданы в Москве на русском языке. Одна из красивых черт ее характера – гордость. Она гордая татарская женщина, татарская писательница.

Наиболее популярные романы – «Милосердие», «Вихрь», «Очарование», «Красный цветок», «Вкус ржи», повести «Весенние венки», «Потерянные сокровища», «Цветочный мед», «Взошла я на высокую гору». По ее пьесам поставлены спектакли в Татарском государственном академическом театре им. Г.Камала, Мензелинском государственном татарском драматическом театре им. С.Амутбаева и в Альметьевском государственном татарском драматическом театре.

**Обучающийся 3:**Творческий путь М.Маликовой можно разделить на два значительных периода. Первый из них - ранний период и творчество до 1990 годов, то есть до времен перестройки

В период работы в журналистике, она создает свои первые значимые произведения. Ранние рассказы М.Маликовой пронизаны идеей нравственности и неразделенной любви. На появление первой повести «Казан каласы - таш кала» («Свет улыбки Моны Лизы») повлияли личные душевные переживания автора.

Второй период творчества М.Маликовой так же, как и первый начинается с публицистики. Она пишет очерки и статьи на различные темы. Далее выходит на свет цикл рассказов под названием «Полевая дивизия» («Кыргый дивизия») и роман «Вихрь» («Өермә»).

**Учитель:** Давайте послушаем, что говорила сама М.Маликова о начале своего творческого пути.

**Обучающийся 4:**«Мой первый роман «Милосердие» был написан в 1983 году и до сих пор пользуется читательским спросом, он включен в школьную программу (для татарских школ) вместе с еще одним произведением «Цветочный мед» (для русских школ с изучением татарского языка).

**Выставка и обзор книг М.Г.Маликовой.**

**Учитель:** Ребята, сейчас я хочу предоставить слово нашей гостье – библиотекарю нашей школы Бургановой Алсу Сагдеевне. Она проведет обзор книг М.Г.Маликовой, которые представлены на нашей выставке.

**Творческая мастерская.**

Обучающиеся занимаются процессом создания книги. Ребята делятся на три группы (1 – художники-иллюстраторы, 2 – редакторы, 3 - издатели ). Задания по группам:

1 группа – создать иллюстрации с образами главных героев в произведениях М.Маликовой.

2 группа – оформить обложки будущей книги

3 группа – придумать рекламу для продвижения книги.

На выполнение работы дается 10 минут. По окончанию работы учащиеся защищают свои проекты.

**Подведение итогов.**

Вот и закончилась наша встреча в литературной гостиной.Надеемся, она была интересной и познавательной, и у вас возникло желание прочитать книги М.Маликовой.

Как сказал Рене Декарт «Чтение хороших книг – это разговор с самыми лучшими людьми прошедших времен, и притом такой разговор, когда они сообщают нам только лучшие свои мысли».

## НАШИ ПИСАТЕЛИ-ЗЕМЛЯКИ НА КАРТЕ САРМАНОВСКОГО РАЙОНА

(проект)

Гатин Рафис Исмагилович, Нуртдинова Гульнар Салихзяновна,
Салихова Айгуль Робертовна, учителяДжалильской СОШ №2,
Сармановский район

**Аннотация проекта.**Проект посвящен исследованию жизни и творчества писателей-земляков. Проект дает возможность не только получить углубленные знания о жизни и творчестве писателей, но и развивать свои творческие способности.

**Актуальность темы.** Наш край не обделён литературными талантами. Рядом с нами живут и творят удивительные люди – композиторы, поэты, исполнители. Именно с любви к родному краю, к своей земле начинается творчество.

**Цель проекта:**расширить и углубить знания о жизни и творчестве писателей родного края;создать электронную версию карты Сармановского района с именами писателями

**Задачи:**познакомиться с биографиями писателей; создать презентацию.

**Формулировка проблемы.**Сегодняшним молодым читателям мало что говорит имена писателей Сармановского района. Кто-то может заметить, что иное время — иные песни. Но, как писал сам Виль Владимирович: «Хорошее дело Вы придумали: повспоминать прошлое! Без этого прошлого — плохо формируется настоящее, без взгляда назад, на самом деле, трудно жить».

**Проверка, реализация гипотезы.**Каждый край имеет свои литературные традиции. Занятия литературным краеведением позволяют учащимся осознать связь литературы с жизнью, увидеть ту среду, те факты явления, которые послужили материалом для творчества.

### Основная часть

**Глава 1. 1-ый этап работы - создание информационного проекта.** Сбор материалов для создания карты

**Глава 2. 2-ой этап работы – исследовательский. <u>Анкетирование</u>**

Из 40-ка опрошенных учащихся, мы получили такие сведения:

1.Знакомы ли вы с творчеством поэтов-земляков (19 -да, 21- нет)

2.Знали ли вы, что в Сармановском районе живут писатели ? (22-да, 18- впервые слышу)


**<u>Вывод.</u>** Приоритеты сменились, и сегодняшние учащиеся могут даже не знать имена поэтов-земляков.

**<u>Глава 3. 3-ий этап работы- творческий.</u>** В ходе работы мы

1) Изучили литературу по данному вопросу
2) Создали электронную версию в операционной среде MSPowerPoint, которая позволила представить изученный материал в более удобной и систематизированной форме.

**Заключение**

Наш проект поможет пропагандировать творчество писателей и поэтов Сармановского района и повысит интерес к писательской и краеведческой деятельности.




## М.МАЛИКОВА ИҖАТЫНА БАГЫШЛАНГАН БЕНЕФИС ДӘРЕС

(Осталык дәресе)

Гыйльфанова Фәнүсә Мәгъсүмҗан кызы,
А.Тимергалин исемендәге Иске Минзәләбаш төп гомуми белем бирү мәктәбе,
Сарман районы

**Максат:** билгеле бер язучы иҗаты белән бәйле рәвештә китап укуга кызыксындырып җибәрү; М.Маликова иҗаты, тормыш юлы белән тирәнтенрәк танышу, иҗади фикерләп, сорауларны аңлап, аларга киңәйтелгән җаваплар бирергә, төркемнәрдә эшләргә өйрәтү; якын-тирәдәгеләргә карата игътибарлылык, тәрбиялелек сыйфатлары булдыруга ирешү.

**Җиhазлау:** М.Маликова китапларыннан күргәзмә, Р.Фәхреддиннең тәрбия темасына язылган китаплары, презентацион материал, төркемнәрдә эшләү өчен таратма материал, мультимедиа проекторы

**Дәрес барышы**

1. Оештыру моменты.

- Исәнмесез хөрмәтле хезмәттәшләр. Мин А.Тимергалин исемендәге Иске Минзәләбаш төп гомуми белем бирү мәктәбенең башлангыч класслар укытучысы Гильфанова Фәнүсә Мәгъсүмҗан кызы.

- Мин сезне үзем белән таныштырдым, ә хәзер минем сезнең белән танышасы килә. Игътибар экранга! Иң беренче башка нинди җавап килә, шуны әйтәбез. "Кыз нәрсә турында уйлый?"

- Барыгызга да рәхмәт. Башка җаваплар булмаса, алдагы картинага күз салыйк. Малай нәрсә турында уйлый?

- Җавапларыгыз өчен рәхмәт. Ә хәзер урындыкларыгызга игътибар итегез. Кызыл һәм зәңгәр битләрдә саннар язылган урындыкларга утыручыларны бирегә чыгуларын сорыйм. Һәм сезне тантаналы рәвештә минем мастер-классымның катнашучылары итеп игълан итәм. Рәхим итегез.

- Тышта кар бөртекләре арасыннан көлеп караган кышкы кояш кебек бер-беребезгә якты итеп елмаябыз да урыннарыбызга утырышабыз. Дуслар, безнең бүген кабинетка да бәйрәм төсе кергән. Ник икәнен башваткычны чишеп белербез. (Экрандагы башваткыч тәкъдим ителә. Аны чишкәч, "БЕНЕФИС" сүзе килеп чыга.

- Бүген бездә - бенефис. Нәрсә соң ул бенефис? Аңлатмалы сүзлек белән эшләп алабыз. (Бенефис сүзенең аңлатмасы белән танышу). Рәхмәт.

2. Төркемнәрдә эшләү.

- Минем сезгә бирем тәкъдим итәсем килә. (Мэнэдж мэд). Сезнең өстәлләрдә ак битләр бар. Минем арттан эшләп барабыз. Беренче санлы кунаклар битне икегә бөклиләр һәм икенче сан астында утыручыга бирәләр. Алар үз чиратында тагын икегә бүләләр һәм ерталар. Һәркемдә менә шундый битләр барлыкка килде. Хәзер шушы битләргә үзегезнең төркемдә утыручыны тасвирлаган сыйфатлама языгыз әле. Тик кем икәнен күрсәтмәгез. Килештекме? Язабыз, шулай ук минем әйткән сүзләргә колак салабыз.

- Сыйфатлама язганда тәрбияле укучылар турында әйтелгән шушы фикерләрне истән чыгармаска кирәк иде. Тиз генә шуларны кабатлап алабыз. Р.Фәхреддиннең "Балаларга үгет-нәсыйхәт" китабы белән таныштырып алу.

- Тәрбиялелек турында язган Р.Фәхреддиннең китаплары сезгә һәрвакыт ярдәмгә килә ала. Аларда тәрбияле бала, тәрбияле ана, тәрбияле ата, хәтта тәрбияле укытучы нинди булырга тиеш дигән сорауга да җавап табып була. Ә тәрбияле кешеләр күбрәк булган саен, безнең тормышыбыз матуррак була ала. Сезнең язмалар да безнең дәресне матурласын иде.

"Мине таны" уенын кемнән башлыйбыз? (3-4 сыйфатлама укыла). Кем бу таныдыгызмы?

3. Төп өлеш.

- Ә хәзер минне тыңлагыз. Аның исемен ишеткәч, кайберәүләр, Аяз Гыйләҗевкә ияреп, зыялы язучы, - дияр. Кайберләре исә батыр, дип тә өстәр. Ипле генә итеп Россиянең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Хөсәен Ямашев, Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе икәнен дә искәртеп куярлар. Ә менә хатын-кызлар арасында гына түгел, ир-ат каләм ияләренең дә борынына чиертеп иң күп роман иҗат иткәнен, детектив жанрда оста язганын, китап кадере хакында иң күп уйланып, шул хакта матбугатта публицистик язмалар белән чыкканын һәм үз мисалында, китапларын таратып, татар китабының укучысы барлыгын, татар әдәбиятын сатуның табышлы икәнен раслаганын әйтүче табылырмы икән? Сүзебез Мәдинә Маликова хакында. Иҗат эшчәнлеген журналистикада башлап, тугыз роман, күп кенә хикәя, повестьлар иҗат итә ул.

Мәдинә Габделхак кызы Маликова 1935 елның 5 августында Татарстан АССРның Сарман районы Мортыш Тамагы авылында колхозчы гаиләсендә туган. Үз авылларындагы җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, 1949—1959 елларда башта Минзәлә педагогия училищесында, аннары Казан дәүләт педагогия институтында укый. Әйдәгез аның турындагы фильмнан өзек карап алыйк. (Өзек күрсәтелә)

Хәзер без бенефис-дәресебезне дәвам итәбез.

Сезнең өстәлләрегездә язмалы пазллар бар. Алардан тулы бер дөрес язма төзергә кирәк. Һәрберегезне, урыннарыгыздан торып, үз төркемен табарга, берләшергә чакырам.

Төркемнәрне барлау.

- Беренче төркем "М. Маликова – детектив повестьлар авторы" дигән язманы ача алды. Сез беренче санлы өстәл артына үтегез.

- Икенче төркем "М.Маликова – лирик хикәяләр авторы" дигән язманы ачкан. Сезне икенче өстәл артына озатабыз.

- Төркемнәрне барладык. Инде хәзер биремнәргә тотынып вакыт җитте. Һәр өстәлдә конвертлар ята. Аларда биремнәр. Шунда ук сез биремнәрне ничек үтәргә икәнен күрсәткән белешмә материал да бар. Соңыннан төркемнән бер кешегә үзләренең эш нәтиҗәләре белән таныштырырга туры киләчәк.

4. Төркемнәрнең мөстәкыйль эшләве.

1 нче төркем: М.Маликованың лирик әсәрләре исемлеген төзергә. (Әсәр исеме тасмаларга язылган һәм бүленгән. Исемнәрне кушарга һәм аерым биткә ябыштырырга кирәк).

2 нче төркем: М.Маликованың детектив ханрындагы әсәрләре исемлеген төзергә. (Әсәр исеме тасмаларга язылган һәм бүленгән. Исемнәрне кушарга һәм аерым биткә ябыштырырга кирәк).

- Төркемнәр эшләгән арада без М.Маликованың иҗат һәм тормыш юлын чагылдырган презентацияне карауны дәвам итик.

- Төркемнәр эшне төгәлләгән, әйдәгез сүзне аларга бирик.

5. Кунак каршылау.

- Дуслар, бенефис кунакларсыз булмый. Язучы бенефисын китаплар патшалыгы хуҗасыннан башка күз алдына китереп булмый. Кем булыр ул? (Китапханәче). Безнең авыл китапханәсендә бик күп еллар инде Гарифуллина Айзирәк Әнәс кызы эшли. Авылыбызның китапханәсе бик күпләргә үрнәк булырлык. Ул сезгә менә шундый күчтәнәч-бирем әзерләгән.

1. М.Маликованың китапларыннан төзелгән күргәзмә белән танышу.

2. Сорауларга җавап бирү.

- Беренче хикәяләр җыентыгының елы, исеме? (1967 нче ел, «Юлдашлар»)

-Беренче басылып чыккан романы? («Ак давылда тал бөресе» («Шәфкать»)

- Хәзерге заман яшьләре турындагы әсәре? ( «Тылсым») һ.б.

6. Дәрескә йомгак.

- Дуслар, бенефис үткәрү җиңел эш түгел. Ә аны үткәрүгә лаек булу тагын да авыррак. Моның өчен нинди булырга кирәк? (Уңай сыйфатларны санау).

- Менә шул сыйфатларга ия булырга тырышыгыз, осталыкка омтылыгыз. Сезнең турыда бары матур сүзләр генә сөйләсеннәр иде.

Чыгу билеты. Дәреснең истәлеге итеп язманы кабул итегез һәм бары тик тырышлык кына уңыш китерүен онытмагыз.(Язмалар өләшенә)

Игътибарыгыз өчен рәхмәт

## М. МАЛИКОВАНЫҢ «ТЫЛСЫМ» РОМАНЫНДА ГАИЛӘ БӘХЕТЕНЕҢ БИРЕЛЕШЕ

Даутова Роза Мөгайяр кызы,
Кәүҗияк төп гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**Максат:**М. Маликованың «Тылсым» романы нигезенә салынган вакыйгаларны, кешеләр арасындагы һәм кеше белән җәмгыять арасындагы мөнәсәбәтләрне тикшереп, әсәрнең тематикасын, проблематикасын, автор фикерен ачыклау; укучыларны үз фикерләрен төгәл, дәлилле итеп исбат итәргә өйрәтү; мәхәббәт, гаилә бәхете һәм ныклыгы нинди булуын ачыклау.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр**:

Ме т а п р е д м е т: өйрәнгән теманы аңлап, күзәтү ясый белү

Регулятив универсаль уку гамәлләре:укытучының күрсәтмәләрен аңлап үти белү; анализлый белү; уку эшчәнлеген оештыра белү; уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү.

Танып-белүуниверсаль укугамәлләре:уку максатын мөстәкыйль билгеләү; тиешле мәгълүматны табу, билгеләү; сөйләм берәмлекләрен логик эзлеклелеккә салу; объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү, чагыштырып нәтиҗә ясый белү күнекмәләрен формалаштыру.

Коммуникатив универсаль уку гамәлләре: фикерне төгәл итеп җиткерү; әңгәмәдәшең белән аралашу калыбын төзү; мәгълүматны туплау өчен күмәк эш башкару.

П р е д м е т- ш ә х е с к ә кагылышлы: балаларда белемгә омтылыш тәрбияләү.

**Җиһазлау.** М.Маликова иҗатына карата әдәби бюллетень, әсәрләреннән китап күргәзмәсе М. Маликованың портреты; М. Маликованың «Тылсым» китабы / М. Маликова.- Казан: Тат. кит. нәшр., 2008.; әсәр буенча ясалган презентация; Сарман районы картасы, “Аңлатмалы сүзлек” китабы, тактада **эпиграф** язылган:

Нурга төренгән фәрештә -
Аһ, сөю, әллә синме?
Бер кулында – баллы касә,
Берсендә - утлы сөңге...

**Дәрес барышы**

**I.Оештыру.** Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Уку мәсәләсе кую.** Укучылар түбәндәге рәсемгә карагыз эле. Нәрсә күрәсез? Алар арасында нинди бәйләнеш булырга мөмкин? (*рәсемдә гаилә сурәте бирелгән һәм М.Маликованың «Тылсым» китабы-слайд1)*

**Укытучы сүзе.** Әдәбият дәфтәрләренә числоны һәм дәреснең темасын яздыру.Без бүген Мәдинә Маликованың «Тылсым»әсәрендәге шундый гыйбрәтле язмышлар белән танышырбыз. Гаилә бәхетенең нәрсәдә булуын ачыкларбыз. Гаилә ныклыгын ничек саклап калырга мөмкин икәнлеге турында сөйләшербез. Һәр сүзгә аңлатмалы сүзлектән аңлатманы уку һәм дәфтәрләргә язып кую. Кем соң ул М. Маликова?

2. **М. Маликованың тормышы һәм иҗаты турында.** (*Бер укучы сөйли)*

«Тылсым» **романы турында** (*Бер укучы сөйли*) Язучының «Тылсым» (2006) романы интеллигенция тормышына багышлана. Бу романда язучы кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең катлаулы нечкәлекләрен, нокталарын ачарга омтыла. М. Маликова әлеге әсәрендә яшәешнең төп мәгънәсе һәм максаты турында укучысы белән җитди әңгәмә алып бара...

**Укытучы сүзе**: Мәхмүт Әхмәтҗанов: “Әхлак тәрбияләүдә М. Маликова әсәрләренең роле әйтеп бетергесез зур. Моның сәбәбе шунда: әдәби әсәр берьюлы аңга да, хисләргә дә тәэсир итә. Бу исә тәрбиянең – инанулар формалаштыруның иң нәтиҗәле ысулы”,- дип яза. “Тылсым” романы да нәкъ шундый әсәрләрнең берсе.

4. **Әсәрнең сюжетын сөйләү, искә төшерү.** Укучылар, әсәрне уку сездә нинди тәэсир калдырды? (*Берничә укучының фикере тыңланыла).*

**III Уку мәсьәләсен чишү.** Әсәр хакында фикер алышу, укучылар фикерен тыңлау.

1. Әсәрнең эпиграфы итеп М.Маликова шигъри юллар алган. Бүгенге дәреснең дә эпиграфы булып шигырь юллары тора.

2. Әсәрдәге төп образларны ачыклау. Лениза һәм Әнисәнең портретларын әсәрдән табу һәм чагыштыру (*презентациядә портретлар язылган* – слайд 5).

3. Әнисә һәм Ленизаның эшләренә нинди бәя бирер идегез?

4. Әнисәнең төп сыйфаты нинди?

5. Ленизаның төп сыйфаты нинди?

6. Әнисә Лениза турында: “ Кара эчле, мәңге үтмәс хәсрәт китерәчәк, тере бәхетсез итәчәк,”-ди. Бу фараз дөрескә чыгамы? Ничек?

7. Татар халкында туй йолалары бик күркәм. Ә Мидхәт белән Лениза өйләнешкәндә бу йолалар үтәләме?

7. Туйда яшьләргә Алия Фәргатовна теләкләр әйтә (*презентациядә теләкләр язылган слайд 6*): Аның бу теләкләре кабул буламы, үтәләме? Үтәлмәсә, ни өчен үтәлми?

8. Әсәрдә бала һәмана образы бирелә (*презентациядә бала һәм ана рәсеме слайд 7*) Алия Фәргатовна уе аркылы автор безгә сорау бирә: "Әйтик, туачак җан... Кайчандыр без дә аның кебек булганбыз... кемдер безнең язмышны хәл итү хакында уйлаган... Яшәргә мөмкинлек бирергәме юкмы? Укучылар, аның соравына җавап бирик әле. Кемдә нинди фикерләр бар?

9. Мидхәтнең балачагы ничек үтә, ул гаиләсе өчен ниди бала була? Ә Лениза, Рәмилә?

10. Нигә Рәмиләгә шундый исем кушыла, аны кем куша? (*Рамилә исеменең мәгънәсен ачыклау - тылсым иясе, тылсымчы)*

11. Мидхәт белән Ленизаның гаилә тормышы ничек үтә? Алар бәхетлеме? Ни өчен?

12. Гаилә нигә таркала? Кем гаепле?

13. Гаилә башлыгы буларак Мидхәт турында нәрсәләр уйлыйсыз? (*Презентациядә Мидхәтнең портреты язылган)*

14. Ленизага нишләргә? Әллә соң ялгызың гына шушы рухани янына кереп киңәш сорарга микән? Ни дип сүз башларсың? Ирем мине яратмый, аның мәхәббәтен ничек кайтарыйм? дияргәме?

15. "Син белмисеңмени, иманлы кешеләргә яшәү җиңелрәк бит", - ди Рәйсә Ленизага. Кемнәр алар иманлы кешеләр?

16. Ә автор мондый сорау куя: мәхәббәт һәм иман...

Боларның бер-берсенә катнашы, мөнәсәбәте бармы? Иманлы кеше гашыйк булса, үз-үзен ничек тота да, имансызы нинди гамәлләр кыла? Аның кылганнары мәгъшугы белән ике арада гына каламы, әллә бүтәннәргәдә таш булып килеп бәреләме? Укучыларның фикерләре тыңланыла. (*Презентациядә бу хакта Рәйсәнең әйткән сүзләре китерелә)*

17. Әсәрдә мәчет, чиркәү, "Нур һәм Сафлык" оешмасы бирелгән. Сез алар турында ни уйлыйсыз?

18. Әсәрдәге иң зур фаҗига дип сез нинди вакыйганы атар идегез? Ул фаҗига ни өчен килеп чыга? Аны булдырмый калу мөмкин идеме? Тормышта да мондый хәлгә калган кешеләрне очратырга мөмкинме?

19. Әсәр түбәндәге сүзләр белән тәмамлана: (экранда күренә) Яратмыйча, инанмыйча яшәү яшәүмени ул?! Бу фикер белән килешәсезме, укучылар?

20. Әсәр ни өчен «Тылсым» дип атала? "Тылсым" сүзен сез әсәрдә кайсы урыннарда очраттыгыз?

21. Бу әсәрен иҗат итеп М.Маликова кирәкле эш башкарганмы? Аны укып укучылар үзләре өчен файдалы киңәш яки рухи азык алырлармы?

**III Рефлекция.** Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Нәрсәләр белдегез? Әсәр сезгә ошадымы? Ошаса, ни өчен ошады, ошамаса, ни өчен ошамады? (*Укучыларның фикере тыңланыла*).

3. Укучылар,язучы яшәү мәгънәсен нәрсәдә күрә? Сез аның белән килешәсезме?

**IV. Өй эше.** Укучылар бүген дәрестә күп эш башкардык. Сезгә үзегез өчен кызыксынып укырга «Чәчкә балы» әсәрен тәкъдим итәм**.** Анда бүгенге көн өчен актуаль булган проблемалар күтәрелгән.

**V. Укытучының йомгаклау сүзе.**

# ИЛҺАМЛАНЫП ИҖАТ ИТҮЧЕ ЯЗУЧЫ

Җиһангиров Айдар Фаиз улы, А. Тимергалин исемендәге
Иске Минзәләбаш төп гомуми белем бирү мәктәбе,
Якупова Гүзәлия Фаиз кызы, икенче санлы Җәлил урта мәктәбе,
Сарман районы

**Максат:** укучыларны Мәдинә Маликова тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштыру, якташ язучыбыз иҗатына кызыксыну уяту

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, презентация, Мәдинә Маликовага багышланган китап күргәзмәсе, газета-журнал мәкаләләре.

**Укытучы.** Бүгенге кичәбез Россиянең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, татар телендә романнар иҗат иткән беренче хатын-кыз язучы, Татарстан язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге премиясе лауреаты, Татарстан журналистларының Х.Ямашев исемендәге премиясе лауреаты, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Мәдинә Маликовага багышлана. Мәдинә апа Маликова чыгышы белән сандугачлы Сарман якларыннан. Якташ язучыбызның тормыш юлы һәм иҗаты белән якыннан танышу өчен телдән журналыбызның беренче битен ачабыз.

1**нче бит. Мәдинә Маликова – күпкырлы талант иясе. (Биографиясе белән таныштыру)**

**2 нче бит. Журналистикадан башлап...**

**3 нче укучы.** «Чаян»нан соң «Азат хатын»га килеп эләгүем һәм анда эшләгән 23 ел гомерем үзе бер алтын чор булды. «Азат хатын»дагы журналистлык тәҗрибәм булмаса, мин бүген Мәдинә Маликова дигән язучы була алмас идем. Әнә шул журналистлык эшендә җыйган тормыш тәҗрибәм миңа әдәби әсәрләр язганда бик булышты”, – дип җавап бирә ул укучылар белән очрашу вакытында.

**4 нче укучы.** Узган гасырның 70-80 нче елларында 400 меңнән артык тираж белән басылган «Азат хатын» журналында Мәдинә Маликованың очерклары, сәнгатькә, әхлак темаларына багышланган язмалары киң яңгыраш таба, журналда басылган беренче хикәяләре, повестьлары укучылар тарафыннан яратып кабул ителә.

**5 нче укучы.** Язучының «Казан каласы – таш кала» (1967), «Кояш күпере» (1973), «Янар таулар яктысында» (1977) повестьлары, «Шәфкать» (1985), «Басып сайрар талы бар» (1987), «Фидая» (1990) романнары шәһәр һәм авыл зыялылары – инженерлар, архитекторлар, рәссамнар, табиблар, артистлар тормышына багышлап язылганнар.

**4нче бит. Зыялылыкка беренче адымнар**

**6 нчы укучы.** Халык язучысы Аяз Гыйләҗев үзенең бер чыгышында Мәдинә Маликованы “зыялы язучы” дип атаган. Чыннан да, зыялылык язучы иҗатының бөтен рухында чагыла. Ул, заман тормышының төрле өлкәләренә мөрәҗәгать итеп, геройларның рухи дөньясын бөтен тирәнлеге белән яктыртырга, кешеләр арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрнең нечкәлекләрен ачарга омтыла, яшәешнең мәгънәсен яхшылыкка, матурлыкка хезмәт итүдә күрә.

**7 нче укучы**. Мәдинә апа беренче әсәрен 6 нчы сыйныфта укыганда язып, укытучысына күрсәтә. Бу әсәр сугыш вакытында бер пионерның отряд флагын фашистлардан яшереп алып калуы турында була. Ләкин укытучысы әсәрне бәясез калдыра. Мәдинә апаның беренче каләм тибрәтүе шушы булгандыр. Мәктәптә ул алдынгы укучы булу сәбәпле, төрле бәйгеләрдә, олимпиадаларда актив катнаша. Сәхнәдән үзе чыгарган шигырьләрне дә укый торган була. 5-6 нчы сыйныфларда ул үзе язган шигырьләр белән бер дәфтәр тутыра. Мәдинә апага бу сәләт аның әнисеннән күчкәндер, чөнки Һәдия әби такмак чыгарырга бик оста була.

**4 нче бит. Мәдинә Маликова – хәзерге заман сулышы белән яшәүче һәм илһамланып иҗат итүче язучы.**

**8 нче укучы.** М. Маликова — иҗат эшчәнлегенең буеннан-буена каләмен детектив әсәрләр жанрында да чарлаган әдибә. Аның «Хөкем» (1969), «Августның беренче кичендә» (1970), «Адашканга юл кайда?» (1971), «Югалган якутлар» (2003), «Чәчкә балы» (2004) исемле маҗаралы повестьлары, «Өермә» (2002) исемле детектив романы, «Кыргый дивизия» (2001) кебек хикәяләре, жанр хасиятләре таләп иткәнчә, мавыктыргыч, киеренке агышлы вакыйга-сюжетка корылганнар. Гомумән, М. Маликова сюжетны оста, мавыктыргыч итеп кора белә, вакыйгаларны йөрәк аша үткәреп, укучының күңел кылларын тибрәндерерлек итеп тасвирлый.

**9 нчы укучы.** М. Маликова драматургия өлкәсендә дә уңышлы гына эшли. Аның «Оҗмах балалары» исемле драмасы Г.Камал исемендәге академия театры сәхнәсендә куела (1990), «Йөрәк ничек түзсен», «Моңнар төште башыма», «Синең өчен үзем үләрмен» исемле драма әсәрләре узган гасырның туксанынчы елларында Минзәлә һәм Әлмәт театры сәхнәләрендә зур уңыш белән бара. “Сөембикә” трагедиясе 2004 нче елда уздырылган “Яңа татар пьесасы конкурсы”нда бүләккә лаек була.

**10 нчы укучы. «**Оҗмах балалары» трагикомедиясе күпләрнең күңелен яулап ала. Әсәрдә күтәрелгән проблемалар бөтенебезне дә борчый. Бүген без киләчәгебезне төзибез, тик без дөрес юлдан барабызмы? Балаларыбызга тиешле игътибар бирәбезме? Аларны укытучылар кулларына, мәктәпкә, җәмгыятькә тапшырып бетермәдекме? Безнең балаларыбыз бәхетлеме? Алар ялгыз түгелме? Бүген дә нәкъ шушы сорауларга без җавап эзлибез түгелме?

**11 нче укучы.** Әйе, пьесада хыял да бар. Ләкин төп проблемалар бүгенге көндә ата-ана һәм бала мөнәсәбәте, гаилә һәм тәрбия нигезләре турындагы социаль эчтәлек алган мәсьәләләр.

**Укытучы**. Мәдинә Маликова – хәзерге заман сулышы белән яшәүче һәм илһамланып иҗат итүче язучы. Ул халык арасында күп йөри, шуңа күрә аларның һәр борчыган проблемалары белән дә таныш. Язучының иҗаты башкалардан халык арасында тәвәккәллеге, кыюлыгы, күп сүзгә урын калдырмыйча өздереп әйтә белүе белән дә аерылып тора.

**Кулланылган әдәбият:**


1.Әхмәдуллин А. “Оҗмах балалары” ның бәхетсез тормышы// Мәйдан, 2004, №7

2.Әхмәтҗанов М. Басып сайрар талы бар// Сөембикә, 1995, №8

3.М.Маликова М. Югалган якутлар: Повестьлар, пьесалар. – Казан: «Рухият» нәшрияты, 2004


## “СҮЗ ТӨРКЕМНӘРЕН ГОМУМИЛӘШТЕРЕП КАБАТЛАУ” ТЕМАСЫ БУЕНЧА КОНТРОЛЬ ЭШ


Җиһангирова Гөлшат Таһир кызы,

А.Тимергалин исемендәге Иске Минзәләбаш төп гомуми белем бирү мәктәбе,

Сарман районы


**Аңлатма язуы**

Контроль эш татар мәктәбендә укучы 6 нчы сыйныф укучыларының “Сүз төркемнәрен гомумиләштереп кабатлау” темасы буенча алган белемнәрен тикшерү максатыннан төзелде. Контроль эш 3 өлештән тора. Беренче өлештә (1-5 нче биремнәр) – тестлар, икенче өлештә (6-10 нчы биремнәр) – үтелгән темалар буенча төрле биремнәр, 11нче биремдә иҗади эш тәкъдим ителә. Белемнәрне тикшерү эшенең күләме программа таләпләреннән чыгып билгеләнде. Ул 45 минутка исәпләнгән.

**I вариант**

**1нче өлеш**

1.Калын хәрефләр белән бирелгән исемнең килешен билгеләгез.

Бу җирдә үләннәр, агачлар да, игеннәр дә гөлләр дә **орлыктан** шытып үсә.

а) төшем килеше ә) чыгыш килеше б) урын-вакыт килеше

2.Артыклык дәрәҗәсендәге сыйфатлардан гына торган сүзләр рәтен табыгыз.

а) гүзәл, яшел, борынгырак

ә) кып-кызыл, әчкелтем, сарырак

б) иң акыллы, зәп-зәңгәр, җете кызыл

3. Рәвешләр кайсы җөмлә кисәкләре була ала?

а) ия

ә) тәмамлык

б) хәл, аергыч, хәбәр

4.Кайсы сан төркемчәсенең саналмышы булмый?

а) тәртип санының

ә) бүлем санының

б) җыю санының

5. Калын хәрефләр белән бирелгән фигыльнең төркемчәсен күрсәтегез.

Балалар бәрәңге **җыярга** бардылар.

а) шарт фигыль

ә) инфинитив

б) хәл фигыль

**2 нче өлеш**

1) Мин кар суына барам. 2) Күгелҗем сукмак буйлап тау арасына менәм. 3) Сукмак тар, аякларны туп-туры басарга кирәк, юкса батасың. 4) Сукмак кырыенда карның өсте челтәрләнгән. 5) Ул кыш көнендәге шикелле күзләрне чагылдырмый, асылташлар сипкәндәй җемелдәми. 6) Кар да картая икән. 7) Дөрес, биредә ул шәһәрдәге кебек каралмаган, пычранмаган, тик тоныкланган, басылган, авырайган. 8) Уйсу җирдә ул әле нык ята, ләкин яз кояшы аны тау түбәсеннән куган инде, ул, күкселләнеп торган текә тау битенә өр-яңа җыерчыклар салып, агып төшкән. (Мәдинә Маликовадан)

6. Кайсы җөмләдә кимлек дәрәҗәсендәге сыйфат кулланыла?

7. Кайсы җөмләләрдә зат алмашлыклары кулланыла? Җөмләләрнең санын арта бару тәртибендә күрсәтегез.

8. Юклык формасындагы фигыльләрне язып алыгыз.

9. 6-8 нче җөмләләрдән III зат берлек санда, чыгыш килешендә килгән тартымлы исемне язып алыгыз.

10. 6-7 нче җөмләләрдән рәвешне язып алыгыз.

11. Текстны дәвам итеп, 4-5 җөмлә языгыз.

**II вариант**

**1нче өлеш**

1.Калын хәрефләр белән бирелгән исемнең килешен билгеләгез.

Тирә-юнендә ул булдырган **орлыклардан** үскән арыш.

а) төшем килеше

ә) чыгыш килеше

б) урын-вакыт килеше

2.Кимлек дәрәҗәсендәге сыйфатлардан гына торган сүзләр рәтен табыгыз.

а) гүзәл, яшел, борынгырак

ә) кызгылт, әчкелтем, күгелҗем

б) иң акыллы, зәп-зәңгәр, кызыл

3.Зат алмашлыклары кайсы җөмлә кисәкләре була?

а) баш кисәкләр

ә) иярчен кисәкләр

б) төрле җөмлә кисәкләре

4. Җыю саннарын билгеләгез.

а) беренче, икенче, өченче

ә) җиделәп, унлап, унбишләп

б) бишәү, алтау, җидәү

5. Калын хәрефләр белән бирелгән фигыльнең төркемчәсен күрсәтегез.

Алар авыл балалары белән **ярыша-ярыша** эшләделәр.

а) шарт фигыль ә) сыйфат фигыль б) хәл фигыль

**2 нче өлеш**

1) Минем кулымда ак чиләк, аның эчендә яшел чүмеч. 2) Без бәләкәй чакларда сыңар чиләк белән суга йөрү юк иде. 3) Хәзер инде мин иңемә көянтә асудан күптән биздем, чөнки каладагы квартирабызда су краннан агып тора. 4) Авылда да өебез турына ук колонка китереп куйганнар. 5) Аннан чишмә суы ага. 6) Ул су җиргә күмелгән торбалар буйлап, тау өстендәге басулар аркылы, ерактан агып килә. 7) Ә без чишмәгә шактый озак бара торган идек. 8) Ул су бик кадерле була, аны самавырга гына тоталар иде. (Мәдинә Маликовадан)

6. Кайсы җөмләдә сыйфатлар кулланыла? Аларның дәрәҗәсен күрсәтегез.

7. Кайсы җөмләләрдә зат алмашлыклары кулланыла? Җөмләләрнең санын арта бару тәртибендә күрсәтегез.

8. 6 нчы җөмләдән сыйфат фигыльне язып алыгыз.

9. 1-3 нче җөмләләрдән I зат күплек санда, урын-вакыт килешендә килгән тартымлы исемне язып алыгыз.

10. Кайсы җөмләләрдә рәвешләр кулланыла? Җөмләләрнең санын арта бару тәртибендә күрсәтегез.

11. Текстны дәвам итеп, 4-5 җөмлә языгыз.

## ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА ӘНИ ОБРАЗЫ

(Иҗади проект)

Загирова Гөлчәчәк Гаяз кызы, Хабирова Гөлшат Салимҗан кызы
«Дуслык» 59 нчы балалар бакчасы, Яр Чаллы шәһәре

**“Татар әдәбиятендә әни образы” проектының актуальлеге:** Иң беренче тәрбияне бала гаиләдә ала. “Ана сөте белән кермәсә, тана сөте белән кермәс”, “Оясында ни күрсә, очканда шул булыр”, дигән безнең бабаларыбыз. Баланың чын шәхес булып тәрбияләнүе дә иң беренче чиратта әнигә һәм гаиләгә бәйләнгән.

**Максат:**Балаларны иҗади эзләнүгә тарту, ата-аналарда Мәдинә Маликованың әдәби әсәрләренә карата кызыксыну уяту, әдәбиятта һәм сәнгатьтә сурәтләнгән Ана образлары аша аналарга хөрмәт һәм мәхәббәт тәрбияләү.

**Җиһазлау:** слайдлар, Мәдинә Маликованың әсәрләре, әниләр темасына багышланган халык авыз иҗаты әсәрләре, шигырьләр, хикәяләр, рәсемнәр, видеоязмалар, аудиоязмалар.

**Проектның этаплары:**

**I.Әзерлек этабы:** Балаларның яшь үзенчәлекләренә туры китереп теманы уйлау, максат кую, перспектив план әзерләү. Әти-әниләр белән анкета үткәрү. М.Маликованың әниләр темасына кагылышлы әдәби әсәрләре белән танышу. Балаларга һәм әниләргә эш әзерләү. Төркем җыелышларында проектның максаты, бурычлары белән таныштыру, интернет челтәреннән, китаплардан кирәкле материаллар эзләү, туплау.

**II. Төп этап:** 1. Балалар белән эш: материаллар туплау; әңгәмәләр үткәрү; шигырь-җырлар өйрәнү, мәкальләр өйрәнү, рәсем конкурсы уздыру, әвәләү, кисеп ябыштыру; уеннар уйнау; әниләр темасына кагылышлы экиятләр уку; презентацияләр карау.

2. Әти-әниләр белән эш: анкета үткәрү; балалар белән әниләр турында шигырьләр, җырлар өйрәнү; “Минем әни” рәсем конкурсында катнашу; әдәби- музыкаль кичәдә катнашу;

**III. Йомгаклау:** Әти-әниләр белән, Мәдинә Маликованың әсәрләрендә чагылган ана образлары турында, фикер алышу. Күргәзмәләргә, алган белемнәргә нәтиҗә ясау. Стенгазета ясау. Күргәзмә оештыру: “Әниемнең алтын куллары” Бәйрәм үткәрү: “Минем әнием иң, иң, иң...!”

**Проект эшчәнлегенең перспектив – тематик планы.**

| Эшчәнлек темасы | Тәрбияче белән балаларның бердәм эшчәнлеге | Балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге | Әти-әниләр белән балаларның бердәм эшчәнлеге |
|---|---|---|---|
| Әңгәмәләр | «Минем әнием” | Рәсемнәр карау, фоторәсемнәр карау | Үткәрелгән әңгәмәләр буенча өйдә балалар белән сөйләшү, бергәләп нәсел-нәсебеңне барлау. |
| “Өч кыз” мультфильмын карау | Үстерешле диалог, мультфильм карау, аның эчтәлеген сөйләү, эчтәлек буенча фикер алышу. | Рәсем ясау | Гаилә, әниләр темасына багышланган мультфильмнар карау |
| Әнием профессиясе | Әңгәмә “Әниемнең эш урыны”, “хатын-кыз профессияләре”, “Язучы хатын-кызлар: М.Маликова, Ә.Ситдикова, Г.Зәйнәшева...” | Рәсемнәр, китаплар карау | Кечкенә китапчыклар ясау |
| Әкиятләр уку | Әкиятләр уку, эчтәлеген сөйләү,аларны чагыштыру | Әкиятнең ахырын үзләренчә дәвам итү | Балалар белән бергәләп әниләр темасына багышланган әкият язып килү |
| «Әни була бер генә”әниләр турында җырлар | М.Маликованың “Ятим бала” җырын тыңлау, җырның эчтәлеге буенча фикер алышу | Смайликлар белән җырның характерын ясау | М. Маликованың башка әсәрләре белән танышу |
| Дидактик уеннар | “Ягымлы сүзләр” “Табышмак әйтәм тап!” | | |
| Әниләр темасына багышланган шигырьләр уку: | Ф. Яруллин «Әниләр бәйрәмендә», В.Хәйруллина “Минем әни бик әйбәт”, Р. Харис “Әнием”... Үстерешле диалог, шигырь өйрәнү, өзекләр ятлау, сөйләргә өйрәнү. “Әниләр көне”, 8 март бәйрәмендәбәйрәм кичәләре уздыру | Шигырьләрне өйрәнү, сөйләү, бәйрәмнәрдә катнашу, Рәсем ясау, бүләкләр әзерләү | Үстерешле диалог, шигырь өйрәнү, өзекләр ятлау, сөйләргә өйрәнү. “Әниләр көне”, 8 март бәйрәмендәбәйрәм кичәләре уздыру |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Рәсем ясау: “Минем әнием-иң матуры” | Рәсемнәр карау, карандаш белән ясап, аннары краска белән буяу | Балаларның мөстәкыйль эше | ”Минем әнием” рәсем конкурсында катнашу |
| Әдәби музыкаль кичә | Әдәби музыкаль кичә “Минем әнием иң, иң, иң..!” | Шигырьләр, җырлар өйрәнү | Бәйрәмдә катнашу |

## МӘДИНӘ МАЛИКОВАНЫҢ "АРЫШ ТӘМЕ" РОМАНЫНА КЫСКАЧА КҮЗӘТҮ

Закирова Әлфия Ринат кызы, Нуретдинова Айгөл Гамирҗан кызы,
икенче санлы Җәлил урта мәктәбенең инглиз теле укытучылары,
Сарман районы

Мәдинә Габделхак кызы Маликова — күренекле татар язучысы, драматург. Мәдинә Маликованың әсәрләре аның 20 гә якын китабына тупланган. «Арыш тәме» китабы 2012 елны 3000 тираж белән басылып чыкты, шул елны сатылып та бетте.

**«2012 нче ел китабы» конкурсында «Арыш тәме» китабы 1 урынны алды.** 2014 елны ул кабат нәшер ителде.

**2017 елны** Мәдинә Маликова «Арыш тәме» китабы өчен Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә тәкъдим ителде.

«Арыш тәме» романын язарга Мәдинә Маликованы авыл хуҗалыгы институтында эшләүче бер галимә рухландыра. Ул арышның яңа сортларын чыгару белән шөгыльләнә һәм алар илнең уналты өлкәсендә игелә икән. Арыш турында гына түгел, күңеленә якын кешеләр турында да сөйләшеп утыралар аның белән. Галимәнең сөйләгәннәренә авыр язмышлы күрше карчыгының башыннан кичкәннәрне дә өстәгән. Романны илһамланып, яратып язган.

**Әсәрдә берничә төрле әһәмиятле проблема күтәрелгән. Шуларның берсе -– хатын-кызларыбызның чит ил кешесенә кияүгә чыгып китеп барулары. Моны кайберәүләр үзенчә горурлыкка да саный.** СССР таркалып, чикләр ачылгач, чит илләргә китүчеләр күбәя. Кемнәрдер эшкә китә, кемнәрдер – кияүгә. Сагынуларга ничек түзәләрдер. Уңган, зирәк ватандашларыбызның дөнья буйлап таралуына риза түгел язучы. Үзебездә мантысыннар, тырышлыклары белән үз ватаныбызны баетсыннар иде. «Арыш тәме»ндәге Ләйсәнне ул акламый, әмма аңлый. Һәркемнең бәхетле булырга хакы бар!

**Милләттәшләребез арасында, элекке елларда, талантлары югалып калу очракларын ишетеп беләбез. «Арыш тәме»ндәге Нәзилә дә шундый язмыш иясе.** Талантларны вакытында күреп алу, аларга белем алырга мөмкинлек тудыру – искиткеч мөһим мәсьәлә.

Әсәрдә ачык буяулар белән өч буын язмышы тасвирланган. Инде менә заманнар нык үзгәрде, яшь буынга сәләтен ачарга моңарчы булмаган мөмкинлекләр туды кебек. Тик гомер юлы киртәле-сикәлтәле. Мәхәббәтне мәкер сагалый. Шактый авырлыклар кичерергә туры килә Айзирәккә.

Ахырда барыбер мәхәббәт җиңә, яхшылык өскә чыга. Әгәр дә шулай булмаса, җирдә яшәеш бетәр иде.

# КИЛЕР БУЫННАРГА МИРАС БУЛЫП, ЭЗЕҢ КАЛГАН САРМАН ЯГЫНДА...

Закирова Фəридə Марат кызы, Заһитова Зинфера Ильяс кызы,
Беренче номерлы Актүбə мəктəбенең Əлкəй филиалы укытучылары,
Азнакай районы

“Кешелек дөньясы яшəгəн вакытта, һəр кеше һəр кайчан иҗади эзлəнүлəр юлында булырга тиеш, дип язган XIX гасырның беренче яртысында яшəп иҗат иткəн мəгърифəтче, фəлсəфəче, тарихчы, дин галиме, педагог, археолог, этнограф Ш.Мəрҗани. Əйе,эзлəнүлəр өчен беркайчан да соң булмый.

**Слайд1** Исəнмесез, хөрмəтле коллегалар. Бүген без сезнең белəн тəҗрибə уртаклашуга багышланган фəнни-гамəли укуларга җыелдык. Бүген бездə кунакта: бик күп роман-повесть, хикəялəр авторы, “Бөтентатар Кызыл Ай җəмгыяте” президенты Мəдинə Маликова.

Мəдинə Маликованың тормышы һəм иҗат юлы сокландыргыч. Ул гомере буе җəмгыяви эшчəнлектə, иҗади эзлəнүлəрдə, төрле иҗтимагый хəрəкəтлəрдə актив катнаша. Ул гомуми бер сəяси тормышта үзенең иҗади юлын башлап җибəрə. Аннан үзгəртеп кору чорының иҗтимагый-сəяси һəм милли проблемалар белəн кызыксына, ə соңгы елларда аның күп кенə романнары барлыкка килə. 1990 нчы елларда ул, Кызыл Ай җəмгыятен оештырып, дистəдəн артык ел буена аның президенты булып эшлəп килə.

Чыгышымда минМ. Маликова телəгəн төп фикерне һəм төшенчəлəрне ачыкларга, язучы иҗатына багышланган конференциядə чыгыш ясарга телəдем, язучы əсəрлəреннəн буклет төзү максаты куйдым.

**Слайд2** Əлеге максатка ирешү өчен түбəндəге бурычлар куелды: əсəрлəрендəге вакыйгалар эзлеклелеген, гомуми барыш һəм хəрəкəт схемасын тикшерү; əсəр нигезенə салынган вакыйгаларны, кешелəр арасындагы һəм кеше белəн җəмгыять арасындагы мөнəсəбəтлəрне ачыклау; əсəрлəрдə образның рухи дөньясын, тема, идеялəр һəм психологизм төшенчəлəрен традициялəрне дəвам итү һəм яңачалык җирлегендə тикшерү, нəтиҗə ясау.

**Слайд 3** Хикəяче, романнар авторы, драматург, публицист Мəдинə Маликова иң беренче басылып чыккан «Юлдашлар» (1967) исемле беренче җыентыгында ук тирəн əхлакый мəсьəлəлəрне җитди итеп куярга омтылуы белəн аерылып тора. Аның беренче хикəялəре үк моның ачык мисалы була.

**Слайд 4** Ə хəзер язучы иҗаты буйлап əдəби-экскурсия чыгабыз. Алдыбызда «Көмеш билбау» əсəре. Авторның детектив сюжетка корылган яңа романында узган гасырның туксанынчы елларында – үзгəрешлəр чорында булган вакыйгалар, яшьлəрнең мəхəббəте, шəхес буларак җитлегүе, кискен бəрелешлəре тасвирлана.

**Слайд 5** Алдыбызда «Сандугачның күз яше» романы гасырлар алышынган чорда булган кискен үзгəрешлəрнең кеше язмышына, аның рухына һəм үз-үзен тотышына йогынтысын тəсвирлый. Бүгенге көндə яшь кешегə үз юлын сайлау өчен зур мөмкинлеклəр бирелгəн. Лəкин шул ук вакытта аларга төрле афəтлəр дə яный.

**Слайд 6** «Арыш тəме» əсəре өчен автор республикабызның Г. Тукай исемендəге Дəүлəт премиясенə тəкъдим ителде. Романының төп герое – Айзирəк. Ул сөйгəн егете Васил белəн бəхетле гаилə корырга əзерлəнə, килəчəктə яраткан эшендə уңышларга ирешү турында хыяллана. Фаҗигалəр, кавышулар.

**Слайд 7** «Кызыл гөл» əсəрендə сөйгəн ярын язга күмеп, бəхет бишегендə генə тибрəтү турында кем генə хыялланмый икəн? Əмма бу матур хыялга ирешү юллары сикəлтəле, кантарлы. Аларга бер яктан без үзебез ясаган хаталар киртə салса, икенче яктан ил өстенə килгəн фаҗигалар, иҗтимагый яшəешнең көйсезлеклəре ташлар өйгəндəй итə.Изге хыялларың чынга ашсын дисəң, үзеңне генə түгел, илеңне кайгыртып яшəргə кирəк.

**Слайд 8** «Мендем биек тауларга» дип исемләнгән китапка кергән ике повесть һәм бер роман гасырлар алышынган чор, үзгәреш елларында булган вакыйгалар тасвирлана. Ил әкренләп хәлсезләнде, аннары бөтенләй таралды. Күпләр зур сынаулар аша үтәргә мәҗбүр булды. Кемнәрдер биреште, үз юлыннан тыйпылды, кемнәрдер фаҗигага юлыкты, кемнәрдер зур тырышлык куеп, намус сафлыгын да, мәхәббәтен дә саклап кала алды. Язмышлар төрле-төрле, бар гыйбрәт булырлыклары, бар үрнәк алырлыклары.

**Слайд 9** «Тылсым». «Шәфкать» әсәрләренә килгәндәмәхәббәт һәм иман... Боларның бер-берсенә катнашы, мөнәсәбәте бармы? Иманлы кеше гашыйк булса, үз-үзен ничек тота да, имансызы нинди гамәлләр кыла? Аны кылганнары мәгъшугы белән ике арада гына каламы, әллә бүтәннәргә дә таш булып килеп бәреләме? Бу китап менә шундый гыйбрәтле язмышлар турында.

**Слайд 9** «Кар сулары» дип исемләнгән хикәяләр җыентыгы ниләр сөйли? Табигатькә, әйләнә-тирә мохиткә мөнәсәбәт яктылыгында яшүсмер кызның самими образын гәүдәләндергән «Кар сулары» лирик хикәясе, шундый ук лирик тонда язылган «Сары тюльпаннар», «Көндәшләр», «Ай сүрелгән чак иде», «Узма, гомер!», «Берәгәйле бәрәңге» һ.б. хикәяләр моның ачык мисалы булып тора.

**Слайд 10** «Югалган якутлар»әсәренең үзәгендә җәмгыятебездә булган төп проблема - наркомания, эчкечелек, гаилә һәм тәрбия мәсьәләләре. Вакыйгалар йөрәк аша үтеп, күңел кылларын тибрәндерә. Төп герой Гамил һәм аның гаиләсе үрнәгендә кешенең рухи дөньясы, кешеләр арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләр сурәтләнә. Автор яшәешнең мәгънәсен яхшылыкка, матурлыкка хезмәт итүдә күрә. Гамил нык ихтыяр көче булган кеше буларак күз алдына килеп баса.

**Слайд 11** Татарстан Республикасының Милли китапханәсе Мәдәният министрлыгы, Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы белән берлектә үткәрелә торган «Ел китабы – 2010» конкурсында Мәдинә Маликованың «Саф сөю турында кыйссалар» әсәре 3 урынга лаек булды.

**Слайд 11 «**Юкә чәчәк аткан чак иде**»** әсәре. Адәм баласын кеше иткән төп сыйфат - ул матурлыкны күрә белү, аннан тәм таба белү; аны үз кулларың белән булдырып, тормышны бизәү. Чын сөю - шулай ук матурлыкны тудыруга тиң. Сөя белгән кеше үзен, сөйгәнен, бөтен яшәешен күңел нурлары белән бизи.

**Слайд 12** Әсәрләр тезмәсен бик күп дәвам итәргә булыр иде. Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, халкыбызның зыялы язучысы, хатын-кызлар арасында роман жанрында иҗат итүче әдибә Мәдинә Маликова да җәмгыятебезнең бүгенге тормышы, киләчәге, кешелек дөньясының язмышы турында уйлана.

## ОБРАЗ ЖЕНЩИН В ПРОЗАХ МАДИНЫ МАЛИКОВОЙ

Залилова Аида Ренатовна, Джалильская СОШ №1, Сармановский район

В литературе немало произведений, где правдиво и честно описана женская доля. Хотелось бы проанализировать творчество татарского прозаика и драматурга Мадины Маликовой. Одной из особенностей ее творчества является то, что все главные герои ее произведений – женщины различных специальностей: врачи, архитекторы, артисты, поэтессы, химики, ученые, художники, поэтессы, бизнесмены, руководитель благотворительного общества, первый секретарь обкома. Зачастую героями ее произведений становятся просто женщины-матери.

Повесть «Весенние венки», например, дополняет коллективный портрет современной женщины. Несмотря на присутствие колорита военного времени, атмосфера повести пронизана светлым лиризмом, добротой, заботой о близких. Произведение представляет собой воспоминания бабушки Газзи.

В романе «Фидая» главная героиня – женщина, занявшая высокую должность, потерявшая мужа, которая одна растит дочку. Фидая поднимается по карьерной лестнице до должности секретаря обкома. Но в один миг весь мир рушится, ее снимают с должности, и Фидая остается наедине с собой. Этим романом М. Маликова показывает, насколько трудно женщине работать в мужском коллективе, строить свою карьеру; вдвойне труднее вдове, если она красивая, умная. Мирные годы по-новому характеризуют коллективный портрет женщины.

Все радости и печали современной жизни описываются в прозе М. Маликовой. Романом милосердия и нравственности считают произведение «Милосердие». Роман о врачах-гинекологах, которые дарят жизнь людям, надежду женщинам, счастье семьям. В то же время они обычные люди, у них такие же житейские проблемы, как и у всех женщин: семейные неурядицы, измена, несчастная любовь. Автор, описывая жизнь врачей-ученых, затрагивает проблему века: черствость душ, черную зависть, предательство близких и необходимость быть милосердными.

На рубеже веков М. Маликова обрела новое дыхание. Перо ее стало более острым, энергичным и сатиричным.Судьба героини повести «Золотые цепи» Таслимы круто и трагично переменилось в связи с коренными изменениями в стране. Раньше она служила красоте, искусству, вела детский танцевальный кружок. Таслима была счастлива и уверена, что нашла свое призвание и место в жизни, что имеет любимую семью, детей, работу. Но жизнь все изменила, и все рухнуло. Дворец культуры остался без средств, детские кружки распались, она потеряла любимую работу, да и муж-инженер после закрытия завода остался без работы... Чтобы прокормить семью, Таслима стала «челночницей-торгашкой». В дом вернулся достаток, но исчезли душевное равновесие и покой.

Детективный роман М. Маликовой «Вихрь» охватывает все те же проблемы бытия. Простая женщина – Жаухария, видя все трудности жизни: нищету, голодных и голых детишек, инвалидов, организует благотворительное общество, делает все возможное, чтобы помочь им. Но, к сожалению, есть такие люди (Даниф), которые из-за корыстных целей разрушают все, что сделано во благо людей, для них нет ничего святого.

Совершенно новый роман М. Маликовой «Очарование». Он также о женских судьбах. Автор в контексте сравнивает двух девушек: Ленизу и Анису. В начале произведения их судьбы чем-то схожи: обе сироты, выросли с чужими людьми, влюблены в одного и того же человека – Мидхата. Но характеры у девушек совершенно разные. Лениза по природе своей ревнивая, беспомощная, всегда ждет помощи со стороны. А Аниса решительная, знает, чего она хочет и умеет ждать своего момента и вести себя достойно. Лениза не может найти себе места в жизни, ее что-то тревожит, она не доверяет мужу, не умеет любить и быть любимой, что так важно для каждой женщины. В итоге она теряет все то, что щедро подарила ей судьба: ребенка, любимого мужа, семью, попадает в секту и сама тоже пропадает без вести. А Аниса, напротив, приобретает все, о чем мечтала: любимого человека, достойную профессию. Автор еще раз доказывает, что вера, надежда и любовь должныжить в каждом человеке.

Проанализировав произведения женщины-прозаика, можем сказать, она талантлива, ее романы интересны для читателя. Она пишет в основном о обществе, семье, любви, смерти, предательстве, рассказывает о судьбах разных людей, показывает реальный мир, ищет ответы на самые актуальные и сложные жизненные вопросы.

## «ЧӘЧКӘ БАЛЫ» ПОВЕСТЕ БУЕНЧА СЫЙНЫФТАН ТЫШ УКУ ДӘРЕСЕ

Зарипова Зөлфия Флер кызы,
Зур Нөркәй урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**Максат.**Укучыларның әсәрнең эчтәлегенә төшенүләренә, геройларга хас сыйфатларны дөрес бәяли алуларына ирешү.Укучыларның монологик һәм диалогик сөйләмнәрен үстерү.Укучыларда күркәм әхлак сыйфатлары тәрбияләү.

Планлаштырылган нәтиҗәләр. Предмет буенча:

М. Маликованың иҗаты турында белешмә алу. «Чәчкә балы» повестеның идея эчтәлегеначыклау. Әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын билгели белү. Әсәрнең үзенчәлеген, иҗат методын билгеләү.

Метапредмет нәтиҗәлелек: әйләнә-тирәдәге тормышны мөстәкыйль бәяли белүгә ирешү, әсәр эчтәлеген аңлау, төп фикерне табабелү.Үз фикереңне дәлилли, кирәк икән, үзгәртә, төгәлләштерә, нәтиҗәләр чыгара алу. Төп образга карата башкаларның фикерен тыңлау, үз фикереӊ белән чагыштыру, дәлилләү. Әсәрнең эчтәлеген мөстәкыйль рәвештә үзләштерү һәм анализ ясау күнекмәләре булдыру. Әсәр буенча дөрес нәтиҗәләр чыгару, гомумиләштерүләр ясау.

Шәхси нәтиҗәләр: укучы шәхесенең әхлакый-рухи сыйфатларын камилләштерү.

***Дәрес төре*:** дәрестән тыш уку.

**Җиһазлау.** М.Маликова иҗатына карата әдәби бюллетень, М.Маликова әсәрләреннән китап күргәзмәсе, мәкальләр язылган плакатлар, матбугат, интерактив такта, презентация.

**<u>Дәреснең планы</u>**

**I.Ориентлашу, мотивлаштыру этабы**

1). Исәнләшү. Уңай психологик халәт тудыру.

2) Актуальләштерү. а) М.Маликова турында Г.Ахунов сүзләрен уку ә) Иҗаты турында әңгәмә кору б) картадан туган авылын табу.

3) Уку мәсьәләсен конкретлаштыру ситуациясе процессы а) Әсәрнең эчтәлеген сөйләү.

**II.Уку мәсьәләсен (УМ) чишү этабы.**

Әсәрнең идеясен ачыклау. Гамил образы өстендә эш. Ике анага чагыштырма характеристика бирү. Ике гаиләне чагыштыру. Әсәрдәге проблемаларны табу. Әсәрдән Җәмил турында язылган урыннарны табып уку. Газета-журналлардан эчкечелек һәм наркомания турында уку.

**III.Рефлексия, бәя этабы**

1. Куелган максатларга ирешү-ирешмәүне билгеләү.
2. Макарның җинаять юлына этәрүче сәбәпләрне санагыз

**VI. Өйгә эш бирү.** 1.“Баккан ана кадерлерәк” темасына кечкенә инша язарга. 2. Наркомания турында газета-журнал материаллары тупларга.3. Гаилә турында халык мәкальләре язып килергә.

## МӘДИНӘ МАЛИКОВА ИҖАТЫНДА ӨЛКӘННӘР ХЕЗМӘТЕ

Иксанова Рәмзия Мөдәрис кызы,
5 нче «Әкият» балалар бакчасы тәрбиячесе, Җәлил бистәсе, Сарман районы

Проект балаларны Мәдинә Маликова иҗаты белән кызыксындыру өчен, балаларның һәм ата-аналарның уку культурасын күтәрүгә юнәлтелгән. Бу проект - Мәдинә Маликова иҗатына ачкыч.

**Проектның максаты:** балаларны Сарман районы язучыларының иҗат мирасы белән кызыксындыру һәм таныштыру;

**Проектның бурычлары:** Балаларны Мәдинә Маликова иҗаты һәм тормыш юлы белән таныштыру. Мәдинә Маликова иҗаты аша балаларда өлкәннәр хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү. Ата-аналарның татар әдәбияты турында белемнәрен киңәйтү һәм аларны гаилә укуларына һәм әдәби әсәрләрне укуларына гадәтләндерү.

Проектның тормышка ашыру өлкәсендә көтелгән **нәтиҗәләр**:

- Балаларны Мәдинә Маликова әсәрләре белән таныштыру өчен төркемдә һәм гаиләдә кирәкле шартлар тудыру; проектны тормышка ашырганда ата-аналарның актив катнашуларын күздә тоту; гаилә укуларының әһәмиятлелеген ата-аналар тарафыннан дөрес аңлау; Мәдинә Маликова әсәрләрен танып белү, кызыксыну чыганагы итеп карату;

**Проектны тормышка ашыру этаплары**

| Этаплар | Эшнең эчтәлеге | Вакыт |
|---|---|---|
| 1 этап-әзерлек этабы | - Катнашучылар белән проектның максатлары һәм бурычларын ачыклау;<br>- Проектны тормышка ашыру буенча кирәкле шартлар тудыру;<br>- Проектны тормышка ашыруны алдан күрә белү һәм нигезләү; | 1 атна |
| 2 этап-төп | - Төркемдә предмет-үстерү чолганышы яхшырту (китап почмагы, информация стенды);<br>- Мәдинә Маликованың иҗаты һәм тормыш юлы өйрәнү буенча балалар белән шөгыльләнү;<br>- Ата-аналарны укыту (Мәдинә Маликованың иҗади эшчәнлеге турында алар белән сөйләшү)<br>- Проблема буенча методик әсбаплар булдыру һәм туплау;<br>- Балаларда Мәдинә Маликованың иҗат мирасына кызыксындыру тудыру өчен төркемдә, гаиләдә кирәкле шартлар тудыру.<br>- “Мәдинә Маликованың иҗаты” танытмасын төзү, тарату; | Проектны үтәү чорында |
| 3 этап-йомгаклау | - Проектның үтәлешен күрсәтә торган нәтиҗәләрне туплау;<br>- “Балаларның иҗат профессиясе вәкилләре турындагы күзаллауларын үстерүдә Мәдинә Маликова әсәрләренең әһәмияте” семинар-практикумда проектны презентацияләү | 4 атна |

**Балалар белән эш.**

| **№** | **Чаралар** | **Максатлар** | **Вакыт** |
|---|---|---|---|
| 1. | Төркемдә күчмә китапханә «Барысы да Мәдинә апа турында» оештыру. | Проектны тормышка ашыру буенча шартлар тудыру. М.Маликованың китапларына кызыксыну үстерү. | 1- атна |
| 2. | Кичке кычкырып укулар «М.Маликованың могҗизалар тулы китап дөньясына сәяхәт» | Балаларда М.Маликованың китапларына карата кызыксыну уяту. | 1-4 атна |
| 3. | «Мәдинә Маликова – балаларга» дигән китап күргәзмәсе. | Балаларны М.Маликова китаплары һәм үзе белән таныштыру, укырга кызыксыну уяту. | 2- атна |
| 4. | М.Маликова иҗаты буенча карточкалар төзү. | Әдәбият белән эшләгәндә эзләнү эшчәнлеген оештыру. Балаларның дөньяга карашын киңәйтү. | 2-атна |
| 5. | М.Маликова әсәрләреннән өзекләр уку: «Шәфкать» | Балаларда матур әдәбияткә кызыксыну уяту һәм үстерү, геройларның кыланышларын бәяли белергә өйрәтү. | 2- атна |
| 6. | Иртәнге әңгәмәләр «М. Маликова әсәр өзекләре буенча хикәя төзү» | М.Маликова әсәрләренә кызыксыну уяту, укыган буенча хикәя төзү осталыгын үстерү. | 1-4 атна |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7. | Музыкаль эшчәнлек: җырлар тыңлау | Җырлау сәләтен үстерү, бер-берсен тыңлый белергә өйрәтү, әсәрне игътибар белән тыңларга өйрәтү һәм әсәрнең жанрын билгели белү. | 1-4 атна |
| 8. | «Янар таулар яктысында» повесте буенча рәсем ясау. | М.Маликова әсәрләрендәге персонажлар буенча рәсем ясау осталыгын ныгыту. Балаларны үзләрен чын рәссам итеп тоярга өндәү. | 2-атна |
| 9. | «Казан каласы - таш кала» әсәре буенча аппликация. | Балаларда шатлык хисе уяту һәм композицияны кызыклы итеп ясарга омтылу.Төрле төсләрдә күрсәтә белү, бер-берсенә дусларча мөгалләмәдә булырга өйрәтү. | 2- атна |
| 10. | «Китап кадере» | М.Маликова әсәрләренең образлы эчтәлеген эмоциональ кабул итә белергә өйрәтү, геройның характерлы үзенчәлекләрен сөйләп күрсәтергә өйрәтү, башлаган эшне ахырына хәтле җиткерергә өйрәтү. | 3-атна |
| 11. | Мәдинә Маликова әсәрләре буенча балалар рәсем конкурсы «Нәрсә укыдың, нәрсә күрдең, нәрсә бирдең -шуны кәгазьдә төшер» | Яраткан әсәрләрнең эпизодларын сүрәтләү, кузаллауны һәм иҗади активлыкны үстерү. | 3-атна |
| 12. | «Хөкем», «Адашканга юл кая?» мажаралы повестьлары | Балаларны детектив жанры беләнтаныштыру. | 3-атна |
| 13. | Ата-аналар белән берлектә «Һөнәрләр илендә» дигән темага балаларның үзләре ясаган әйберләре күргәзмәсе | Балаларның иҗади һәм кул хезмәте һөнәрләрен, фантазияларын үстерү. | 3-атна |
| 14. | Балалар хикәяләренең «Минем иң яраткан героем» дигән презентациясе. | Балаларны укыган әсәр өзекләре буенча төзелгән кечкенә хикәяләр ярдәмендә иҗади активлыкларын үстерү. | 3-атна |
| 15. | «Язучының бер әсәре буенча кечкенә генә өзек» темасына театраль чыгыш. | Бу чыгыш вакытында эмоциональ шатлык хисе тудыру. Балаларны үз теләкләре буенча роль сайларга өйрәтү. Геройларның характерлы үзенчелекләрен күрсәтергә өйрәтү. | 4-атна |
| 16. | Әңгәмә “Нәрсә ул яхшы, нәрсә ул начар?” | Геройларның кылган эшләренә, эхлакый сыйфатларына дөрес бәя бирергә өйрәтү. | 4-атна |

**Ата-аналар белән эш.**

| **№** | **Чаралар** | **Максатлар** | **Вакыт** |
|---|---|---|---|
| 1. | Ата-аналарны М.Маликова китапларын уку буенча анкета тутыру. | Ата-аналар балаларга нәрсә укыганнарын ачыклау, балалар нәрсә турында тыңларга ярataлар. | 1-атна |
| 2. | Тәрбияче, ата-аналар һәм балалар белән берлектә «Түгәрәк өстәл» | Проектның максатын һәм бурычларын билгеләү. Ата-аналарда проектка карата кызыксыну уяту. | 1-атна |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3. | «Балалар бакчасына китап бүләк ит» дигән акция | Төркем китапханәсен Сарман язучылары китаплары белән баету. Ата-аналарны, балаларны проекта катнашасы килү теләген устерүен дәвам итү. | 1-атна |
| 4. | «Китаплар укырга ничек кызыксыну тудыру?» дигән консультациялар. | Төркем китапханәсен язучы китаплары белән баету. Ата-аналарны, балаларны проекта катнашасы килү теләген устерүен дәвам итү. | 1-2 атна |
| 5. | «М. Маликова китапларын укырга тәкъдим итәбез» дигән акция | Ата-аналар белән балаларны Мәдинә Маликованың иҗат мирасы белән таныштыру турында сөйләшү. | 2-атна |
| 6. | «Мәдинә апа китапларын укыйбыз» | Балаларны М.Маликова иҗат мирасы белән таныштыруны дәвам итү. Балаларның китапханә дөньясын белүе белән танышу. Басма сүзгә кызыксыну үяту. Китапларга сакчыл караш тәрбияләү. | 2-атна |
| 7. | «Бөтен гаилә Мәдинә апа китаплары белән дуслаша» дигән ата-аналар клубы | Балаларда М.Маликова иҗаты белән кызыксындыру уяту буенча ата-аналарда тупланган гаилә тәҗрибәсе буенча бер-берсе белән аралашуларын оештыруга мөмкинлек тудыру . | 4-атна |
| 8. | «Кечкенәләрне язучы китаплары белән ничек дуслашырга» дигән истәлек | Ата-аналарда язучы китапларына кызыксыну саклау. | 4-атна |

Проектының әһәмиятлелеге шунда ки, шушы проектка нигезләнеп балаларны Мәдинә Маликова әсәрләренең серле дөньясына кертү буенча гаиләдә яңа юнәлешләр барлыкка килүдә.

## Йомгаклау

Мәдинә Маликова иҗатына колачлылык, киң планлылык хас. Чыннан да, соңгы чирек гасыр эчендә ул табиблар, галимнәр, инженерлар турында иң күп иҗат итүчеләрнең берсе. Ул иҗат объектын тирән белә, һәръяклап ача, персонажларының эчке дөньясын тулы һәм җентекле итеп сүрәтли.

Мәдинә Маликова иҗаты татар әдәбиятында узенең лаеклы урынын алды. Иң әһәмиятлесе шул: мөхтәрәм язучыбызның басып сайрар талы бар. Ул – аны яраткан, хөрмәт иткән халкыбыз.

## Кулланылган әдәбият

1. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге.- Казан: Мәгариф, 2007.
2. Маликова М.Г. Тылсым. Шәфкать: романнар/ М.Г.Маликова.- Казан: Тат.кит. нәшр., 2007.
3. “Мәйдан” журналы, 2004, №7

## МӘДИНӘ МАЛИКОВА– КҮПКЫРЛЫ ШӘХЕС

Исмәгыйлева Минзирә Рәсим кызы, Садыйкова Гөлсинә Солтан кызы,
Казан шәһәре Киров районытатар телендә белем бирүче өченче гимназия

**Максат:** Мәдинә Маликованың тормышы һәм иҗаты белән танышып чыгу һәм аның тәрбияви әһәмиятен билгеләү .

**Бурычлар:** язучы иҗатына карата кызыксыну уяту, мәхәббәт тәрбияләү, аның иҗаты турында күбрәк белү теләге үстерү. Әсәрләр аша туган телебезнең байлыгын, матурлыгын күрсәтү, һәм соклану хисләре уяту, гореф-гадәтләребезгә, милләтебезгә хөрмәт белән карарга һәм ихтирамлы булырга өйрәтү.

**Җиһазлау:** Мәдинә Маликова китапларыннан күргәзмә.

**Укытучы:**Хикәяче, романчы, драматург, публицист Мәдинә Маликованың тормышын өйрәнү, яшь буынга җиткерү бүгенге көндә бик актуаль**.** Бүгенге класс сәгатебез татар телендә романнар иҗат иткән беренче хатын-кыз язучы, Татарстан язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге премиясе лауреаты, Татарстан журналистларының Х.Ямашев исемендәге премиясе лауреаты, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Мәдинә Маликовага багышлана. Ярты гасырлык иҗат дәверендә, аның татар һәм рус телләрендә 30 китабы басылып чыга, пьесалары республика театрларында сәхнәләштерелә. Мәдинә Маликова чыгышы белән сандугачлы Сарман якларыннан. (Укучылар биографиясе белән таныштыралар)

**Укучы:**М. Маликова иҗатына колачлылык, киң планлылык хас. Ул соңгы чирек гасыр эчендә табиблар, галимнәр, инженерлар турында иң күп иҗат итүчеләрнең берсе. Ул иҗат объектын тирән белә, һәръяклап ача, персонажларының эчке дөньясын тулы итеп сурәтли

**Укучы:**М. Маликова детектив жанрында да уңышлы гына эшли. Аның «Хөкем» (1969), «Адашканга юл кайда?» (1971) исемле маҗаралы повестьлары мавыктыргыч, киеренке вакыйга-сюжетка корылган һәм укучылар тарафыннан яратып укыла.

**Укучы:**Язучының «Казан каласы – таш кала» (1967), «Кояш күпере» (1973), «Янар таулар яктысында» (1977) повестьлары, «Шәфкать» (1985), «Басып сайрар талы бар» (1987), «Фидая» (1990) романнары шәһәр һәм авыл зыялылары – инженерлар, архитекторлар, рәссамнар, табиблар, артистлар тормышына багышлап язылганнар.

**Укучы:** М. Маликова драматургия өлкәсендә дә уңышлы гына эшли. Аның «Оҗмах балалары» исемле драмасы Г.Камал исемендәге академия театры сәхнәсендә куела (1990), «Йөрәк ничек түзсен», «Моңнар төште башыма», «Синең өчен үзем үләрмен» исемле драма әсәрләре Минзәлә һәм Әлмәт театры сәхнәләрендә зур уңыш белән бара. «Сөембикә» трагедиясе 2004 нче елда уздырылган “Яңа татар пьесасы конкурсы”нда бүләккә лаек була.

**Укучы:**Халык язучысы Аяз Гыйләҗев үзенең бер чыгышында Мәдинә Маликованы «зыялы язучы» дип атаган иде.

**Укучы:** Күптән түгел дөнья күргән «Сандугачның күз яше» романында хәзерге яшьләр, бүген бара торган вакыйгалар, проблемалар күтәрелә. Үзәктә – яшьләр. Бүгенге көндә 9 роман авторы булган М. Маликованың иң беренче романы - «Шәфкать». Инде күпләр онытa да башлаган роман медицина дөньясын реаль җирлектән чыгып яктырта. Романның геройлары табиблар да, башкалар кебек үк, җан ияләре. Аларга да мәхәббәт, хөсетлек, тар күңеллелек, коллегалардан көнләшү кебек сыйфатлар хас.

**Укытучы:** Мәдинә Маликова иҗаты белән горурланабыз. Аның әсәрләрен укыган саен укыйсы гына килеп тора. Миңа калса, халык арасында тәвәккәллеге, кыюлыгы, күп сүзгә урын калдырмыйча өздереп әйтә белүе белән дә танылган язучының әсәрләре башка телдә дә бик яңгыраш таба. Мәдинә Маликова иҗаты татар әдәбиятында үзенең лаеклы урынын алды. Күренекле әдибебез киләчәктә дә яңадан-яңа әсәрләре белән укучыларны куандырыр, дип чын күңелдән ышанасы килә.

**Кулланылган әдәбият:**

1. Мәдинә Маликова «Югалган якутлар».- Казан, « Рухият» нәшрияты, 2004.

2. Мәдинә Маликова «Шәфкать».- Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1990.

## КЕШЕ ӨЧЕН ТОРМЫШ КАДЕРЛЕ

(Сыйныф сәгате эшкәртмәсе)

Ихсанова Римма Ильяс кызы, Шәйдуллина Чулпан Камил кызы,
икенче санлы Җәлил урта мәктәбе укытучылары, Сарман районы

**Максат:** укучыларны әдәби әсәр эчтәлеге аша тормыш турында уйландыру, төрле тормыш хәлләре аша хаталардан сак булырга өндәү, кеше булып калырга чакыру.

**Җиһазлау:** М.Маликова әсәрләреннән китап күргәзмәсе, автор турында белешмә материал, презентация.

**Алып барылган әзерлек эше**: берничә укучының бүленеп, М.Маликованың әсәрләрен укуын, эчтәлеге буенча чыгыш ясарга әзерләнүләрен сорау.

**Сыйныф сәгате барышы**

- Хәерле көн укучылар. Бер генә минутка күзләребезне йомыйк та үзебезне ап-ак ромашкалар үскән болында дип хис итик әле. Тирә-якта кошлар сайрый, якты, җылы кояш битне иркәли, бөтен дөньяга хуш ис таралган. Без чәчәкләрнең исен иснәп, иркен итеп сулап куябыз. Безгә шундый рәхәт булып китә.

Без бүген шул рәхәтлекләрне тоярга һәм сизәргә мөмкинлек биргән тормыш турында сөйләшербез. Безнең бүгенге әңгәмәбез “Кеше өчен тормыш кадерле” дип атала. Минем аны түбәндәге сораудан башлыйсы килә? Сез бу сүзләрне ничек аңлыйсыз икән?

1. Нәрсә ул тормыш? (Гомер, яшәү)

2.Тормыш төшенчәсе белән нинди төшенчәләр бәйле? Тормыш дигәндә куз алдыгызга нәрсәләр килә? (Язмыш, гомер, бәхет, гаилә...)

- Экранга карагыз әле, укучылар. Анда сез күренекле кешеләрнең фикерләрен – афоризмнарны күрәсез.

**Экранда:**

Кеше өчен иң кадерле нәрсә – тормыш. Ул аңа бер тапкыр гына бирелә. Аны шундый итеп яшәргә кирәк, файдасыз яшәгән еллар өчен үкенерлек булмасын, үлгәндә дә: бөтен тормыш, барлык көч дөньяда иң гүзә нәрсәгә бирелде, дип әйтерлек булсын. (Н.Островский)

Тормыш – бер очы янып, көлгә әйләнеп, икенче очы, чәчәк атып, җимеш бирүче мәңгелек агач. (Ш.Галиев)

Яшәү - туктаусыз алга бару ул. (С.Джонсон)

Җиңел тормыш эзләгән кеше - иң мескен кеше. (Д.Джордан)

Кешенең иң кадерле нәрсәсе - гомере. Яшәү – эзләнү һәм борчылулар утында яну ул.(Э.Верхарн)

Чын тормышның төп максаты – гүзәллекне тоя белү, яхшылыкка омтылу. (А.Платон)

Кеше үз тормышын үзе бизәргә тиеш. Дөнья матур, якты. Тик шул матурлык, шул яктылык белән файдалана белергә кирәк. (М. Кәрим) (Афоризмнар буенча фикер алышу үткәрү)

- Рәхмәт, укучылар. Игътибарыгызны менә бу китап киштәсенә юнәлтегез әле. Монда якташ язучыбыз Мәдинә Маликова әсәрләрен күрәсез. Аның әсәрләрендә дә тормышчан вакыйгалар, геройлар тормышы сурәтләнә. Аларның кайсыларыдыр бәхетле, кайсыларыдыр бәхетсез кешеләр. Нинди генә әсәрне алма, ул тормыш турында сөйли, кешеләрнең хаталары, уңышлары белән таныштыра, сабак алырга чакыра.

Сүзне М.Маликова әсәрләрен укып, үз фикерләре белән уртаклашырга теләүчеләргә бирәсе килә. Бер сорауга җавап эзлибез. Бу әсәр безне нәрсәгә өйрәтә? Тормышчан сабагы нинди?

**Беренче укучы** «Сары тюльпаннар» хикәясе буенча чыгыш ясый. (**Кыскача белешмә**: хикәядә Люция исемле кызның мәхәббәте сурәтләнә. Ул киң күңелле, чиста җанлы, мәхәббәтне иң зур хис итеп кабул иткән кеше. Аның кияүгә чыгасы, үзен һәм үзе яраткан кешене бәхетле итәсе, шул кешенең киң күкрәгенә сыенып, җил-давылдан ышыкланасы килә. Аңа аны аңлый торган кеше кирәк. Ә ул гашыйк булган егет шул хисләрне пычрата, таптый, изә).

Укучы чыгышыннан соң "Мәхәббәттә тугрылык" темасына әңгәмә оештырыла. Флүннең гамәлләренең бик пычрак булуын, андый булырга ярамаганлыгын искәртәбез.

**Икенче укучы** «Егетлеккә бер адым» повесте буенча чыгыш ясый. (**Кыскача белешмә**: әсәрнең герое – яшүсмер Бикташ. Аның тормышы җиңелләрдән түгел. Аны әнисе ялгызы гына үстерә. Әтиләре алар белән яшәми. Тик менә фатир алырга кирәк булгач, аны яңа хатыны малаен алып килергә чыгарып җибәрә. Әтисен күрүгә шат малай, әнисенең сүзен тыңламыйча, әтисенә ияреп чыгып китә һәм шундый күп кыенлыклар күрә. Әсәрнең исеме бик гыйбрәтле. Ул Бикташның үсүен, аның бервакытта да әтисе эшләгән адымнарны эшләмәячәген күрсәтә)

Укучы чыгышыннан соң нинди генә шартларда да кеше булып кала белергә кирәклеге искәртелә. Образларга характеристика бирелә. Чын ир-егет нинди булырга тиеш? соравына җавап эзлибез.

- Язмыш сиңа җылы елмайганда, кеше булып калу җиңел, ә менә киресенчә булганда, күпкә авыррак, - дип язган Франсуа де Ларошфуко. Бу әсәрләрдә геройларга бик зур сынаулар аша үтәргә туры килгән. Ялгышу бик тиз, ялгышларны төзәтү авыр. Дусларны дөрес сайларга, нидер эшләр алдыннан бик яхшылап уйларга кирәк, укучылар. Бүгенге сыйныф сәгатен тормышта бик күп кыенлыклар күреп тә сынмаган, сыгылмаган Халык язучысы Фәнис Яруллинның «Сорау һәм җавап» шигыре белән тәмамлыйсыбыз килә. Аның да теләкләренә колак салсагыз иде.

## «МИН –БӘХЕТЛЕ ЯЗУЧЫ» (М. МАЛИКОВА)

Корычбаева Гүзәл Сәлим кызы,
29 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе, Түбән Кама шәһәре

**Максат**: М. Маликованың тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштыру. Балаларда мәрхәмәтлелек. әхлаклылык, әдәплелек, үз-үзеңне тәрбияле тоту күнекмәләре булдыру. Китаплар укуга кызыксыну хисләре тудыру.

**Җиһазлау:** М. Маликованың портреты , китаплар күргәзмәсе, презентация, компьютер.

Хәерле көн, укучылар! Һәр милләттә исеме телгә алынуга ук хөрмәт уятырлык шәхесләр була. Шундый исемнәрнең берсе татар телендә романнар иҗат иткән беренче хатын-кыз язучы, Гаяз Исхакый исемендәге премия лауреаты, публицист, драматург, детективлар остасы, җәмәгать эшлеклесе, Россия һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Хөсәен Ямашев исемендәге бүләк иясеМәдәният өлкәсендәге иң зур бүләк – Тукай премиясен алу насыйп булган Мәдинә Маликова. Хәзер, әйдәгез Мәдинә Маликованың тормыш юлы һәм иҗаты белән якыннанрак таныштыру өчен сүзне алдан әзерләнеп килгән укучыларга бирик. ( 1укучы тормыш юлы турында сөйли)

**2 нче укучы** «Кечкенәдән китап корты идем. Хәер, ул чакта китаплар аз иде. Нинди генә басма язма кыйпылчыгына юлыксам да, йотлыгып укый идем шуларны. Әнкәй миңа, тәпи йөри башлаганчы, телең ачылды, ди иде. Арттыргандыр, мөгаен. Ә бәлки, соңрак тәпи киткәнмендер. Әнкәй үзе бик шигъри җанлы кеше, авызыннан шигырьләр коелып кына тора иде. Тик аңа укырга насыйп булмаган, кияүгә чыккан, балалар үстергән – без биш бала идек бит гаиләдә.» диеп яза ул үзе турында.

Мәктәпкә бик яратып йөри. Шигырьләр яза, стена газетасы редакторы була. Концертларда катнашып, үз шигырьләрен сөйләп, сәхнәдән төшми ул.

Мәдинә апа беренче әсәрен 6 нчы сыйныфта укыганда язып, укытучысына күрсәтә. Бу әсәр сугыш вакытында бер пионерның отряд флагын фашистлардан яшереп алып калуы турында була. Ләкин укытучысы әсәрне бәясез калдыра. Мәдинә апаның беренче каләм тибрәтүе шушы булгандыр

**3 нче укучы** Мәдинә Маликованың әдәби иҗат юлындагы беренче адымнары да журналистлык язмаларыннан — көндәлек матбугат өчен хәбәрләр, документаль очерклар, репортажлар, мәкаләләр язудан башлана.

**4 нче укучы** Узган гасырның 70-80 нче елларында 400 меңнән артык тираж белән басылган «Азат хатын» журналында Мәдинә Маликованың очерклары, сәнгатькә, әхлак темаларына багышланган язмалары киң урын ала, журналда басылган беренче хикәяләрен, повестьларын укучылар яратып кабул итәләр.

**Укытучы «**Азат хатын»дагы журналистлык тәҗрибәм булмаса, мин бүген Мәдинә Маликова дигән язучы була алмас идем. Уйлап карагыз, журналистның язу өчен конкрет темасы, ниндидер максаты бар, һәм ул, шуны өйрәнеп, тиешенчә язып чыга. Ә язучының эшен мин болганчык суда чуртан тотарга тырышуга тиңләр идем. Элегәме әле ул, юкмы. Әнә шул журналистлык эшендә җыйган тормыш тәҗрибәм миңа әдәби әсәрләр язганда бик булышты,"- диеп сөйли ул үзенең журналистлык тәҗрибәсе турында.

М. Маликова – детектив әсәрләр жанрында иҗат итүче әдибә.

**5 нче укучы** М. Маликова драматургия өлкәсендә дә уңышлы гына эшли. Аның «Оҗмах балалары» исемле драмасы Г.Камал исемендәге академия театры сәхнәсендә куелды (1990), «Йөрәк ничек түзсен», «Моңнар төште башыма», «Синең өчен үзем үләрмен» исемле драма әсәрләре Минзәлә һәм Әлмәт театры сәхнәләрендә уңыш белән Минзәлә һәм Әлмәт театры сәхнәләрендә зур уңыш белән барды. «Сөембикә» трагедиясе 2004 нче елда уздырылган "Яңа татар пьесасы конкурсы"нда бүләккә лаек булды.

**Укытучы.** Алдагы чыгышлардаМәдинә Маликованың күпкырлы шәхес икәнен әйтеп үттеләр. Язучы иҗаты турында уйланганда әсәрләрендәге зыялылыкка игътибар итәсең. Бүгенге укучы яхшы хәзерлекле, ул әдәби әсәрләрдә тормыштагы төрле хәл-әхвәлләрне күрсәтү белән генә канәгать түгел. Укучы белән фикердәш була алу, аны борчыган сорауларны ачыкларга тырышу, һич югы шул мәсьәләләрне укучы уйланырлык итеп куя белү Мәдинә Маликованың үткер каләмле язучы икәнен тагын бер кат раслый.

Шуның белән, Мәдинә Маликова иҗатына багышланган бүгенге сыйныф сәгатебез тәмам. Игътибарыгыз өчен рәхмәт.

## МӘДИНӘ МАЛИКОВА-ЯРАТКАН ЯЗУЧЫБЫЗ ҺӘМ ЯКТАШЫБЫЗ

(Иҗади проект)

Кәримова Зөлфия Франыс кызы, Җәлил гимназиясе укытучысы
Хәйруллина Зөлфирә Франыс кызы, "Әкият" балалар бакчасының өлкән тәрбиячесе, Сарман районы

**Аңлатма язуы**

Элек – электән кешене тарихка җәлеп итүнең иң актив һәм иҗади формаларының берсе булып, туган якны өйрәнү торган. Рухи кыйммәтләребез үз төсен югалта, онытыла барган бу чорда туган як язучыларын өйрәнү үз Ватанының лаеклы улы яки кызы булырлык шәхес тәрбияләргә ярдәм итә.

**Проектның актуальлеге:**

Әлеге проект бик актуаль, чөнки үз туган ягының язучыларын белмәгән педагог балага да, укучыларга да аны җиткерә алмый.

**Проектның төп максаты:**

Халкыбыз күңеленә кыйммәтле рухи байлык салуда иң зур нәтиҗәгә ирешкән язучыбыз, остазыбыз, якташыбыз Мәдинә Маликова белән бакча тәрбиячеләрен һәм башлангыч класс укытучыларын таныштыру.

Көтелгән нәтиҗәләр: туган як язучыларыбызның иҗатын өйрәнүгә кызыксыну арта.

Проектны тормышка ашыру этаплары:

1.Әзерлек этабы: Бурычлар белән танышу. Кирәкле әдәбиятләр булдыру. Проектны тормышка ашыру өчен шартлар булдыру.

2. Төп этап: Түгәрәк өстәлләр артында сөйләшү, әңгәмәләр үткәрү, туган авылына экскурсия, язучы белән очрашу.

3. Йомгаклау этабы. Педсоветта, база утырышларында чыгышлар ясау.

Проектны тормышка ашыру буенча эш планы

| № | Башкарасы эшләр | Максат |
|---|---|---|
| 1. | Укытучылар һәм тәрбиячеләр белән проект буенча әңгәмә. | Проектнын максаты һәм бурычлары белән танышу. |
| 2. | Китапларын туплау. | Әсәрләренә кызыксыну уяту. |
| 3. | Мәдинә Маликованын балачагы. | Балачагы белән танышу. |
| 4. | Мәдинә Маликова – Сарман кызы. | Язучының тормыш юлы белән танышу. |
| 5. | МәдинәМаликованың – студент еллары. | Язучы укыган уку йортлары белән таныштыру. |
| 6. | Мәдинә Маликова – журналист. | «Чаян», «Азат хатын» журналында эшләгән вакытлар белән танышу. |
| 7. | Мәдинә Маликова – детектив жанрында. | «Хөкем», «Адашканга юл кайда?» исемле маҗаралы повестьлары белән танышу. |
| 8. | Мәдинә Маликова – лирик хикәяләр авторы. | «Кар сулары», «Сары тюльпаннар», «Көндәшләр», «Ай сүрелгән чак иде» хикәяләре белән танышу. |
| 9. | Иң беренче роман язучы хатын кызыбыз. | «Ак давылда тал бөресе» («Шәфкать») исемле романнары белән танышу. «Арыш тәме», «Кызыл гөл», романнарының язылу тарихы белән танышу. |
| 10. | Мәдинә Маликованың мактаулы исемнәре. | Нинди мактаулы исемнәргә ирешүе белән танышу. |

## МӘДИНӘ МАЛИКОВА ИҖАТЫ БУЕНЧА “ҮЗ УЕНЫМ” БӘЙГЕСЕ

Миназова Равия Җәмигънур кызы,
Чуракай төп гомуми белем бирү мәктәбе, Актаныш районы

**Максат: у**кучыларны Мәдинә Маликова иҗаты белән таныштыруны дәвам итү, мөстәкыйль эзләнү эшчәнлеген булдыру, күренекле язучылар белән горурлану хисе тәрбияләү.

**Җиһазлау.** Ноутбук, интерактив такта, М.Маликова портреты,китап күргәзмәсе,”ТАССР–100 ел” плакат.

**Укытучы:** Исәнмесез! Хәерле көн, укытучылар, укучылар. Бүген без “Үз уеным” исемле интеллектуаль уеныбызны башлап җибәрәбез. Әлеге чара ТАССР төзелүнең 100 еллыгына, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә ия булган күренекле язучы – Мәдинә Маликованың тормыш юлы һәм иҗатына багышлана.

Уеныбызда катнашучылар: бишәр укучыдан торган 2 команда. Беренче команда – “Тапкырлар”, икенче команда – “Зирәкләр”. Хөрмәтле тамашачылар! Жюри әгъзалары белән танышып узыйк. (Жюри әгъзалары белән таныштыру).

“Үз уеным” дип аталган интеллектуаль уен кагыйдәләрен искә төшерәбез. Уенда Мәдинә Маликованың иҗаты, тормыш юлы буенча сораулар куелган. Сораулар 4 бүлектән тора. Һәр бүлектәге сораулар баллар белән билгеләнә. Иң түбән балл – 50. Сораулар катлаулырак булган саен баллар да югары. Командалар сорауларны чиратлап сайлыйлар. Рәхим итеп, уенны башлыйбыз.

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Тормыш юлы | 100 | 50 | 90 | 150 | 80 |
| Иҗаты | 50 | 100 | 90 | 80 | 150 |
| Бөек шәхес | 90 | 150 | 80 | 100 | 50 |
| ТАССР төзелүгә –100 ел | 150 | 100 | 90 | 50 | 80 |

**Тормыш юлы:**

1. М.Маликованың туган көне – 100 балл (5 август,1935 нче ел)

2. Туган авылы – 50 балл (Сарман районы Мортыш Тамагы авылы)

3. Кайсы уку йортларында белем ала – 90 балл (Минзәлә педагогия училищесын,Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлый)

4.”Чаян”журналында нинди вазифа башкара? –150 балл (корректор)

5. Һөнәре? – 80 балл ( язучы, драматург)

**Иҗаты:**

1.Нинди жанрларда иҗат итә? - 50 балл (хикәя, повесть, роман, драма)

2. Балалар өчен язылган пьеса -100 балл («Оҗмах балалары» пьесасы )

3. Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куелган әсәр – 90 балл(«Оҗмах балалары» драмасы)

4. Кайсы журналда әдәби хезмәткәр, җаваплы секретарь вазифасын башкара – 80 балл (“Азат хатын” журналы)

5. Беренче хикәяләр җыентыгы кайчан,нинди исем белән басыла? – 150 балл (1967,«Юлдашлар»)

**Бөек шәхес**

1) 1985 елда нинди мактаулы исем бирелә? – 90 балл («Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем )

2) М.Маликованың ничә романы басыла – 150 балл (тугыз)

3) Җөмләне дәвам ит. Мәдинә Маликова – беренче хатын-кыз .....–80 балл ( романист)

4) «Арыш тәме» романы өчен нинди премиягә лаек булды? – 100 балл (Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә)

5) ПРИЗ –50 балл

**ТАССР–100 ел**:

1) Татарстан кайчан төзелгән? – 150 балл ( 1920 елның 27 мае – ТАССР төзелгән көн)

2) Татарстанны дүрт елга иле дип атыйлар. Алар нинди елгалар? – 100 балл (Идел, Кама, Агыйдел, Вятка)

3) Татарстан гимнын язган композитор – 90 балл (Р.Яхин)

4) Татарстанның беренче президенты кем? – 50 балл ( М.Ш.Шәймиев)

5) Кайсы татар бию көе классик әсәр дип танылды?– 80 балл (“Әпипә”)

**Укытучы:** Сорауларга җавап биреп бетердек. Жюри нәтиҗә ясаган арада без татар халкының “Сарман” җырын тыңлап китик. Жюри әгъзалары тулаем уен нәтиҗәләрен, ягъни кайсы команда күпме очко җыйганын саный. Командаларның очколары игълан ителә. Бүләкләү.

**Укытучы:** Мәдинә Маликова иҗаты татар әдәбиятында үзенең лаеклы урынын алды. Күренекле әдибебез киләчәктә дә яңадан-яңа әсәрләре белән укучыларны куандырыр, дип чын күңелдән ышанасы килә.

# БАЛА-ГАИЛӘНЕҢ КӨЗГЕСЕ

(Мәдинә Маликованың «Чәчкә балы» повесте буенча ата-аналар җыелышы)

Мияссарова Ләйлә Кәбир кызы, Шангараева Нәзифә Наил кызы,
икенче санлы Җәлил урта мәктәбенең башлангыч сыйныф укытучылары,
Сарман районы

**Җыелышның максаты:** Мәдинә Маликованың «Чәчкә балы» повестенең эчтәлеге белән танышу, әсәрнең эчтәлеге аша ата-аналар тарафыннан балаларны тәрбияләүдә шәхси үрнәкнең әһәмиятен аңлауга ярдәм итү, бала һәм ата-аналар арасындагы мөнәсәбәтләрнең нәтиҗәлелеген арттыруга ярдәм итү.

**Җиһазлау:** өч стакан су, чәй кашыгы, алтын порошок, ком, губка, кәгазь битләре, ручкалар, киңәшләр һәм теләкләр язу өчен чәчәкләр.

**Җыелышка әзерлек эшләре:** китап күргәзмәсе оештыру, «Чәчкә балы» повестен укып чыгуны тәкъдим итү, китапханәчене һәм психологны чакыру.

Җыелышның барышы.

Оештыру моменты.

Бу җыелышны мин 1920 елда Һиндстанда булган вакыйгадан башлыйсым килә.

«Ике һәм җиде яшьлек ике кыз бүре оясында табыла.. Алар дүрт аякта йөгерделәр, ит белән генә тукландылар. Кызларны приютка алалар, анда кечкенәсе бер елдан соң вафат була, ә өлкәне кеше җәмгыятендә тагын сигез ел яши. Тәрбиячеләрнең зур тырышлыгына карамастан, кыз өченче елга гына аякка баса. "Кешеләрне ул яраткан, әмма аларны үзе кебек кабул итмәгән. Унҗиде яшендә, үсеш дәрәҗәсе буенча, кыз дүрт-биш яшьлек бала дәрәҗәсенә генә җитә. Ул илледән артык сүз әйтергә өйрәнә».

Тарихта тагын утыздан артык шундый очрак билгеле, әмма хайваннарга эләккән барлык балаларның язмышы фаҗигале. Ничек уйлыйсыз, ни өчен? (Чөнки аларны кешеләр түгел, ә хайваннар тәрбияли. Балаларны кешеләр тәрбияләргә тиеш.)

- Хайваннарда тәрбия һәм укыту процессы берничә ай дәвамында бара. Алар үсеп килүче буынны ауга, азык табарга, ерткычлардан коткарырга һәм салкыннан, ягъни олы тормышта туры килгән бөтен нәрсәгә өйрәтә. Ә кешеләрдә тәрбия һәм укыту процессы күпкә катлаулырак һәм озынрак. Ул егерме елга сузыла диярлек. Ягъни кеше үз гомеренең өчтән бере кешеләр җәмгыятендә яшәргә өйрәнә. Галимнәр бу чорның гомер буе дәвам итүен исбатладылар. Бүгенге җыелышыбызның темасы нидән гыйбарәт соң? Аны үзегез формалаштырып карагыз әле (Фикерләр тыңланыла).

Мин бүгенге җыелышыбызда "Бала – гаиләнең көзгесе" дигән темага сөйләшергә тәкъдим итәм. Сез бу мәкальнең мәгънәсен ничек анлыйсыз? (Фикер алышу).

**2.Мотивацияләү этабы**.

- Бу нәрсә? (ата-аналарга губка күрсәтелә). Губкага нинди сыйфатлар хас? (Ул сыеклыкны яхшы сеңдерә).

- Менә бу стаканга зәңгәр буяу бутап, губканы шул суга салксак. Ул нишли? Дөрес, зәңгәр төскә керә.

- Кызыл төсле суга салсак?

- Ә суга 5-6 төрле төстәге буяны салсак? Су нинди төскә керә? Ә губка? (Фикер алышу).

- Мин сезгә бу экспериментны ни өчен курсәттем? Нинди нәтиҗә ясап була?

Безнен балаларыбыз, шушы губка кебек үк, әти-әнисе аңа «керткән» нәрсәне үз эченә ала. Кадерле ата-аналар, бүген без балаларны тәрбияләүдә гаиләнең һәм ата-аналарның мәхәббәтенең нинди роль уйнавын ачыкларга тырышырбыз. Яхшы күңелле, тәрбияле кеше үстерү өчен, балага ата-ана үрнәге кирәк.

**3. Китапханәче белән очрашу.**

2020 ел истәлекле даталарга бик бай, Сез шуларның ниндиләрен атар идегез? (Фикер алышу)

Кластер төзү. 2020 нче ел вакыйгалары: Бөек Ватан сугышында Җиңүгә 75 ел; ТАССРның оешуына 100 ел; Сарман районы оешуына 90 ел; якташыбыз М.Маликованың тууына 85 ел.

Соңгы көннәрдә мин Мәдинә Маликова иҗаты белән танышуымны дәвам иттем. Һәм иң соңгы укыган әдәби әсәрем аның 2003-2004 нче елларда язылган «Чәчкә балы» повесте.

Бу повесть, минемчә, безгә бүгенге җыелышыбызның темасын ачыкларга ярдәм итәргә тиеш. Кемнең бу әсәрне укыганы бар? Мин бугенге очрашуга китапханәче .... чакырдым. Ул сезне кыскача бу әсәрнең эчтәлеге белән таныштырып китәр. **(Китапханәченең чыгышын тыңлау.)**

Ике-өч сүз белән әсәрнең нәрсә турында икәнен билгелик. (Ата-аналарның фикере тыңлана):

Мәхәббәт турында. Хыянәт турында. Күңел сафлыгы, җан пакълыгы турында. Гаилә бәхете һәм бәхетсезлеге турында. Бала язмышы турында. Ата-ана һәм бала мөнәсәбәте турында. Рухи кыйммәтләр һ.б.

Әсәрнең үзәгендә ике хатын-кыз – ике ана. Бу Сәгъдия белән Эльза. Әйдәгез эле төркемнәрдә эшлик. Таблицаны тутыру барышында аларга хас сыйфатларны язып барырга кирәк булыр. (Төркемнәрдә эшләү. Бергәләп тикшерү. Фикер алышу).

Бу әсәрдә тагын актуаль проблемаларның берсе – ул тату гаилә. Ике гаиләне чагыштырыйк. (Тикшерү.Фикер алышу).

Әсәрнең көче – бүгенге көн кадагына суга торган булуында. Повестьта нинди проблемалар алга куела? Әсәрнең үзәгендә җәмгыятебездә булган төп проблема – наркомания, эчкечелек. Җәмилнең авыру бала булып тууының сәбәбе нидән дип уйлыйсыз? (Фикерләр тыңлана.)

Бала багуы – елан агуы, ди халык. Бер бала да начар, явыз булып тумый. Ул өлкәннәр йогынтысында гына бозыла. Бу сүзләр әсәрдәге кайсы образга туры килә? Макарның җинаять юлына этәрүче сәбәпләрне санагыз.

4.Психологик тренинг.

Җыелышыбызны дәвам итәбез. Сүзне психолог... бирәм.

- Хәерле кон. Кечкенә генә эксперимент уздырыйк.

• Һәр гаиләдә ата-ана үз балаларына таләпләр куя, ниндидер кагыйдәләр билгели. Каршыгыздагы кәгазьгә шул кагыйдәләрне баганалап язып чыгыгыз әле. Ә сез бу таләпләрне үзегез үтисезме? Кайсыларын үтәмисез, шуларны сызыгыз. Тагын бер тапкыр тикшерегез, нинди таләпләр калды? Нәкъ менә шушы таләпләрне генә балагыздан таләп итә аласыз.

* Исегездә тотыгыз, бала тәрбияне гаиләдә ала. Оясында ни күрсә, очканында шул булыр, ди халык. Ата-ананын шәхси үрнәге, йогынтылы сүзе, ягымлы һәм таләпчән мөгаләмәсе тәрбиянең нигезен тәшкил итә. Ягъни балада тәрбияләнергә тиешле сыйфатларга беренче чиратта өлкәннәр ия булырга тиеш, чөнки бала шуларны күреп, шуның тәэсирендә үсә, тәрбияләнә.

- Бала тәрбияләүдә һәм аралашуда тагын бер серне белү өчен киләсе экспериментта катнашырга тәкъдим итәм. «Стаканннар» күнегүе. Максат: метафора ярдәмендә ата-аналарның игътибарын бала тәрбиясенә карата гуманлы мөнәсәбәт кирәклегенә юнәлтү.

- Сезнең алда чиста су белән өч стакан. Күз алдыбызга китерик, аларның һәркайсы – яңа туган бала. Туганда һәр баланың күңеле саф, чиста була. Шулай итеп, беренче стаканны алып, аны үзгәрешсез калдырачакбыз. Ләкин без күрмәгәндә, бу стаканга нәрсә дә булса эләгергә мөмкин. Монда су чиста калсын өчен, безгә бик тә игътибарлы булырга кирәк. Икенче стаканга җир кисәкләрен ташлыйбыз һәм аны болгатабыз. Стаканда су нишли? Ни өчен? Өченче стаканга алтын порошок өстибез. Бу стаканда су нишли? Су алтын очкыннар белән уйный. Нинди нәтиҗә ясыйбыз? (Фикер алышу)

Тормышта да баланы тәрбияләү шулай бара. Без баланы игътибарсыз һәм күзәтүсез калдырабыз икән, ул алга таба да үсә. Әмма нинди юнәлештә? Балага «пычрак» - кычкыру, шелтәләр, канәгатьсезлек, хурлау һәм түбәнсетү генә күрсәтәбез икән, бала безгә дә шулай ук итеп җавап бирә башлый. Балага игътибар, мәхәббәт, хөрмәт күрсәтсәк, бала да безгә шул ук мөнәсәбәттә була.

Нәтиҗә ясау. Минем бүгенге очрашуыбыз турында сезнең фикерегезне беләсем килә. «Теләкләр тәкыясы» күнегүе.

Өстәлләрегезгә чәчәкләр бар. Шуларга бүгенге очрашуыбызның нәтиҗәсен ясавыгызны сорыйм. Очрашу дәвамында туган теләкләрегезне, уй-фикерләрегезне языгыз. Соңыннан тактада шул чәчәкләрдән тәкыя үрербез.

Гаилә белән мәктәп кулга-кул тотынып эшләгәндә, бу теләкләребез тормышка ашуына, белем-тәрбия бирүнең нәтиҗәле булуына шигем юк.

Бүгенге җыелышыбызны Мәдинә Маликованың «Чәчкә балы» повесте герое Сәгъдиянең сүзләре белән тәмамлыйсым килә: ”Тормыш никадәр генә авыр булса да, кыенлыклар күпме генә очраса да, түбәнлеккә тәгәрәмә. Кеше булып кал! Тормыш әлифбасын гомер буе өйрәнергә тырыш!”

**Кулланылган әдәбият:**


1. Н.И. Дереклеева. Родительские собрания. 1-4 классы. – М.: «Вако», 2004. – 252с.
2. М.Маликова.Югалган якутлар: повестьлар, пьесалар.- Казан: «Рухият» нәшрияты, 2004.-400б.


## МӘДИНӘ МАЛИКОВА ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ХАТЫН-КЫЗ ОБРАЗЫ ЧАГЫЛЫШЫ


Муллашова Эльмира Рәис кызы,
Яр Чаллы шәһәренең “Бизәкләр” 112 нче балалар бакчасы


Хатын-кыз... Нечкә билле, сылу гәүдәле, кыйгач кашлы, кара күзле, озын толымлы татар хатын-кызлары... Кем генә сокланмый аларга! Матур булуларына карамастан, үтә тыйнак, җыйнак, сабыр, түземле, кунакчыл, сынмас рухлы, батыр йөрәкле, үзенең милләте, дине өчен гомерен дә кызганмаган хатын-кызларның язмышлары кемнәрне генә кызыксындырмый да, кемнәрне генә борчымый?!

Борынгы заманнардан ук җырчылар хатын-кызларны мактап дан җырлаганнар, рәссамнар гүзәл сыннар ясаганнар, ә язучылар һәм шагыйрьләр, аларга атап, мәңгелек әсәрләр иҗат иткәннәр. Татар әдәбиятында хатын-кыз образын яктырткан әсәрләр бик күп. Һәрбер язучы үзенең күңелендәге идеаль хатын-кыз образын тудыра. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасындагы гүзәл Зөләйха образыннан башлап, татар әдәбиятында хатын-кыз язмышын яктырткан меңнәрчә әсәрләр мәгълүм. Борынгы әдипләребез хатын-кызның хокуксызлыгына борчылсалар, соңрак аларның батырлыкларына сокланып иҗат иткәннәр.

Ә егерменче гасыр әдәбиятына күренекле язучы Мәдинә Маликова ныклы адымнар белән атлап керде. Аның әсәрләрен һәрчак көтеп алалар. Бигрәк тә хатын-кызлар. Геройлары – көчле, гүзәл, талантлы, иҗатта һәм хезмәттә максатка ирешергә тырышучы ханымнар. Укучылары аны «Азат хатын» журналисты чагыннан ук беләләр, аның иҗатына гашыйк булып яратып укыйлар. Бер тынга укыла торган «Шәфкать», «Басып сайрар талы бар», «Фидая», «Кызыл гөл», «Юкә чәчәк аткан чак иде» романнары күз алдына ирексездән килеп баса. Һәм, әлбәттә, соңгы романы «Арыш тәме»!

«Арыш тәме»ндәге Нәзилә образы турында Мәдинә Маликова менә нәрсәләр сөйли: ”Талантларны вакытында күреп алу, аларга белем алырга мөмкинлек тудыру – искиткеч мөһим мәсьәлә. Милләтне талантлар баета, халыкара мәйданда таныта. Милләт үзе дә талантлы ул-кызларының кадерен белсен, аларны бәяләсен, яратсын иде! Бездә исә, минем күзәтүемчә, күпләрнең таланты, сәләте ачылмый кала, югала. Бу – аерым шәхесләрнең фаҗигасе генә түгел, милләтнең байлыгын югалту да. Мин моны Нәзилә мисалында калку

итеп күрсәтергә тырыштым.” Бу әсәре өчен Мәдинә Маликова быел республикабызның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә тәкъдим ителде. Язучы бу мәртәбәле исемгә чыннан да лаек!

«Янар таулар яктысында» повестеның төп герое – рәссам Зуфирә. Ул тора-бара үзенең мәшһүр рәссам, ире Эльвирның күренекле композитор булып китүенә ышана. Әсәрендә заман кешеләренең күңел сафлыгы, рух бөеклеге, җәмгыять һәм киләчәк буыннар каршында җаваплылыгы тасвирлана.

«Адашканнарга юл кайда?» дигән повесте миндә аеруча тирән хисләр кузгатты. Монда автор замандашыбызның тормыш философиясе, хис дөньясы хакында, тәрбия темасына кагылышлы катлаулы мәсәләләр күтәрә.Аеруча Зөлфә образы хатын-кызга хас нечкәлек, тирән хис белән иҗат ителгән.Тормыш матурлыгын яңа күрә башлаган, күңеле тулы якты моң, омтылыш булган, тирән мәхәббәт хисе кичерүче бу кызның тәҗрибәсезлеге, беркатлылыгы аркасында алдашуы, ялгышуы күрсәтелә.

«Ак давылда тал бөресе» романындагы Зәйтүнә турында аерым язасы килә. Бездә яшь гаиләләр тиз таркала. Ә Зәйтүнә андыйлардан түгел: иренең хыянәтен белсә дә, йөрәге бик әрнесә дә, үзен нык тота, гаиләне саклау өчен бөтен сабырлыгын җыя. Ахырдан гаилә таркалмый кала. Бу әсәр күп яшьләрне гаилә тормышына аек карарга өйрәтер. Сәламәтлек сагына нык аяк баскан Зәйтүнә Мәҗитованың сүзләре алтын хәрефләр белән язарлык.

Мәдинә Маликова иҗаты татар әдәбиятында үзенең лаеклы урынын алды. Ул яшәешнең хикмәтләрен ача, кешенең теге яки бу адымын ясауга китергән сәбәпләрнең тирән фәлсәфәсен шәрехли, гамәлләренең ахыр нәтиҗәләрен гомумиләштерүләр ярдәмендә күңелгә үткәрерлек итеп яза. Ягъни, укучы белән фикердәш була белә, аны борчыган сорауларны ачыкларга тырыша, һич югы шул мәсьәләләрне укучы уйланырлык итеп куя белә.

**Кулланылган әдәбият**

1. “Мәйдан” журналы, 2004 №7
2. Маликова М.Г. Тылсым. Шәфкать: романнар/ М.Г.Маликова.- Казан: Тат.кит. нәшр., 2007.
3. Яхин А.Г., Әдәбият дәресләре: Укытучылар, югары уку йортлары студентлары һәм укучылар өчен методик кулланма.- Казан: Мәгариф, 2003.

## МАТЕРИАЛ ДЛЯ ПОДГОТОВКИ К ОГЭ ПО АНГЛИЙСКОМУ ЯЗЫКУ

Мусина Гузель Фаритовна, Юнусова Резеда Фадитовна,
учителя английского языка, Джалильская средняя школа №2, Сармановский район

Данная работа предназначена для подготовки к ОГЭ по английскому языку. Работа состоит из 1 задания раздела 2 (задания по чтению) и 15 заданий раздела 3 (задания по грамматике и лексике). Содержание заданий построены на основе биографических данных жизни и творчества Мадины Маликовой.

Целью данной работы является развитие навыков поискового чтения, совершенствование лексико-грамматических навыков и ознакомление с творчеством писателя.

**Раздел 2 (задание по чтению)**

*Вы проводите информационный поиск в ходе выполнения проектной работы. Определите, в каком из текстов* ***A-F****содержатся ответы на интересующие вас вопросы* ***1-7.*** *Один из вопросов останется без ответа. Занесите ваши ответы в таблицу.*

What main problems does Madina Malikova reveal in her works?

What attracts bookworms in the works of Madina Malikova?

How is the problem of citizenship depicted in the novel “The Red Flower”

Where does Madina Malikova describe the problem of generation gap?

When did she study at the Faculty of History and Philology of Kazan Pedagogical Institute?

What educational establishments did she graduate from?

What periodicals was she connected with?

The name of Madina Malikova became known in Tatar literature half a century ago. Readers loved her lyrical stories, full of sincerity and love of life, action-packed novels that pose moral problems to readers.

She was born on August 5, 1935 in the village of Murtysh-Tamak, Sarmanovsky district of the Tatar Autonomous Soviet Socialist Republic. After graduating from a seven-year school in her native village, she studied at the Menzelinsky Pedagogical College. In this educational institution, village children, often dressed in darned quilted jackets and bast shoes, were tried to educate as true intellectuals. Teachers taught them not only general sciences, but also musical notation, the ability to play musical instruments, and understanding painting. Years of study at the Faculty of History and Philology of Kazan Pedagogical Institute armed her with a deep knowledge of history and the laws of development of society.

As a student, M. Malikova actively collaborated with republican youth newspapers, and then worked for more than twenty years in the editorial office of the Azat Khatyn magazine. She traveled a lot around the country, talked with representatives of different professions. She is a writer, keenly aware of the pulse of time, its tendencies, and moral guidelines.

In the works of Madina Malikova, it is showed a wide panorama of modern life. The main characters of her books are active, enthusiastic, creative people. They are convinced that a person comes to this world to make it better and brighter.

One of the best works of Madina Malikova is the novel "Red Flower". From the first minutes, it attracts readers attention, makes them follow the follow difficult destinies of main characters. While reading the novel, readers think about the problems of the whole society, the country in which young generation live and will live.

The events described in the novel cover the life of two generations: parents, whose youth fell on the so-called "stagnant" years, and their children, who matured in the "dashing 90s". The tragic events that occurred with the older generation left a sad imprint on the characters and fates of their children. In this regard, the problem of the relationship between the human person and society is posed with all acuteness.

In the novel, the problems of citizenship are raised with all acuteness. But still, this is primarily an amazing love story, told with lyricism and penetration. The works of Madina Malikova distinguishes a broad outlook and the ability to write as if using watercolor, depicting the subtlest movements of the human soul.

Запишите в таблицу выбранные цифры под соответствующими буквами.

| Текст | A | B | C | D | E | F |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Вопрос | | | | | | |

**Раздел 3 (задания по грамматике и лексики)**

*Прочитайте приведенный ниже текст. Преобразуйте слова, напечатанные заглавными буквами в конце строк, обозначенных номерами* ***17-25****, так, чтобы они грамматически соответствовали содержанию текста. Заполните пропуски полученными словами. Каждый пропуск соответствует отдельному заданию* ***17-25****.*

| | | |
|---|---|---|
| 17 | Madina Malikova - a journalist, writer. She was born in the Sarmanovsky district of Tatarstan. She graduated from the Menzelinsky Pedagogical College and the ___________and philological faculty of Kazan Pedagogical Institute with honors degree. | HISTORY |
| 18 | The ___________ tales are “Mercy”, “Whirlwind”, “Charm”, “Red Flower”, “Taste of Rye”, novels “Spring Wreaths”, “Lost Treasures”, “Flower Honey”, “I ascended a high mountain”. | POPULAR |

| | | |
|---|---|---|
| 19 | Her plays were staged at the Tatar State ___________Theatre of G. Kamala, Menzelinsky State Tatar Drama Theatre of S. Amutbaev and in the Almetyevsk State Tatar Drama Theatre. | ACADEMY |
| 20 | Madina Malikova is the ______ female novelist in Tatar literature, | ONE |
| 21 | the initiator and ________ of the charity of Kyzyl Ay, thanks to which many people received help and support in «the post-perestroika» years. | FOUND |
| 22 | She is the _______ worker of Culture of the Republic of Tatarstan and Russia, laureate of the Khusain Yamashev Republican Journalism Prize. | HONOR |
| 23 | Her work is characterized by genre ________, including novels, stories and poetic works. | DIVERSE |
| 24 | She talks about _________, about her books, about charity on the pages of the Tatarstan Elite magazine. | SHE |
| 25 | Although it’s wrong to say “it started”, because I ________ gave the media over twenty years. | ACTUAL |

*Прочитайте приведенный ниже текст. Преобразуйте слова, напечатанные заглавными буквами в конце строк, обозначенных номерами* ***26-31****, так, чтобы они грамматически и лексически соответствовали содержанию текста. Заполните пропуски полученными словами. Каждый пропуск соответствует отдельному заданию* ***26-31****.*

| | | |
|---|---|---|
| 26 | My first stories and stories __________ in the Azat Khatyn magazine. | PUBLISH |
| 27 | But I really wanted to write a novel, especially since among the Tatar women they _________ in a similar genre. | NOT/WORK |
| 28 | And in material terms in Soviet times, one ________ get a good reward for it. | CAN |
| 29 | Today, this ________at all a profitable genre for authors, disproportionate to the time and effort spent. | NOT/BE |
| 30 | “Tatknigoizdat” ________for it about 100 thousand, and then if we are talking about a really large volume of work. | PAY |
| 31 | My first novel “Mercy” _________in 1983 and is still in popular demand, it is included in the school curriculum (for Tatar schools) along with another work “Flower Honey | WRITE |

Ответы к заданиям:

9

| Текст | A | B | C | D | E | F |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Вопрос | 2 | 6 | 7 | 1 | 4 | 3 |

17 historical18 mostpopular19 academic20 first21 founder22 honored23 diversity
24 herself25 actually26 werepublished27 didnotwork28 could29 isnot30 pays31 waswritten

## «ЕГЕТЛЕККӘ БЕР АДЫМ » ИҖАДИ ПРОЕКТЫ

Нәҗметдинова Чулпан Мөнир кызы, Сарман аграр көллияте укытучысы

Проект эше ике юнәлешкә бүлеп башкарылды: беренчесе, әдәби әсәрләрдән эзләнүләр булса, икенчесе, чынбарлыктан, тормыштан алынган вакыйгалар белән бәйле булырга тиеш. Студентларны да, үз теләкләре буенча төркемнәргә бүлдек, һәм проект эшенең түбәндәге планын төзедек.

| | |
|---|---|
| Проект эше | Егетлеккә бер адым... |
| Проектның җитәкчесе | Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Нәҗметдинова Чулпан Мөнир кызы |
| Катнашучылар | Сарман аграр көллиятенең 2 курс студентлары |
| Проектның максаты | Җәмгыять ничек кенә үзгәрмәсен, кеше яхшы белән начарны, ак белән караны, бөеклек белән түбәнлекне аерырга, ата-анага булган хөрмәт-мәхәббәтне аңлап үсәргә тиеш. Чөнки бәхетле тормышны безгә үзебезгә төзергә туры киләчәк. Нинди генә сынаулар алдында калганда да чын ир булып калырга кирәклеген онытмаска, булган хаталарны төзәтә белергә кирәклеген аңларга. Студентларны мөстәкыйль эш йөртүгә һәм активлыкка чакыру өчен, яхшылык эшләүче, күңелләрендә изгелек йөртүче кешеләрнең күбрәк икәнен, өлкән буын белән яшь буын арасын якынайту. |
| Проектның актуальлеге | Олыны олы, кечене кече итә белмәгән бу катлаулы дөньяда, кешеләрнең яхшылык эшләргә омтылып кына торучы, өлкәннәргә хөрмәт белән караучылрның күплеген күрсәтү; кешелекнең алай ук аяныч хәлдә түгеллеген исбатлау; дөньяга күңел күзе аша карасаң, бар матурлыгын бар матурлыгын күрә алуны дәлилләү – хәзерге буынга бик кирәк. Кешеләргә яхшылык эшләргә омтылу – бүгенге көндә иң актуаль мәсьәләләрнең берсе булып тора. |
| Проектның бурычлары | - укучыларда татар әдәбиятына, халык авыз иҗатына карата мәхәббәт тәрбияләү, аларның тәрбияви кыймматенең зурлыгын аңларга ярдәм итү;<br>- аерым төркемнәрдә эшләү күнекмәләрен булдыру;<br>- эзләнү-тикшерү эшләре алып барырга өйрәнү;<br>- яшь буынны үткәнебез белән кызыксындыру;<br>- туган җир мәсьәләсе, аның кеше тормышында зур урын алуын аңлату;<br>- ата-ана хакын аңлау;<br>- изге гамәлләрнең җирдә ятмаганын исбатла;<br>- халкыбызның гореф-гадәтләре турында күзаллау булдыру. |
| Проекттан көтелгән нәтиҗәләр | • студентларның активлыкка, мөстәкыйль фикер йөртүгә, акыл эшчәнлегенә һәм рухи эшчәнлеккә өйрәнүләре<br>• төркемнәрдә эшләүнең уңай һәм тискәре якларын ачыклаулары<br>• һәр төркемгә бирелгән эшләрнең төгәл башкарылуы<br>• әзерләп килгән материалларны дөрес итеп куллану<br>• үз фикерләреңне мөстәкыйль дәлилли белүләре<br>• барлык материалларны кулланып иҗади конференция оештыру<br>• куелган максат һәм бурычларга уңышлы ирешү |

| | |
|---|---|
| Көтелгән нәтиҗәләрне чынга ашыру шартлары | - Студентларның актив булулары<br>- Төркемнәрне дөрес итеп оештыру<br>- Аерым төркемнәргә бурычларны куя белү<br>- Өлкән буын кешеләре белән якынаю<br>- Авыл һәм районыбыз китапханәчеләренең ярдәме<br>- Техник җайланмалар белән тәэмин ителү |
| Проектны чынга ашыру сроклары | **I этап -әзерлек этабы**(гыйнвар – март)<br>*Укытучы эшчәнлеге:*<br>Әлеге проектны чынга ашыру планы<br>Укучыларны дөрес итеп төркемнәргә бүлү, иҗади биремнәр бирү<br>Кулланылачак әдәбият исемлеген төзү һәм укучыларны таныштыру<br>Китапханә хезмәткәрләре белән сөйләшү<br>*Студентлар эшчәнлеге:*<br>Иҗади-тикшеренү эше.Фәнни-тикшеренү эше<br>**II этап – төп этап**(апрель)<br>- җыелган материалларны дөрес итеп төркемнәргә бүлү, тикшерү<br>һәр төркемгә бирелгән эшләрнең төгәл башкарылуын тикшерү, ачыклау; язмаларны уку, иң уңышлыларын ачыклау; иҗади кичә үткәрү<br>**III этап – йомгаклау**(май)<br>Эшләнгән эшләрне йомгаклап конференция үткәрү<br>Проектны чынга ашыруда зур өлеш кертүчеләргә рәхмәт хатлары җиткерү. Җиңүчеләрне һәм актив студентларны диплом һәм грамоталар белән бүләкләү |

## ГАИЛӘ ТӘРБИЯСЕ АЛЫШТЫРГЫСЫЗ

(Методик берләшмә утырышы өчен чыгыш)

Нуриева Миләүшә Вәгыйз кызы,
Җәлил бистәсенең 5нче "Әкият" балалар бакчасы тәрбиячесе,
Сарман районы

Әдәбиятта тәрбия темасына язылган әсәрләр аз түгел. Аларны укып, кеше үзен-үзе дә тәрбияли ала, аларны дәрес, занятиеләр вакытында, җыелышларда файдаланып, укытучы, тәрбиячеләр балаларга, ата-аналарга киңәш бирә алалар, мисал итеп кулланалар.

Мәдинә Маликованың «Оҗмах балалары» әсәре әнә шундый әсәрләрнең берсе. Ул республикабызның Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә дә, К.Тинчурин театрында да, Әлмәт, Минзәлә театры сәхнәләрендә дә уйналды, үзешчән артистлар тарафыннан да яратып кабул ителде. Әсәрдә бик җитди проблемалар күтәрелә, башкача була да алмый, чөнки театр – бүгенге көннең рухы, бүгенге көннең көзгесе ул. Ә бүгенгебез артык куандырырлык түгел. Бу спектакль хыял дөньясына да алып керә керүен, анда җиһан, космос бар. Тик проблемалар Җирдәге һәм алар чишелеш көтә. Болар: ата-ана һәм бала мөнәсәбәте, гаилә һәм тәрбия мәсьәләләре. Әсәрдә ерак-ераклардагы Бәхтия планетасыннан җирдәгеләргә ярдәмгә очып килгән кыз Гөлнур һәм робот Эшбикә бик тә җайсыз хәлләргә юлыгалар, кешеләр арасында торган саен көчәя барган тупаслыкка, шәфкатьсезлеккә, инструкцияләр буенча яшәүгә корылган тормышка тап булалар.

Әсәрне укыгач, бер нәрсәгә инанасың, коллектив тәрбия гаилә тәрбиясен алыштыра алмый. Бала әти-әни кочагында тәрбияләнергә тиеш. Шулай булмаса, ул бәргәләнә, югалып кала, бәхетсез була. Әсәрдә андый берничә бала образы бирелә: Дездемона, Фингал.

Дездемона әнисеннән аерым яшәүне үзенчә кичерә, аның җаны өзгәләнә. Фингал исерек ата белән үсә. Аның тәртибе бозыла башлаган, ләкин әле ул кешелеген җуймаган. Исемнәрен генә карагыз әле сез. Автор безнең колакка ят исемнәр биреп, бу эшләр безнең халык өчен ят, ди. Уяныргa, уйланырга чакыра.

Балалар йортлары заманында ятимнәр өчен төзелгән, ә бүген анда әти-әниләре исән-сау булган балалар тәрбияләнә. Нәкъ менә шундый балаларны башка гаиләләргә тәрбиягә бирәләр. Газеталарда, телевизор экраннарында андыйларның үлеме турыда әледән-әле куркыныч хәбәрләр күренә. Менә монысы аеруча куркыныч. Балалар йортларына китерелгәннәр арасында вокзал-аэропортларда, бала табу йортларында, подъездларда калдырылган балалар бар.

Әсәрдәге тәрбиячеләрнең бирелеше дә безнең файдага түгел. Мәгърифә (ләкин ул үзен Марья Михайловна дип атауларын таләп итә итүен) формализмга корылган, инструкцияләр белән яшәгән система вәкиле. Андыйлар баланың күңелен җәрәхәтләп кенә калмыйлар, аны тупас, имансыз, кешелексез итеп тәрбиялиләр. Эшбикәне аңлап була, ул – робот. Ә бу кеше бит ләбаса.  Ул роботның ”тимер тәртип” урнаштыруын, шуның белән балаларны рухи изеп яшәвен хуплый, аңа ул ошый.

Тик начарлык булган җирдә яхшылык бар. Әсәрдәге Гөлнур белән милиционер Тәүфикъ – шундый образлар. Гөлнуры һәрнәрсәне яхшылыкка корырга кирәк, баланы үз әти-әнисе тәрбияләргә тиеш, алар бергә яшәргә тиеш дигән фикер белән яши. Икенчесе нечкә күңелле, эшенә җаваплы каравы, мәхәббәте белән аерылып тора. Хәтта бераз гаҗәбрәк тә. Гадәттә, милиционер образын без катгый, шәфкатьсез итеп күреп ияләнгән бит.

Әсәрдә безне уйландырырга тиешле әйберләр: бала ата-анасыз була алмаган кебек, ата-ана тәрбиясеннән башка шәхес булып өлгерә алмый. Кешене кеше иткән, табигатьнең бөек заты иткән сыйфатларны – итагатьлелек, миһербанлылык, туганлык мөнәсәбәтләрен изге итеп карауны гаилә генә тиешенчә тәрбияли ала. Шуңа да Эшбикә кебек роботлар тәрбиядән ерак торырга тиеш.

Теләгем шул: бу әсәр белән һәр мөгаллим, тәрбияче танышсын, ата-аналарга тәкъдим итсен, өстәл китабы итсен иде.

**Кулланылган әдәбият:**

1.Маликова М.Г. Алтын ятьмә / М.Г.Маликова.- Казан: Матбугат йорты нәшрияты., 2001.

2. Мәйдан / әдәби-нәфис, иҗтимагый журнал., июль, 2004 ел.

## МӘДИНӘ МАЛИКОВАНЫҢ “ЧӘЧКӘ БАЛЫ” ПОВЕСТЕНДА ТЕМА, ИДЕЯЛӘР ДӨНЬЯСЫ, ПСИХОЛОГИЗМ БИРЕЛЕШЕ: ТРАДИЦИЯЛӘР ҺӘМ ЯҢАЧАЛЫК

Нуртдинова  Раушания Равил кызы, Калимуллина Әлфия Нәҗиб кызы,
А.Тимергалин исемендәге Иске Минзәләбаш төп гомуми белем бирү мәктәбе,
Сарман районы

**Проектның максаты:** М. Маликованың «Чәчкә балы» повестенда җиткерергә теләгән төп фикерне һәм төшенчәләрне ачыклауны, психологизм бирелешен тикшереп, китап укучылар конференциясе үткәрү.

**Проектның бурычлары:** Повестьтагы вакыйгалар эзлеклелеген, гомуми барыш һәм хәрәкәт схемасын тикшерү, конфликтны билгеләү. Әсәр нигезенә салынган вакыйгаларны, кешеләр арасындагы һәм кеше белән җәмгыять арасындагы мөнәсәбәтләрне тикшереп, «Чәчкә балы» повестеның тематикасын ачыклау, тема һәм проблемаларның идеяләр дөньясындагы чагылышын күзәтү. Повестьта образның рухи дөньясын, ягъни психологиясен нинди үзенчәлекле чаралар, алымнар ярдәмендә сурәтләнүен анализлау. Әдәби әсәрне тикшерү нәтиҗәләре буенча, китап укучылар конференциясе уздыру.

**Проектның реализация вакыты:** 2019-2020нче уку елы.

**Проектны тормышка ашыру этаплары**

| № | Эш төре | Үткәрү урыны | Үткәрү вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|---|
| **Әзерлек этабы** | | | | |
| 1. | Тема буенча материал туплау | мәктәп | Сентябрьнең беренче атнасы | татар теле һәм әдәбияты укытучылары,китапханәчеләр |
| 2. | Чыганаклар белән эшләү | мәктәп | Сентябрьнең икенче атнасы | татар теле һәм әдәбияты укытучылары,китапханәчеләр |
| 3. | Укучылар өчен консультацияләр үткәрү | мәктәп | Сентябрь - февраль | татар теле һәм әдәбияты укытучылары,китапханәчеләр |
| 4. | План төзү | мәктәп | Сентябрьнең беренче атнасы | татар теле һәм әдәбияты укытучылары,китапханәчеләр |
| **Төп этап** | | | | |
| 5. | Фәнни хезмәтләрне уку, анализлау | Мөстәкыйль рәвештә | Сентябрь-октябрь | 8-9 сыйныф укучылары |
| 6. | Тиешле урыннарны билгеләп бару, аларны язып алу | Мөстәкыйль рәвештә | Ноябрь-декабрь | 8-9 сыйныф укучылары |
| 7. | Нәтиҗәләр чыгару | Мөстәкыйль рәвештә | гыйнвар | 8-9 сыйныф укучылары |
| 8. | Чыгыш әзерләү, презентация ясау, рәсем, плакатлар конкурсы оештыру | Укытучы белән берлектә | февраль | Укытучы,<br>8-9 сыйныф укучылары |
| 9. | Укучылар өчен китап укучылар конференциясе үткәрү | Мәктәпнең актлар залы | февраль | Укытучы,<br>8-9 сыйныф укучылары,<br>китапханәчеләр |
| **Йомгаклау этабы** | | | | |
| 10. | Мәкалә язып, “Сарман” газетасында бастыру | | февраль | |

## Йомгаклау

М. Маликованың «Чәчкә балы» повестен тикшереп, анализлап, югарыда алынган максатларны чишеп, түбәндәге нәтиҗәләргә килдек: повестьта төп сюжет сызыгы акыл һәм хис каршылыгына нигезләнеп хәрәкәт итә. Повестьтагы тема ике аспекттан тора: конкрет-тарихи һәм гомумкешелек кыйммәте. Конкрет-тарихи аспект традицион сурәтләнгән. Ул – хәзерге заманда хатын-кызның иҗтимагый урынын билгеләү темасы. Гомумкешелек кыйммәтен чагылдыручы мәңгелек тема – мәхәббәт, бала тәрбияләү. Идеалга омтылучы геройлары романдагы тема – проблематикага яңалык өсти.

Әсәрнең үзегендә җәмгыятебездә булган төп проблема – наркомания, эчкечелек. Безгә газета-журналлардан, интернеттан эчкечелек һәм наркоманияне дәвалау турында эзләнү бик күп куанычлы нәтиҗәләр чыгарырга ярдәм итте.

Подольск табиблары беренче булып апитерапия ысулын, ягъни бал һәм умарта корты белән дәвалауны сынап караганнар. Моның өчен махсус схемалар һәм таблицалар эшләнгән, бал кортларын чактыру өчен махсус зоналар сайланган. Диспансерның тернәкләндерү бүлегенең башка процедуралары белән бергә, метод үзенең нәтиҗәлелеген исбатлаган: ун пациентның өчесе сәламәтләнә икән. Бал кортлары наркоманияне дәвалый. Элеккеге наркоман гадәти бал кортлары ярдәмендә начар гадәтләрдән арынган. Ул «дарулар»ның

тәэсирен үзендә тикшерергә булган. Кыргый умарта кортлары ояларын эзләп табып, ул анда даими рәвештә бара башлый. Ике ел да үтмәгән, наркоман бәйлелектән тулысынча котылган һәм хәтта яңа белгечлек алган. Хәзер ул умартачы булып эшли икән.

Сарман халкы – ачык, киң күңелле, талантлы, җырга-моңга оста, ярдәмчел һәм эшчән халык. Һәр районның үзенә генә хас, кабатланмас, истәлекле урыннары, горурланырлык күренекле шәхесләре бар. Якташыбыз Мәдинә Маликова дә – хәзерге көннәрдә илһамланып иҗат итүче татар язучыларының берсе. Ул – Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, Хөсәен Ямашев исемендәге республика бүләге лауреаты, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, хикәяче, романчы, драматург, публицист, җәмәгать эшлеклесе. Без аның иҗатын югары бәялибез, яратабыз, аның белән горурланабыз, үзен бик хөрмәт итәбез.

**Проектның эффективлык индикаторлары һәм критерияләре(диагностика методы)**

1. Бу әсәрне анализлаганнан соң, укучыларның белем дәрәҗәсен контроль эш яки контроль тест ярдәмендә тикшерү
2. Уку елы азагында укучыларның тәрбиялелек дәрәҗәсен тикшерү.

**Кулланылган әдәбият:**


1. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007.
2. Заһидуллина, Д.Ф., Әдәби әсәргә анализ ясау/ Д.Ф. Заһидуллина, М.И.Ибраһимов. – Казан, Мәгариф, 2005.
3. Маликова Мәдинә. Югалган якутлар: Повестлар,пьесалар. – Казан: “Рухият” нәшрияты, 2004.


## КӨНДӘШЛӘР

(сәхнәләштерелгән хикәя)


Рахимова Гөлүзә Әзһәм кызы,
Саклау-Баш урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы


I пәрдә

Авылның атлар асырый торган добыры (диаль. дворы). Малайлар атларны әйләндереп алган киртәләргә якын ук килеп, Заһир абыйларының атларны чистартканын, ашатканын күзәтәләр. Заһир абый капчыктагы солыны чиләккә сала һәм ачык ишектән эчкә кереп китә. Малайлар үзара сөйләшәләр.

**Берсе**. Әй малайлар, ишеттегезме соң, узган кыш ак айгыр чанасы-ние, чанадагы председателе белән бергә тимер юл шлагбаумы аркылы сикереп чыккан...

**Икенчесе** . И-и-и анысы пүчтәк, язын ул җимерелеп барган күпер аша очып үткән...

**Өченчесе**. Җиргә карап йөри белми инде ул тулпар, йолдыз санап кына йөри инде. Озын, сөякчел башын бары тик Заһир абыйның иңенә аның шыпырт тавыш белән назлап дәшкәнен ишетер өчен генә ия инде ул...(Заһир абый ат абзарыннан чыга, малайларга якын килә)

**Заһир абый**. Барыгыд, бар, өйләрегедгә кайтыгыд, аналарыгыдны аптыратмагыд. (Заһир абый абзар кырындагы ачык торган келәтенә таба китә. Ачык ишектән аның эш кораллары күренеп тора: сбруйлар, челтәрле кәрнизләр, балта-пычкылар һ.б.ш.)

**Беренчесе**. Их, малайлар, Заһир абый кебек булсаң икән! Аның кебек ак айгырга атланып, Тарагыш урамнарын дер селкетеп чабып узарга иде!..

**Икенчесе**. Их, Заһир абый тирә-юньдә дан тоткан балта остасы да бит! Күрәсезме келәт янында эленеп торган сбруйларны, тәрәзә рамнарын,кәрнизләрне... Барысын да үзе ясый бит! (Заһир абый кулына чүкеч алып, нидер каккаларга керешә, үз алдына моңлана)

Агыйдел сулары кебек
Тар сулар булмас инде.

Минем йөрәккәем кебек
Ярсулар булмас инде.

(Бераздан җыр өзелә. Заһир абый, карашын малайлар өстенннән уздырып, еракка төбәп карап тора башлый.Әйтерсең бик кадерле нәрсә күрә.)

**Өченчесе**. Урманның чикләвеге, җиләге беткән, Агыйделдә коеныр чак үткән... Ни күрә икән анда Заһир абый?! (Малайлар гәүдәләрен бормыйча гына, башларын борып, Заһир абый караган якка төбәләләр.)

Заһир абый шактый карап торганнан соң малайлар арасыннан Давытны күреп ала.

**Заһир абый.** Әле сед һаман мондамыни? Давыт, син дә мондамы? Кер әле, кер...(Давыт керергә кузгала, аңа башка малайлар да кушылырга уйлыйлар)

**Заһир абый.** Ә седне кем чакырды? Барыгыд, барыгыд өйләрегедгә кайтыгыд. (Малайлар борылып китәргә мәҗбүр булалар).

**Заһир абый.** Миңа әнә теге пычкыны гына алып бир әле.(Давыт пычкыны алып бирә.)

**Давыт.** Заһир абый, кирәк булганда мин такта башы да тотып тора алам. Кушасың икән, атларга башак та болгатам. (Сөйләшә-сөйләшә кереп китәләр.)

II пәрдә

Кичке уенга җыелган кызлар, егетләр.Үсмер малайлар качып кына клубка керергә тырышалар. Уен гөрли. ”Ат эчертеш” уены уйнала. Клубка кергән Давыт кызлар тирәсендә тыңланып йөри. Монда Әкълимә апа да бар. Кисәк кенә Заһир абый килеп керә. Кызлар аңа таба борылып карап, нидер әйтешеп,шаулашып алалар.

**Кызларның берсе.** Ут кечерәйдеме әллә дип торам, кара чутыр кереп караңгылаткан икән!

**Кызларның икенчесе**. Ну хәзер кәкре аягы белән тып итеп бер басса, идән сайгаклары бөгелеп төшә инде! (Заһир шул арада чыгып та китә.)

**Әкълимә апа**.Заһир – чын егет ул ! Аяклары да чын егетләрчә атта йөрергә күнеккән баһадир аягы!

**Өченче кыз.** Кара, кара яклаган була, әллә кара чутыр синең йөрәгеңә утлы кисәү салдымы?

**Беренчесе**. Белмисеңмени әле Әкълимә артыннан Богады егете Әхнәф йөри ич! Әнә әле дә Әкълимәне гел күзәтеп, сәхнә читендә басып тора.

**Әкълимә апа.** Кара әле, Давыт акыллым, минем янымнан китмә әле син. Бергә кайтырбыз өйгә.

**Давыт.** Ярый, Әкълимә апа.(Давыт читкәрәк китеп бара, аның янына Әхнәф килә.)

**Әхнәф.** (Давытны төрткәләп). Бар,бар, балаларга күптән йокларга вакыт...

**Давыт.** Мин Әкълимә апаны көтәм. (Әхнәфтән качып, кызларның әле бер ягына, әле икенче ягына чыга).

Уен тарала. Өйләргә юнәләләр.

III пәрдә

Ат двоеы(диаль.) тирәсендә Заһир абый белән Давыт гаплэшәләр.

**Давыт.** Заһир абый, кичә ничек итсәм иттем, Әкълимә апаны Әхнәф абыйга озата килергә ирек бирмәдем.

**Заһир.** Җиткән егет инде син, Давыт. (Җилкәсеннән кагып ала.) Кара әле, Давыт, менә бу конвертны Әкълимә апаңа бирерсең әле. (Үзе читкә карый. Давыт теләр-теләмәс кенә конвертны кулына ала. Заһир абый кереп китә.)

**Давыт.** (Сәхнә алдына килеп.) Дөресен генә әйткәндә, бездә фатирда торган 2-3ай эчендә, тәмам ияләштем мин Әкълимә апага. Мин аның хәтта Заһир абый белән дә дуслашуын теләмим. Әнә армиядәге егетеннән атнасына 2-3 хат килә бит, шул җиткән. Эх, нинди гүзәл ул Әкълимә апа! Әнә тәнәфестә өлкән класс кызлары да аның толымнары турында, шундый толым буламыни, ялгаган ул аны, ялгаган дип гайбәт сатып торалар. Ләкин Әкълимә апаның гүзәллеге толымнарында гына түгел йөзендә, якты карашында, ягымлы сүзендә. Аның белән аралашкач үзеңне яхшы кеше итеп тоясың. Һәммә кешегә яхшылык эшлисе килеп тора. (Кереп китә)

IV пәрдә

Җилкәсенә матур итеп шәл-яулык япкан Әкълимә апа дәфтәр тикшереп утыра. Давыт килеп керә.

**Давыт.**Әкълимә апа, менә сиңа тапшырырга куштылар.

**Әкълимә апа.** (Утырган урыныннан күтәрелеп, конвертны кулына ала. Конвертны әйләндереп-әйләндереп карый. Тышында язу-фәлән юклыкны күреп) Кем бирде моны?

**Давыт.** Кем булсын... Заһир абый...

**Әкълимә апа.** (Конвертны Давытка суза.) Кире үзенә илтеп бир. Йомышы булса, мәктәпкә килсен, шунда сөйләшербез, дип әйтте Әкълимә апа диген.(Давыт конвертны алып басып кала. Әкълимә апа чыгып китә.)

**Давыт.** (Халык алдына килеп) Ни йөзем белән ачылмаган да килеш Заһир абыйга кире илтеп бирермен?(Конвертны кулында әйләндерә) Ни язды икән Заһир абый? (Чүгәләп утырып конвертны ача. Почмаклары бизәкләнгән шакмаклы битне тартып чыгара. Аны ачып, кычкырып укый)

Агыйделнең пароходы,
Еракка җитә уты.
Сине уйламый үтә микән
Сәгатьнең бер минуты?

Атларымны дагаладым,
Дагалары каралтын.
Эх, дускаем, син белмисең,
Эчләрем тулы ялкын.

Сине чиксез хөрмәт итүче З.

**Давыт.** (Укып чыга, шаркылдап көлә.) Җә, ни дип язган инде бу җырны Заһир абый? Әкълимә апа шуларны да  белми дип уйлый микән әллә? Тукта, Давыт, тукта авызыңны ерма! Тикмәгә генә язмаган бит инде Заһир абый боларны! (Йөгереп өйгә кире кереп китә. Әкълимә апаның каршындагы дәфтәр өстенә конвертны янәдән китереп сала).

**Әкълимә апа.** (Ачылган хатны кулына алып укый) Сине чиксез хөрмәт итүче “З”түгел”Д” (кызыл ручка алып сыза) Давыт – “Д” белән языла

**Давыт.** Юк, Әкълимә апа әлеге хат Заһир абыйдан.

**Әкълимә апа.** Син, Давыт, моннан ары болай итмә! Почтальон  китергәннәрен бир миңа, ә мондыйларын берәүдән дә алма, апа кушмый диген! Җиткән егет бит инде син, аңларга тиеш! (Кереп китәләр.)

Ат абзары тирәсе.Заһир абый ат абзарыннан чыгып килә. Давыт башын аска иеп, салмак кына Заһир абыйсы янына килеп баса.

**Заһир абый.** Әкълимә апаң бер-бер сүд әйтмәдеме?

**Давыт.**Әйтмәде.

**Заһир абый.** Хатка җавап бирмәдемени?

**Давыт.** Җавап кирәк идемени?

Янәшә бүкән өстенә килеп утыралар. Камчы үрергә керешәләр.

**Заһир абый.** Салават батырның камчысы шушындый булган. Уфадагы Салават һәйкәлен ишетеп беләсеңме? Аның кулында кылыч түгел, камчы бит! Яхшы камчы үткен кылыч кебек көчле корал ул, чын егет аны кулыннан төшерми, үлгәндә дә дошманга бирми.(Урыныннан кузгала, барып, сөяп куелган рамлы көзгене кулына ала.) Менә моны өегедгә алып кайт, яратсалар, түргә эләрсең. (Давытка бирә.)

**Давыт.** Заһир абый, үзең дә  бер кагылып чык безгә.( Чыгып китәләр.)

V пәрдә.

Өй эче. Давыт кайтып керә. Әнисе өйдә йөри.

**Давыт.** Менә моны Давыт абый биреп җибәрде. Яратсалар, түргә элерләр диде.

**Әнисе Мәрхәбәтәй.** И-и, оста да инде шул Даһир, кулы алтын, күңеле җәүһәр шул егетнең! Карале, улым, җайлап кына әйт әле, тәрәзә яңаклары какшаган, бер килеп рәтләп

китмәс микән? (Һәрберсе үз эше белән шөгыльләнә. Кинәт ишек шакып, кулына тармасы белән эш коралларын тотып, Заһир абый килеп керә.)

**Заһир абый.** Исән-саулар гына торасызмы, Мәрхәбәттәй?! Менә бер кагылып чыгарга булдым әле сезгә.

**Мәрхәбәттәй.** Аллага шөкер, улым Даһир. Үзең исән-имин генәме, улым. Ай, рәхмәт төшкере. Керүең бик әйбәт булган әле, улым. (Шул арадаМәрхәбәттәй Давытка эндәшә.) Давыт, улым, бар әле Нәфыйк чишмәсеннән су китер әле. Әкълимә апаң да озакламас, кайтып керер. (Давыт көянтә-чиләкләрен алып чыгып китә.) И-и, улым Даһир, менә шулай әкренләп кенә яшәп ятабыз инде. Аталары вафатына да 4 ел була. Ир-атсыз тормыш үзен бик сиздерә, әле тегесе, әле монысы ватыла. Һәрнәрсәне рәтләп, карап торсаң гына шул инде...

**Заһир.** Мәрәбәттәй, менә монда бер кадак баш калкыткан әле (аяк астына карап), кая әле каккалап куйыйк әле. (Чүкечен алып, идәнгә бер-ике суккалап ала.)

**Мәрхәбәттәй.** И-и, улым Заһир, кулларың алтын да инде синең, күр инде ничек яхшы итеп ясап куйгансың бит ул көзге рамнарын! Кай арада күреп алдың әле ул чыккан кадакны? (Кисәк кенә ишек шакып, Әкълимә апа да кайтып керә.)

**Әкълимә апа.** Исән-имин генә тордыгызмы, Заһир да монда икән, саумы, Заһир. (Шул арада Мәрхәбәттәй каядыр чыгып китә.Яшьләр үзе генә кала.)

**Заһир.** Исәнме, Әкълимә. (Закир әйберләрен җыя башлый. Барып чиләктән чүмеч белән алып су эчә. Ишеккә юнәлә. Каршысына ишектән Мәрхәбәттәй очрый).

**Мәрхәбәттәй.** Даһир улым, кая болай ашыгасың, чәй кайнап чыкты, язмаганны, ризыктан өстен булып чыгып китмә инде. Әйдә, әйдә кер.

**Заһир.** Рәхмәт, Мәрхәбәттәй, анысы башка вакытта. (Ишеккә кузгала).

**Мәрхәбәттәй.** И-и, кара инде моны. (Заһир чыгып та китә. Әкълимәгә карап). Син дә кыстамадың, әйдә бергәләп чәй эчик дип әйтергә телеңне жәлләдең. Синең бер сүзеңне генә көткән иде ул.

**Әкълимә апа.** Әй, Мәрхәбә апа, бер сүз әйтсәң, әллә нигә өметләнер кеше!

**Мәрхәбәттәй.** Өметләнсә ни! Седнең икегеднең дә яхшыдан яхшыга өметләнер чагыгыд!

**Әкълимә апа.** Минем яраткан кешем бар бит, Мәрхәбә апа, вәгъдә биргән ярым бар.

**Мәрхәбәттәй.** Яшь чакта вәгъдә бирешү дә, ташлашу да гаеп түгел, Яшь чак – яр сайлар чак. Янәшә куеп сайлый башласаң, шул Даһирдан да яхшысы булмас ие әле!

**Әкълимә апа.** Яхшы кешеләр күп ул дөньяда, җан сөйгән яр бер генә! (Җыр суза.)

Агыйделнең пароходы
Җиталмый Кызыл Ярга,
Җиталмый дуслар, җиталмый
Яратып сөйгән ярга.

**Мәрхәбәттәй.** Кара аны, егетнең асылына кул селтәп, Богады Әхнәфенә барып каба күрмә тагы!

**Әкълимә апа.** Ничек башыңа килә, Мәрхәбәттәй! Мескен ул Әхнәф гел чәүкә баласы төсле инде, борыныннан тотсаң, җаны чыгар!

**Мәрхәбәттәй.** Озын борынлы егетләр усал була алар, безнең Даһир ише түгел! (Чыгып китәләр.)

VI пәрдә.

Өй эче. Давыт өйдә. Камчысын үреп бетереп утыра. Мәрхәбәттәй килеп керә.

**Мәрхәбәттәй.** Улым, Давыт, ындыр табагына барып, Әкълимә апаңны чакырып кайт әле.

**Давыт.**Ярар, әнкәй. Мин хәзер, чыбыркымны үреп бетердем менә. (Утырган урыныннан торып басып, чыбыркысын шартлатып карый-карый чыгып китә.)

Сәхнәгә Әкълимә белән Вәкил килеп чыга. Вәкил Әкълимә апасының чәч толымын урап тоткан.

**Вәкил.** Абыем-җаным дип әйт. Берне суырып үбәм дип ант ит! Вәкил-җаный диген.

**Әклимә апа.**Вәкил абый, зинһар, азаплама! (Шул вакыт сәхнәгәДавыт килеп чыга.)

**Давыт.** Җибәр хәзер үк!

**Вәкил.** Яле, җаныем диген әле бер генә!

**Давыт.** Җибәр, хәзер үк диләр сиңа! (Чыбыркысы белән идәнгә берне шартлатып ала.)

**Вәкил.** Хәзер, көчек, сиңа да өлеш чыгар!

Давыт кизәнеп, Вәкилнең беләгенә сыдыра. Вәкил Әкълимә апаны кулыннан җибәреп, Давытка ташлана. Давыт йөгереп чыгып кача. (Барысы да чыгып китәләр.)

VII пәрдә.

Давыт белән Әкълимә апа өйдә.

**Әкълимә апа.** Давыт акыллым, кара әле сиңа әйтәм, олы кешегә кул күтәрергә ярамый инде алай. Әдәпле булырга кирәк. Җиткән егет бит инде син.

**Давыт.** Ә ул миңа көчек дип кычкырса да ярыймы? Кешене мыскыл итсә дә ярыймы?

**Әкълимә апа** (Башын аска иеп) Рәхмәт инде сиңа... Ләкин моннан соң алай итмә. (Чыгып китәләр.)

Сәхнәнең бер ягыннан Давыт, икенче ягыннан Вәкил килеп чыга. Вәкил Давытның уң беләгеннән эләктереп ала.

**Вәкил.** Эләктең бит, малай актыгы! (Давыт камчысын сул кулына күчереп өлгерә. Камчысын болгый, Вәкил саклана.)

**Вәкил.** (Давытка иелеп, мыскыллы тавыш белән) Кайда синең тәти апаң, ә? Тү-тү бит тәти апаң! Толымнары белән урап озаттык без аны! Кияү куенына керә бүген тәти апаң! Ха-ха! (Оятсыз кинәнә, Давыт бар көченә тартылып, аннан ычкынып, өенә йөгерә. Вәкил чыгып китә)

**Давыт.** (Өенә йөгереп керә) Әнкә-ә-й, Әкълимә апа кайда ул?

**Мәрхәбәттәй.** (Коты алынып) Нәрсә булды? Кайтмады әле Әкълимә апаң. Мәктәбендә берәр эше чыккандыр.

**Давыт.** Заһир абый янына чаптым мин, әнкә-ә-й. (Йөгереп чыгып та китә. Заһир абыйсы янына тынына буылып чабып килеп керә.) Заһир абый... Әкълимә апа...Богады Әхнәфе... Урлаганнар...

Заһир абый. Урлаганнар?! Әкълимәне? Ни карап торырга, иярлик Алмачуарны... (Йөгереп чыгып китәләр.)

Заһир абый белән Давыт яңадан сәхнәгә килеп керәләр.Сәхнә кырындарак.

**Заһир абый.** Бар, апа кайда дип сора.(Ишегалдында хатын-кызлар сөйләшеп тора.)

**Берсе.** Әстәгыйфирулла,кем бу?

**Икенчесе.** Әкълимәнең энеседер инде! Апасын сорый бит!

**Беренчесе.** Котны алдың, җүнсед! Күрше өйдә апаң, әнә урам аркылы. Кияүгә хәтле күреп чык.(Кереп китәләр)

Шул арада куллары бәйләнгән Әкълимә апа сәхнәгә чыгып утыра. Башы аска иелеп төшкән. Башында яулыгы юк. Мышкылдый. Давыт белән Заһир сәхнәнең бер башыннан йөгереп кереп китәләр. Сәхнәнең икенче башыннан йөгереп чыгалар.

**Заһир абый.** Әкълимә, без сине коткарырга килдек. (Йөгереп килеп бауларын сүтәләр.) Тизрәк булыйк! Кузгалдык! (Сәхнәнең бер башыннан кереп китәләр, икенче башыннан чыгалар. )

Бер-бер артлы сәхнәгә килеп керәләр.

**Заһир абый.** Мәрхәбәттәй, исән-сау килеш кабул итеп ал Әкълимәне.

**Мәрхәбәттәй.** Рәхмәт яусын инде сиңа, Даһир улым. Әйдә тидрәк өйгә керегед, самавыр кайнаган! (Кереп китә.)

**Заһир абый.** Рәхмәт, Мәрхәбәттәй.

**Әкълимә апа.** Рәхмәт яусын инде сиңа. Мин синең яхшылыгыңны кайтара алмам инде. Әҗерен башкалардан күрергә язсын.

**Заһи абый.** Күңелең кушканны эшлә, Әкълимә, күңелең кушканны.

VIII пәрдә

Авыл урамында бер төркем хатын-кызлар сөйләшеп торалар. Иңнәрендә көянтә-чиләкләр. Давыт шулай ук хатын-кызларны үтеп, көянтә-чиләк асып, су юлы буйлап төшеп китә.

**Берсе.** Әкълимәне урлаган егетләрне Давыт юлда ук куып тоткан. Әхнәфне камчы белән ярып, Әкълимәне шунда ук тартып алган икән...

**Икенчесе.** Булыр, булыр теге чакта ындыр табагында Әкълимәне яклап, Вәкилне дә эт урынына кискән ие бит ул.

**Өченчесе.** Ай-яй, башкисәр ул Мәрхәбәнең малае. (Көянтә-чиләкләрен асып, кайтыр юлларына кузгалалар.Кереп китәләр.)

Давыт көянтә-чиләкләр белән судан кайтып килә. Каршысына велосипедка атланган, солдат киеменнән ят бер егет килә.

**Солдат егет.** Саумы, энекәш, укытучы Әкълимәнең фатиры кайсысы икән? (Давыт ияге белән үзләренең өйләренә ымлый. Солдат егет велосипедыннан төшә). Син дә шушы өйгә керәсеңме әллә?(Давыт баш кага.) Эх! Бәхетем миннән алда керсен әле! Үт-үт, энекәш. Тулы чиләк күтәргән кеше очраса, юлың уң була, әллә ишеткәнең юкмы? Димәк, син минем бәхетне күтәргәнсең.

**Давыт.** Әкълимә апа мәктәптә.

**Солдат егет.** Бигрәк әйбәт, ул кайтканчы юл тузанын кагып, адәм рәтенә кереп торырбыз. Син миңа 1-2 чүмеч су бирерсең бит? (Ишегалдына керәләр. Солдат гимнастеркаларын сала. Давыт чиләкләрен җиргә куя. Эленеп торган сөлгене җилкәсенә ташлый.Чүмеч алып килеп, солдатның кулына су сала. Солдат битен-кулын юа. Азакта Давытның җилкәсеннән сөлгене алып сөртенә).

**Солдат егет**. Рәхмәт яусын, менә хәзер Әкълимә апаңны каршыласак та була!(Солдат төзәтенеп беткәч, өй эченә керәләр.) Исән-сау гына яшәп ятасызмы?

Өйдә Мәрхәбәттәй һәм Заһир абый.

Заһир абый да өй эчендә кадак-чүкеч тотып, нидер төзәтеп йөри.Ул эшләгән җиреннән күтәрелеп-басып, шактый гына солдат егет белән күзгә-күз карашып басып торганнан соң солдат каршысына килеп кул бирә.

**Мәрхәбәттәй.** (Өстәл тирәсендә кайнашкан җиреннән туктап кала) Аллага шөкер, улым, Аллага шөкер, исән-сау гына. Үзең исән-имин генәме, улым? (Ике куллап күрешәләр.) Әйдәгез әле, утырышыгыз әле. Хәзер, хәзер улым Давыт алып кайткан чишмә суы белән чәй куеп җибәрәм самаварыма.

Егетләр икесе янәшә утыралар.

**Заһир абый.** Исән-сау гына солдат хезмәтен тәгәлләдең, болай булгач.

**Солдат егет.** Менә кайтып киләм. Үзең соң кайларда хезмәт иттең?

**Заһир абый.** Себер якларында...

Шул арада Давыт кулына чыбыркы тотып, сәхнә алдына килеп баса. Чыбыркысын чалбар балагына суккалый.

**Давыт.** Авыл егетләре арасында мондый очрашуларның ничек тәмамлануын ишеткән дә, күргән дә бар инде анысы... Алай-болай сугыш купса, кемне якларга? Кайсысына камчы белән сугарга? Заһир абыйга каршы бару мөмкин түгел, ләкин солдатны да рәнҗетәсе килми...(Чыгып китә.)

Өйгә Әкълимә апа кайтып керә.

**Әкълимә апа.** Исәннәрмесез. (Баскан җирендә туктап кала. Егетләр икесе дә урыннарыннан сикереп торалар. Карашлары белән аңа төбәләләр. Әкълимә апа карашын бары солдат егеткә төби. Шушы хәлдә шактый басып торалар. Заһир урыныннан кузгалып, эш кораллары тартмасын кулына алып, чыгу юлына юнәлә).

**Заһир абый.** Сау булыгыз.

Әкълимә апа белән Солдат егет бер-берсенә якын килеп, куллардан алышалар.

**Солдат егет.** Исәнме, Әкълимәм.

**Әкълимә апа.** Исәнме, сөйгәнем.

**Солдат егет.** Көттең, димәк.

**Әкълимә апа.** Көттем, сөекле-е-ем.(Җитәкләшеп чыгып китәләр.)

Сәхнәгә Солдат егет велосипедын җитәкләп килеп керә.

**Солдат егет.** Инде безгә кузгалырга да вакыттыр.

Әкълимә белән Мәрхәбәттәй сәхнәгә сөйләшә-сөйләшә килеп керәләр

**Әкълимә.** Мәрхәбәттәй, кылган изгелекләрегез өчен бик зур рәхмәт инде сезгә.(Сәхнәгә Давыт та чыгып килә.) Давыт, акыллым, сиңа да рәхмәтемнең чиксезе. Исән-имин генә торыгыз, әле тагын күрешербез.

**Солдат егет.** Давыт, хушлашыйк инде, үскәнем. (Кул бирешеп саубуллашалар) Мәрхәбәттәй, бик зур рәхмәт инде сезгә, исән-сау булып торыгыз.(Аркаларыннан кагып хушлашалар)

Әкълимә апаны солдат егет велосипедына утыртып чыгып китәләр.

**Мәрхәбәттәй.** Исән–сау булыгыз, балалар, исән йөрегез. И-и-и бигрәкләр дә пар килгәннәр икән шу-у-у-ул.

**Давыт.** Әгәр миннән матурлык һәм ярату турында нинди була дип сорасалар, мин матурлык Әкълимә апа төсле була, ярату – Заһир абый кебек була дияр идем, эх! (Чыгып китә.)

## СҮЗ ЭЧЕНДӘ ЭНҖЕ БАР

Рәшитова Нәзифә Мөхлисулла кызы, филология фәннәре кандидаты
20 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Әлмәт шәһәре

Мәдинә Маликова үзенең «Көндәшләр» исемле хикәясендә халкыбыз тормышының һәр ягына игътибар итә, аның бөтен нечкәлекләренә тирән үтеп кереп, укучы күңеленә тәэсир итәрлек, язучыны олы максатына якыынайтырлык итеп, әсәр тукымасына кертеп урнаштыра. Хикәясендә кеше һәм табигать бердәмлегенраслап торучы борын-борыннан килгән йолалар да, халкыбыз тормышында аерым урын алып торган атка карата җылылык та һәм кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрендәге әхлак кануннары да урын алган. Ачык буяуларга буялып, төрле бизәкләргә төрелеп тасвирланган йола мотивлары (бүләк бирү, хат язу, чиккән сөлге, вәгъдә бирешү) автор иҗатының сәнгатьчә эшләнешенә дә, миллилегенә дә, халыкчанлыгына да ишарә ясап тора. М. Маликова күркәм гадәтләребезне геройларының тормышы, язмышы белән үреп бирә. Хикәядә алар тормышның һәр ягын күзәтеп, яшәргә өйрәнүче, тәҗрибә туплаучы ихлас күңелле Давыт хикәләвендә яктыртылалар. Болар һәммәсе милли характерыбызны ачуга хезмәт итәләр.(”Егет кеше үлгәндә дә коралны кулыннан төшерми”). Халык авыз иҗатын хикәясендә поэтик бизәк итеп сайлаган М.Маликова, әлбәттә, аның этнографиясен дә читләтеп үтми.(..”сырлар белән бизәлгән капка”, “челтәрле кәрнизләр”, “чүпләмле сөлге”). Әсәр тукымасына сеңдерелгән поэтик чараларның һәр төре үз вазыйфасын уңышлы үти. Һәркемгә билгеле, әдәби әсәрдә төп материал - тел байлыгы, сүз.

“Сүз эчендә энҗе бар”,- ди халык. Бу мәкаль сүзнең тышкы ялтыравыклыгын гына түгел, нәкъ менә сүзнең мәгънәсенә, аның эчке мөмкинлекләренә игътибар кирәклеген искәртә. Сүзнең шул хасиятләрен искә алып эш итүче иҗат әһеле генә җанга үтеп керерлек, күңелдә калырлык әсәрләр тудыра ала. Ә хикәядәге халык авыз иҗатының кыйммәтле үрнәкләре авторның хикәяләү осталыгын баетып, тулыландырып торалар.(“Кулы алтын-күңеле җәүһәр шул егетнең”)

М.Маликованың «Көндәшләр» дип исемләнгән хикәясе – татар халкының акылын, әхлагын, яшәешен югары дәрәҗәдә күрсәткән сәнгать әсәре булып тора.

## ТУГАН ЯК БУЙЛАП ВИРТУАЛЬ ЭКСКУРСИЯ

Ризатдинова Эльвира Хәниф кызы, Вахитова Люция Мансур кызы,
икенче санлы Җәлил урта мәктәбенең башлангыч сыйныфлар укытучылары,
Сарман районы

**Максат:** укучыларның туган як турындагы белемнәрен баету, системалаштыру

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран, презентация, җыр язмалары, Сарман районы картасы, биштәр, район турында видеофильм, авыл турында видеоролик, герб рәсеме.

**Дәрес барышы:**

I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру этапы

Актуальлаштерү.

- Укучылар, минем хәзер сезгә бер җыр тыңлатасым килә. Сез тыңлагыз, җыр тәмамлангач, минем ни өчен бу җырны сайлавымны әйтеп карарсыз. Килештекме? (“Сарман” көен тыңлау, куелган сорауга җавап бирү).

- Булдырдыгыз, укучылар. Хәзер минем сезгә менә бу рәсемне күрсәтәсем килә. (Районның гербы рәсеме күрсәтелә). Менә шушы рәсем буенча куелган сорауларга җавап биреп, кроссвордны чишәбез.

1. Рәсемдә нинди кош рәсеме ясалган? (Сандугач)

2. Башак турында сары дип, тагын нинди дип әйтеп була? (Алтын). Без аны ике тапкыр язабыз.

3. Рәсем төгәлләнгән.Моны нәрсә күрсәтә? (Рамка)

4. Укучылар, мин сезгә хәзер менә бу кошчыкның җырын ишеттерәм. Аның сайравы турында ни диярсез? (Матур)

5. Кара фонтан рәсеме нәрсәне аңлата? (Нефть)

- Кроссвордыбыз тәмам булды. Районыбыз гербы безгә нинди сүзне табарга ярдәм итте икән? (САРМАН).

- Бу атама безнең өчен ник кадерле? Районыбыз турында видеофильм карап алыйк.

II. Уку мәсьәләсен кую.

- Укучылар, минем кулымда юл биштәре (рюкзак). Мондый биштәр безгә кайчан кирәк була?

- Дөрес, минем сезне юлга чакырасым килә. Тиз генә әйтегез әле, юлга чыкканда нәрсәләр алабыз?

- Ә юлда адашмас өченниләр кирәк?

- Бүген компас алып тормыйбыз. Ә менә карта кирәк. Карта булды, биштәр бар. Ничек уйлыйсыз, безгә нинди маршрут буенча юлга чыгарга кирәк?

- Туган як буйлап сәяхәт итү нәрсә бирә?

- Туган як тарихын, аның атаклы кешеләрен белү бик кирәк, укучылар. Чөнки һәр як үзенең әнә шундый кешеләре, табигате, истәлекле урыннары белән данлыклы.

III. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү этабы.

1. Карта белән эш оештыру.

- Укучылар, без яшәгән бистә – Җәлил. Без барасы юлны мин менә шулай билгеләп куйдым. Карагыз әле. Нинди ноктада туктыйбыз без? (Мортыш Тамак). Экранга карадык. Хәзер бу авыл турында бик күп белербез. (Видеоролик карау)

2. Китап күргәзмәсе белән эшләү.

- Укучылар, бу авыл матур күле, музее, 100 еллык мәктәбе белән генә түгел, атаклы кешеләре белән дә мактана ала. Шундыйларның берсе – Мәдинә Маликова. Ул менә шундый калын-калын китаплар яза. Алар арасында хикәяләр дә, повесть-романнар, пьесалар да бар. Ул – күренекле язучы. Хәзер экранга карыйбыз. Монда аның иҗаты күрсәтелгән.

(Мәктәптә ул алдынгы укучы булу сәбәпле, төрле бәйгеләрдә, олимпиадаларда актив катнаша. Сәхнәдән үзе чыгарган шигырьләрне дә укый торган була. 5-6 нчы сыйныфларда ул

үзе язган шигырьләр белән бер дәфтәр тутыра. Мәдинә апага бу сәләт аның әнисеннән күчкәндер, чөнки Һәдия әби такмак чыгарырга бик оста була).

2. М. Маликова — иҗат эшчәнлегенең буеннан-буена каләмен детектив әсәрләр жанрында да чарлаган әдибә. (Китаплары күрсәтелә).

3. М. Маликова драматургия өлкәсендә дә уңышлы гына эшли. Аның «Оҗмах балалары» исемле драмасы Г.Камал исемендәге академия театры сәхнәсендә куелды (1990), «Йөрәк ничек түзсен», «Моңнар төште башыма», «Синең өчен үзем үләрмен» исемле драма әсәрләре Минзәлә һәм Әлмәт театры сәхнәләрендә уңыш белән барды. «Сөембикә» трагедиясе 2004 нче елда уздырылган “Яңа татар пьесасы конкурсы”нда бүләккә лаек булды. «Оҗмах балалары» (1989) исемле драмасы Г. Камал исемендәге Академия театры сәхнәсендә куелды.

IV.Ял моменты. (Туплы уен)

Без яшәгән район? Мәдинә Маликова кайсы авылда туган? Мәдинә Маликова кем ул? Мортыштамак авылының мәктәбенә ничә яшь? Бу авыл янында нәрсә бар? Сарман районы гербында нинди кош сурәтләнгән?Гербтагы башак нинди төстә?Безнең районда нинди казылма байлык табыла?

V.Уку мәсьәләсен чишүне дәвам итү.

«Оҗмах балалары» әсәре буенча китапнамә карау. Рәсемнәр аша әсәрләре турында сөйләп алу.

VI. Рефлексия.

1. Рефлексив кабатлау.Укучыларга бүгенге дәрестә нинди яңа белемнәр алулары турында сораулар бирелә.

- Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Нәрсәләр белдегез?

2. Бәяләү. Укучыларга, дәрестә катнашканнарын бәяләп, билгеләр куела.

3. Өй эше: бистәдә яшәүче берәр язучы турында сөйләргә әзерләнергә

## ТАТАРСКАЯ ЛИТЕРАТУРА И РУССКИЙ ЯЗЫК

(Методические рекомендации для подготовки учащихся к устному итоговому собеседованию по русскому языку в 9-ых классах)

Садыкова Ильмира Зуфаровна, Гарифуллина Альфинур Флеровна,
учителя русского языка и литературы Джалильской СОШ№2,
Сармановский район

Хочется предложить вариант задания для подготовки к устному собеседованию по русскому языку с использованием материалов по татарской литературе.

**Задание 1. Чтение текста.**

**Выразительно прочитайте текст**

**У Вас есть 2 минуты на подготовку**

Имя Мадины Маликовой стало известным в татарской литературе ещё полвека назад. Читателям полюбились её лирические рассказы, полные искренности и жизнелюбия, остросюжетные повести, ставящие перед читателями нравственные проблемы. Рассказы «Снеговица – талая вода», «Жёлтые тюльпаны», «Соперницы», «Когда луна на ущербе», «Не проходи, жизнь!» и другие являются тому ярким примером.

Будучи уже известным писателем, Мадина Маликова взялась за крупные литературные формы – стала писать романы. И первый же из них – «Милосердие» – вызвал широкий интерес читателей, получил высокую оценку литературных критиков, по нему был поставлен многосерийный телеспектакль.

К настоящему времени опубликовано девять её романов. Они нашли свою аудиторию, полюбились многим и запомнились.

Одним из лучших произведений Мадины Маликовой является роман «Красный цветок». С первых минут он берёт читателя за душу и не отпускает до последней страницы, заставляет с неослабевающим интересом следить за сложными судьбами персонажей, размышлять о своей судьбе. И не только. Читая роман, мы задумываемся о проблемах всего общества, страны, в которой живём и будут жить дети наши.

В романе со всей остротой поднимаются проблемы гражданственности. Но всё же это прежде всего поразительная история любви, рассказанная с тонким лиризмом и проникновенностью. Именно этим прежде всего отличается творчество Мадины Маликовой: широким кругозором и умением писать словно акварелью, обрисовывая тончайшие движения человеческой души.(Число слов 196)

**Задание 2. Пересказ текста.**

**Перескажите прочитанный Вами текст, включив в пересказ слова Лилии Хисматовой:**

*В произведениях Мадины Маликовой перед нами разворачивается широкая панорама современной жизни.*

*Главные герои её произведений – люди активные, увлечённые, творческие. Они убеждены, что человек приходит в этот мир, чтобы сделать его лучше и светлее.*

Подумайте, где лучше использовать данные слова в пересказе. Вы можете использовать любые способы цитирования.

У Вас есть 2 минуты на подготовку.

Внимание!Задания 3 и 4 не связаны с заданиями 1 и 2.

Для выполнения заданий 3 и 4 Вам необходимо выбрать одну из предложенных тем беседы.

**Задание 3. Монологическое высказывание.**

**Выберите одну из предложенных тем беседы.**

Тема 1. Увлечение (на основе описания фотографии)

Тема 2. Путешествие в мир профессий, которое запомнилось мне больше всего (повествование на основе жизненного опыта)

Тема 3. Нужно ли заранее выбирать себе профессию? (рассуждение по поставленному вопросу)

У Вас есть 1 минута на подготовку.

Ваше высказывание должно занимать не более 3 минут.

Карточки участника собеседования

**Тема 1. Увлечение**

**Опишите фотографию**

Не забудьте рассказать:

- какими могут быть увлечения в зависимости от их тематической направленности;

· что дает человеку его увлечение;

· в чем преимущество интеллектуальных увлечений;

· опишите героев этого фотоснимка и их настроение.

**Тема 2. Путешествие в мир профессий, которое запомнилось мне больше всего**

**Расскажите о том, как Вы путешествовали по стране или по миру.**

Не забудьте рассказать:

· как давно Вы познакомились с разными видами профессий;

· какова основная цель выбора профессии;

· какое из путешествий в мир профессий Вам запомнилось больше всего и почему;

· что изменилось в Вашей жизни благодаря путешествию в мир профессий.

**Тема 3.** Нужно ли заранее выбирать себе профессию**?**

Не забудьте дать ответы на вопросы:

· Какова роль профессии и в чем, по-вашему, заключено её значение?

· Что такое любимая профессия?
· Почему меняется отношение к профессиям в наши дни?
· Что значит выбрать любимую профессию?

**Задание 4. Диалог.**

**Во время беседы Вам будут заданы вопросы по выбранной Вами теме беседы. Пожалуйста, дайте полные ответы на вопросы, заданные собеседником-экзаменатором.**

Карточка собеседника-экзаменатора

**Тема 1. Увлечение**

Опишите фотографию.
1) Есть ли у Вас какое-либо увлечение и в чем его привлекательность?
2) Какие необычные увлечения есть у Ваших друзей и знакомых?
3) Может ли увлечение повлиять на выбор профессии?

Карточка собеседника-экзаменатора

**Тема 2. Путешествие в мир профессий**

Расскажите о вашей любимой профессии.
1) Куда Вы планируете поступить после окончания школы?
2) Нужно ли заранее выбирать себе профессию?
3) Что бы Вы порекомендовали тем, кто еще не выбрал себе будущую профессию?

Карточка собеседника-экзаменатора

**Тема 3. Природа**

Нужно ли заранее выбирать себе профессию?
1) Как Вы понимаете выражение «выбрать профессию по душе»?
2) Что может рассказать о человеке его профессия?
3) Как Вы понимаете фразу: «Выбрал профессию по призванию»?

Литература:

Адлер М. Как читать книги. – М.: 2011. – 344 с.
Галактионова Т.Г., Казакова Е.И., Гринева М.И. и др. Учим успешному чтению. – М.: Просвещение, 2011. – 88с.

## МАДИНА МАЛИКОВА – СЧАСТЛИВАЯ ЖЕНЩИНА…

Салимгараева Альфия Мидхатовна, Гордюшина Лилия Зульфаровна,
Джалильская СОШ №2, Сармановский район

**Цель:** повышение интереса к творчеству М. Маликовой.

**Задача:** углубить знакомство обучающихся с жизнью и творчеством М. Маликовой;развивать читательский вкус, творческие способности; воспитывать познавательный интерес, нравственные качества на личном примере М. Маликовой.

**Оборудование:** выставка книг; проектор, компьютер; периодическая печать: газета «Сарман» ( 9 октября 2015 г.), журналы «Азат Хатын», «Казан Утлары», газета « Аргументы и факты. Казань» №24 (10.06.2014)

**Ход мероприятия:**

Ученик 1: « Люди, что вы делаете? Оглянитесь в прошлое и посмотрите в будущее. Помогайте друг другу, мы ведь не вечные, миром правит любовь!» (высказывание М. Маликовой).

М.Маликова – известная писательница, публицист, драматург, мастер детективов, общественный деятель, обладательница премии имени Хусаина Ямашева, наша землячка.

Творчество начинается с личности. Личность М.Маликовой как раз совпадает с ее творчеством. Она – первая писательница в истории татарской литературы, которая стала

писать в жанре романа. М.Маликова – автор девяти романов, издала 24 книги, 4 из них были изданы в Москве на русском языке.

Учитель литературы: Какие же черты характера помогли М.Маликовой стать талантливой писательницей? Конечно же, старательность, стремление стать многогранной личностью, упрямство и гордость.В школьные годы М.Маликова была активной, посещала различные кружки, выпускала стенгазеты, писала стихи. Интересовалась шахматами, ходила в кружок парашютистов.

Литературное творчество М.Маликовой поражает своим разнообразием. Это и любовные романы, и детективы, и юмористические рассказы.

Ученик 1: Есть женщины, похожие на Солнце –
От их присутствия становится теплей.
Когда улыбка их лица коснется,
Мир кажется красивей и добрей.

Ученик 2: Есть женщины, похожие на Ветер –
Они изменчивы, легки и веселы,
Они, как бабочки, нужны нам на планете,
Чтоб любоваться ими все могли.

Ученик 3: Есть женщины, похожие на Море –
Нельзя измерить глубину их глаз,
И в их таинственно манящем взоре
Сокрыты тайные знамения для нас.

Все вместе: Ты вся одновременно:
Море, Ветер, Солнце.

Учитель истории: В XX веке развитие татарской женской литературы набирает обороты, появляются новые имена: Эльмира Шарифуллина, Набира Гиматдинова, Клара Булатова, Лена Шакирзян…Но особое место среди них занимает Мадина Маликова.

Ученик 4: Герои М.Маликовой – современные женщины. В галерее женских образов встречаются представители разных профессий: артисты, ученые, художники, судьи, врачи, архитекторы. В произведениях М.Маликова характеризует влияние профессии на становление личности.

Ученик 5: Материнская судьба – хранительница всего лучшего, что накоплено развитием человечества и каждого народа в отдельности. В творчестве М.Маликовой можно встретить два противоположных по своим человеческим качествам образа матерей.

Учитель литературы: В произведении «Егетлеккә бер адым» («Шаг к мужеству») автор показывает, что материнство – дар природы, которым награждаются лишь самые достойные и заслужившие, выстрадавшие его женщины («Шәфкатъ»/«Милосердие»). В своих произведениях автор подчеркивает необходимость осознания нравственных последствий каждого шага будущей матери (« Мендем биек тауларга» /«На вершине»).

Учитель истории: М. Маликову всегда привлекали женские судьбы. В пьесе «Последняя легенда» показано противостояние двух государств, двух культур, двух представлений о политике и жизни. Во главу действия поставлена политика, основанная на исторических фактах. Для постановки пьеса трудная, нужны были исторические костюмы, соответствующая сценография. Премьера состоялась 27 февраля 2014 года в Театре имени К.Тинчурина.

Ученик 6: М.Маликова вспоминает: «Татарский язык – мой родной, лучший из всех. Как бы ни хотела, по–русски не пишу так, как по–татарски, хотя по образованию учитель русского языка и литературы».

Ученик 7: Облику человека автор уделяет большое внимание. Перед тем как приступить к написанию произведения, она долго думает, каким типажом должен обладать ее герой. «Книга – это как любовь, она рождается в сердце», - говорит М.Маликова в интервью.

Учитель истории: Писательница награждена премией имени Гаяза Исхаки. Эта премия присуждается ежегодно за наиболее выдающиеся литературные произведения, способствующие росту духовного богатства нации, за активную общественно – политическую деятельность. Издавать свои книги М.Маликова начала в 2000-ом году, когда была еще президентом Красного полумесяца. Издает книги на свои деньги и реализует их сама. М.Маликова говорит, что рекламной деятельностью заниматься не может, потому что не умеет, но телевидение сделало ее популярной.

Ученик 8: Бывают женщины такие,
Что входят в дом – и вмиг светло.
И тают глыбы ледяные,
Когда струится их тепло.

Ученик 9: Женщина – утро в судьбе чьей-то сложной,
Женщина – чистый, прозрачный рассвет,
В чем-то пленительный, в чем-то тревожный…
В женщине все – и вопрос и ответ.

Учитель литературы: Произведения “ Шәфкатъ” / “ Милосердие”, “ Чәчкә балы” / “ Цветочный мед” включены в школьную программу.

Рефлексия 1. Учитель истории: В чем причина популярности книг М.Маликовой? Ребята, отвечая на этот вопрос, попытаемся составить **кластер.**

Рефлексия 2. Учитель литературы: предлагаем вам составить **Синквейн** и посвятим его Мадине Маликовой.

| |
|---|
| Мадина Маликова |
| талантливая, женственная |
| творит, раскрывает, издает |
| герои произведения – женщины |
| автор книг, известная татарская писательница, наша землячка |

Учитель литературы: Попытаемся провести параллель между татарской и русской литературой. Современная русская проза насыщена женскими характерами, героинями - женщинами. Многие писатели конца XX века уже в названии произведения четко определяют свою ориентацию на раскрытие особенностей женской судьбы.

Ученик 1: Известные авторы последнего десятилетия, которые в своих произведениях раскрывают суть женского характера: Л.Петрушевская, Л. Улицкая, М.Палей, Т.Толстая, В. Токарева, Г. Щербакова. Авторы, будучи сами женщинами, пишут о том, что им ближе и понятнее, что в современном мире стало четче осознаваться: женщина – существо совершенно удивительное, способное напрочь забыть о себе и думать только о ребенке, когда речь идет о защите его интересов

( Л.Улицкая « Дочь Бухары»); она – хранительница очага, защитница рода ( Л.Улицкая « Медея и ее дети»); образ вечной неистребимой женственности (М.Палей « Кабирия с Обводного канала»).

Ученик 2: В.Токарева в своих произведениях описывает внутренний мир героинь, их чувства и переживания, события из жизни женщин, которые вопреки стереотипам, пытаются быть наравне с мужчинами (« Римские каникулы», « Сентиментальное путешествие»).

Учитель литературы: С произведениями современной прозы вы познакомитесь на уроках литературы.

Учитель истории: Женщины не раз круто переворачивали ход истории и культуры. Женщины, которые не раз опережали свое время, проявляли настоящую выдержку и невероятную твердость, женщины, которыми мы восхищаемся. Вот их имена.

Ученик 3: Княгиня Ольга – правительница мудрая и справедливая. Феодосия Морозова – является символом мужественности, железной воли и бесстрашия в борьбе за свои убеждения. Екатерина Романовна Воронцова – Дашкова – первая женщина в мире, которая управляла Академией наук. Екатерина II Великая укрепила государство Российское. Софья

Ковалевская – профессор математики. Анна Павлова – символ русского балета XX века. Анна Ахматова – величайшая русская поэтесса. Валентина Терешкова – первая в мире женщина космонавт, совершившая космический полет в одиночку.

2020 год ознаменован важными событиями в жизни нашего района, республики и страны в целом. В эти дни наш район готовится к празднованию 90-летия со дня образования Сармановского района.

А также республика отметит 100-летие со дня образования ТАССР.

Год памяти и славы, посвященный 75-й годовщине Победы в Великой Отечественной войне, начинается в России.

Рефлексия 3.Что я знаю о жизни и творчестве Мадины Маликовой?Рассмотрите иллюстрации.Определите общую тематику.Найдите связь между элементами.Определите последовательность.Сделайте выводы.

Учитель истории: Итак, наше сегодняшнее мероприятие мы посвятили жизни и творчеству Мадины Маликовой, татарскому литератору. В своих произведениях она раскрывает реальные женские характеры и образы. Мадина Маликова - наставник, добившийся огромных успехов в духовном обогащении народа.

## ПАТРИОТИЧЕСКОЕ ВОСПИТАНИЕ НА ОСНОВЕ ПЬЕСЫМ.МАЛИКОВОЙ «ПОСЛЕДНЯЯ ЛЕГЕНДА»

Салихова Айгуль Робертовна,учитель истории и обществознания,
Нуртдинова Гульнар Салихзяновна, учитель татарского языка,
Джалильская СОШ № 2 Сармановский район

Пьесу «Последняя легенда» я прочитала недавно и с удовольствием стала использовать на уроках при изучении истории XVI века.

Тема пьесы - одна из самых драматичных страниц татарской истории. Казанское ханство. 1550 год. Время смуты и кровопролитий, великих интриг и великих людей. Ханский престол — вот главная цель для врагов внешних и внутренних! Но на пути осуществления их мечты есть лишь одна преграда — на престоле гордо восседает Сююмбике. Уязвимая, но властная, несчастная, но не сломленная, она решается на поступок, который навсегда останется в сердцах людей и станет последней легендой Казанского ханства...

Пьеса о правительнице, женщине и матери. Но, в первую очередь, о противостоянии двух государств, двух культур, двух представлений о политике и жизни.

Сююмбике — правительница Казанского ханства, жена казанских ханов Джан-Али (1533—1535), Сафа-Гирея, Шах-Али, дочь ногайского бия Юсуфа и праправнучка основателя династии Ногайской Орды Идегея. Одна из первых мусульманок-глав государств в истории ислама.

Сююмбике – имя единственной женщины, которая правила Казанским Ханством. Настоящее имя – Сююк, а Сююмбике т.е. «любимой госпожой» её за доброту и отзывчивость называл народ. (Исторические факты о дочере Ногайского хана Юсуф бея, праправнучке основателя Ногайской Орды Идегея.Легенда о башне Сююмбике).

В пьесе «Последняя легенда» Мадина Маликова поставила политику, основываясь на исторических фактах. Героиня не выбросилась с башни в Казанском кремле. Её вместе с малолетним сыном увезли в Москву, где насильно выдали замуж. И это, как она и предвидела, привело к войне.

Согласно другой легенде, не менее поэтичной, башня была специально построена царицей Сююмбике в память своего мужа Сафа-Гирея. Тело его покоилось в белокаменном мавзолее рядом с этой башней. Если верить словам очевидцев, над гробом своего мужа Сююмбике часто молилась, оплакивая его смерть и свою судьбу.(Описание

русскимлетописцом прощание пленницы Сююмбике с могилой Сафа-Гирея перед насильственной отправкой ее в Москву).

В пьесе Мадины Маликовой нет Ивана Грозного. Есть князь Серебряный, историческая личность. В противостоянии его и Сююмбике – противостояние двух государств, историческая неизбежность на тот момент. И князь, и ханбике – равновеликие личности, которые борются за интересы своих народов, демонстрируя одинаковые силу духа и воли. Один считает, что для достижения цели все средства хороши, для другой - превыше всего нравственность, а на руках – маленький ребёнок. Кто знает, как сложились бы их судьбы, встреться они в иных обстоятельствах? Может быть, полюбили друг друга? Князь спас ханбику для дальнейшей, но очень несчастливой жизни, ведь сторонников Москвы было тогда в Казани немало.

**Литература:**

1.М.Маликова пьеса «Последняя легенда»

2.История Татарстана и татарского народа (вторая половина XVI-XVII вв.): учебное пособие для 7класса, для средней общеобразовательной школы/ И.А.Гилязов, В.И.Пискарев. Казань: Татарское детское издательство, 2017.

3. Интернет ресурсы

## МӘДИНӘ МАЛИКОВАНЫҢ «КАР СУЛАРЫ», «САРЫ ТЮЛЬПАННАР», «КЫЗЫЛ ГӨЛ» ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ХАТЫН-КЫЗ ОБРАЗЛАРЫНЫҢ БИРЕЛЕШЕ

Соловьева Фәнүзә Фәнис кызы, Хәбибуллина Миляуша Хәмит кызы.,
Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче Җәлил беренче гомуми урта белем бирү мәктәбе,
Сарман районы

Әдәбиятка килү һәм анда үз урыныңны табу, үз сүзеңне әйтү җиңел түгел, минемчә. Ләкин үз укучыңны табу, дөнья һәм күпмилләтле әдәбияттан яхшы хәбәрдар булган замандашның игътибарын җәлеп итү тагын да авыррак. Менә шундый татлы да, газаплы да әдәби иҗат юлына Мәдинә Маликова журналистлык язмаларыннан – көндәлек матбугат өчен хәбәрләр, документаль очерклар, репортажлар, мәкаләләр язу белән килеп керә.

«Көндәшләр», «Күрше бәхете», «Кар сулары» кебек беренче хикәяләре арасында иң бәхетлесе – «Кар сулары»дыр, мөгаен. Ул хикәя татар укучылары тарафыннан шигъри әсәр кебек кабул ителә. Үсмер кыз Зәйтүнәнең күңел дөньясы искиткеч чиста, Рафиска булган тәүге мәхәббәте гаҗәеп саф. Әби-бабаларыбыздан килгән күркәм гадәтләргә булган игътибары, тыйнаклык һәм кешелеклелек сыйфаты бизи Зәйтүнәне.

Без авторның беренче әсәрләреннән үк хатын-кызның ир-ат ярдәменә мохтаҗлыгын, үзенә таяныч эзләвен һәм бүгенге көн өчен дә актуаль булган мәхәббәт темасының чагылышын күрәбез. Зәйтүнә Рафистан яклау көтә. Бәхетенә – аның өмете аклана. Ә ышаныч һәм өмет булганда теләсә кайсы киртәләрне дә атлап үтәргә мөмкин. Төрле хәйләләр табып, йон юнәлтеп перчатка бәйләү һәм аны иясенә тапшыру шуның ачык мисалы.

Кечкенә генә хикәя. Ә аңа күпме матурлык салынган. Еллар аралыгындада «Кар сулары» хикәясе үзенең актуальлеген югалтмаган. «Сары тюльпаннар» әсәрендәге Люциядә яхшы сыйфатлар берничә кешегә бүлеп бирерлек. Югары уку йортын бик яхшы билгеләренә генә тәмамлаган, аспирантурада калдырылган, егерме биш яшендә фәннәр кандидаты булган, хәзер докторлык диссертациясе өстәлендә ята. Кыз үзенең бик эшлекле булуы, җитди кыяфәте белән егетләрнедә бераз куркыткан, читләштергән. Әсәрнең үзендә үк аңа бик яхшы, дөрес бәя бирелә: «Һәр нәрсәне артык җитди кабул итә. Бер егетнең үзенә күзен төшкәнен сизде исә, бу миңа гомерлек яр була алырмы, мәхәббәте чынмы моның, юкмы дип

тикшеренә башлый, егетне микроскоп астына салгандай итә. Кемгә ошасын микроскоп астына керү!» – дип яза Мәдинә Маликова.

Шушылай сайлану аны ялгызлыкка дучар иткән. Әгәр аны ярата калсалар, егетнең ямьсезлегенә дә ризалашыр хәлгә җиткән ул. Көннәрдән беркөнне кыз үзеннән сигез яшькә кече егеткә гашыйк була. Кешеләрне җентекләп өйрәнергә сәләтле кыз, егетнең гашыйк булучы ролен оста башкаруын абайламый кала, чөнки ул үзе чын күңелдән аны ярата. Флүн исә, Люциянең эчкерсезлегеннән файдаланып, аның ярдәме белән укып чыга, чөнки үзе уку ягыннан бик ялкау һәм салмак була. Үзенең уенын уйнап туйгач, икенче бер кызга өйләнә. Бүгенге тормышта үз рәхәтлеге өчен генә яшәүчеләр аз түгел, безнең герой нәгъ шундыйлардан.

М. Маликованың уңышлы әсәрләреннән тагын берсе – «Кызыл гөл». Әлеге романда язучының таланты яңача ачыла. Романда гражданлык проблемалары бик кискен күтәрелә. Гади кеше дәүләт системасына йогынты ясый аламы? Балалар әти-әниләренең җинаять кылганы өчен җаваплымы? Менә шундый сорауларга автор җавап эзли.

Язучының кайсы хикәясенә генә тукталсак та, без анда тормыш фәлсәфәсен күрәбез Алар шуның белән үзләренең актуальлеген югалтмый, укучыны үзенә тартып, кызыксындырып тора. М. Маликованың хикәя жанрындагы табышлары турында күп язарга мөмкин булыр иде.

М.Маликованың без тикшереп үткән «Кар сулары», «Сары тюльпаннар», «Кызыл гөл» әсәрләрендә укучы үзен таба, үзен тапмаса, яшәү өчен сабак ала. Шунысы мөһим: бүгенге тормышыбызның чагылышы әдәби әсәрләрдә ачыграк күренә. Вакыт үткән саен тормыштан алып язылган әсәрләрнең рухи кыйммәте тагын да арта төшәр, минемчә.

Мәдинә Маликова иҗаты татар әдәбиятында үзенең лаеклы урынын алды. Күренекле әдибебез киләчәктә дә яңадан-яңа әсәрләре белән укучыларны куандырыр, дип, чын күңелдән ышанасы килә.

## ТАТАР ВАКЫТЛЫ МӘТБУГАТЫ:ҮТКӘНЕ, БҮГЕНГЕСЕ

(Әдәби-телдән журнал)

Тихонова Резедә Рәфәт кызы, Гайфуллина Зөлфия Нуриман кызы
Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче Җәлил беренче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**Максатлар:** татар телендә вакытлы матбугатның барлыкка килүе, үсеш алшартлары турында мәгълүмат бирү; татар вакытлы матбугатнының бүгенге торышына күзәтү ясау; Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре журналистларның Хөсәен Ямашев исемендәге республика премиясе лауреаты Мәдинә Маликова тормышы һәм иҗат юлы белән таныштыру. Татар телендә нәшер ителүче газета- журнал белән кызыксынуны үстерү, татар теленә хөрмәт тәрбияләү

**Җиһазлау:** татар телендә нәшер ителүче газета-журналлар, М.Маликова иҗатына карата әдәби бюллетень, әсәрләреннән китап күргәзмәсе.

**Кичәнең барышы.**

**Укытучы сүзе:** Хәерле көн, кадерле укучылар.Без бүген бергәләшеп татар вакытлы матбугатының барлыкка килүе, формалашуы, үсүенә һәм дә бүгенгесенә күзәтү ясарга җыелдык һәм халкыбыз күңеленә кыйммәтле рухи байлык салуда иң зур нәтиҗәгә ирешкән якташыбыз,язучыбыз, остазыбыз, үрнәк алыр кешебез Мәдинә Маликованың тормышы һәм иҗат юлы белән танышырбыз.

**Әдәби журналыбызнын 1нче бите.Татар вакытлы матбугатының барлыкка килү тарихы.**

**Укучы:** 1905-1907 елгы революцион вакыйгалар дулкынында, татар халкының күптәнге хыялы тормышка ашты: Санкт-Петербург шәһәрендә “Нур” исемле беренче татар газетасының беренче саны дөнья күрде. Бу 1905 елның 2 сентябре була.

Татарча вакытлы матбугат өчен көрәш озак бара. 1808 елда Казан университеты профессоры И.И. Запольский татар һәм рус телләрендә газета чыгарырга рөхсәт сорый. Ләкин шактый вакыттан соң гына рөхсәт алынса да, билгеле бер сәбәпләр аркасында чыкмый кала.

**Укучы:** Вакытлы матбугатны булдыру өстендә тырышучылар XIX гасырның 70 нче елларында татарларның үз араларында да күренә башлый. 1863 елда К. Насыйри “Таң йолдызы” исемле газета чыгарырга рөхсәт сорап мөрәҗәгать итә. Ләкин үтенеч кире кагыла. Аның һәм башка бик күпләрнең үтенече канәгатьләндерелми. XIX гасырда татарча газета яки журнал чыгарырга рөхсәт сорап патша хөкүмәтенә 20ләп гариза кергән. Ләкин татарча матбугатка юл ябык була.

**Укучы:** 1905 елны революцион көрәш нәтиҗәсендә, Россиянең төрле төбәкләрендә, татарлар яши торган зур һәм кечкенә шәһәрләрдә татарча газета һәм журналлар чыга башлый.

1906 елда татарча нәшер ителүче газеталарның саны 14кә, журналларның саны 9га җитә.Аларның берничә ай гына чыгып калганнары да бар. Галимнәр әйтүенчә, 1905 - 1917 елларда төрле вакыт аралыкларында 120 ләп газета һәм журнал нәшер ителгән. 1917 елгы революцион вакыйгалар матбугат учагын беркадәр дөрләтеп алса да, шуннан соңгы чорда аларның күпчелеге ябылып, большевистик идеологияне пропагандалаучы егермеләп кенә басма орган кала.

**4 нче укучы:**Татарча вакытлы матбугат өчен көрәш озак бара.Әлеге елларда киң таралыш табып, күп укылган газета-журналларның берничәсен, исемен, чыгу еллары, шәһәре белән танышып китик. Газеталар:

| | |
|---|---|
| “Фикер” Уральск | 1905 – 1907 еллар |
| “Вакыт” Оренбург | 1906 – 1918 еллар |
| “Әл - ислах” Казан | 1907 – 1909 еллар |
| “Идел” Әстерхан | 1907 – 1914 еллар |
| “Кояш” Казан | 1912 – 1918 еллар |
| “Тормыш” Уфа | 1913 – 1918 еллар |
| “Нур” Санкт – Петербург | 1905 – 1907 еллар |

Журналлар:

| | |
|---|---|
| “Әл – гасрел – җәдит” Уральск | 1906 – 1907 еллар |
| “Шура” Оренбург | 1908 – 1917 еллар |
| “Аң” Казан | 1912 – 1918 еллар |
| “Сөембикә” Казан | 1913 – 1918 еллар |

**5 нче укучы:**Татар газета һәм журналлары Казанда, Петербургта, Оренбургта, Уфа, Әстерханда һәм башка татарлар яшәгән шәһәрләрдә нәшер ителә. Алар 1917 елга кадәр тулаем татар байлары һәм сәүдәгәрләрнең акчаларына чыгарылганнар.

1918 елга кадәр нәшер ителгән газета, журналлар тоткан юнәлешләре, эчтәлекләре бунча чуар, төрле булганнар. Аларда төп күтәрелгән темалар булып милли мәгариф, милли тарих, милли әдәбият, сәнгать мәсьәләләре тора.

Татар әдәбияты классиклары һәммәсе – Тукай, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Ш. Камал һ.б. күренекле әдипләр татар матбугатын үстерүгә зур өлеш керткәннәр.

**Әдәби журналыбызнын 2 нче бите.Журналларга күзәтү.**

**Укытучы:**Бүгенге көндә хатын-кызларның яраткан киңәшчесенә әверелгән “Сөембикә” журналына тукталып китик.Ул – хатын-кызлар өчен беренче журнал. 1913 елның 27 октябрендә Казанда нәшер ителә башлый һәм 1918 елның гыйнварынача дәвам итә. Аның барлыгы 91 саны дөнья күргән. 1929 елдан журнал “Азат хатын” исеме астында чыга башлый. Бөек Ватан сугышы елларында чыгудан туктый. 16 ел туктап торганнан соң 1958 елда журнал кабат сулыш ала.

1964 елдан башлап «Азат хатын» журналы редакциясендә әдәби хезмәткәр булып:якташыбыз күренекле язучы, публицист, драматург, детективлар остасы, җәмәгать эшлеклесе, Россия һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Хөсәен Ямашев исемендәге бүләк иясе Мәдинә Маликова эшли башлый. 23 ел "Азат хатын" журналында хезмәт итә. 1991 елдан исеме кире "Сөембикә"гә үзгәртелә.

**Әдәби журналыбызнын 3нче бите.**

**Мәдинә Маликованың тормышы һәм иҗат юлы белән танышалар.**

**Укучы:**Узган гасырның 90нчы елларында, илдә глобаль үзгәрешләр башлангач, тормыш юлында югалып калган, фәкыйрьлеккә төшкән кешеләргә ярдәм итү өчен, М.Маликова "Кызыл ай" җәмгыяте ача. "Үзебезнекеләргә генә түгел, авыр хәлдә калган Чечня республикасына да азык-төлек белән булыштык. Бер тапкыр анда үзем дә бардым"- дип исенә төшерә ул. Андагы эшләр "Өермә", "Көмеш билбау" романнарымда, "Берәгәйле бәрәңге" дигән хикәямдә чагылыш таба.

**Укучы:**Мәдинә Маликова драматургия өлкәсендә дә уңышлы гына эшли. "Оҗмах балалары" (1989) исемле драмасыннан өзек карап китик.

**Укучы:** Мәдинә Маликова — иҗат эшчәнлегенең буеннан-буена каләмен детектив әсәрләр жанрында да чарлаган әдибә. Аның «Хөкем» (1969), «Августның беренче кичендә» (1970), «Адашканга юл кайда» (1971), «Югалган якутлар» (2003), «Чәчкә балы» (2004) исемле маҗаралы повестьлары, «Өермә» (2002) исемле детектив романы, «Кыргый дивизия» (2001) кебек хикәяләрен укучылар яратып укый.

**Әдәби журналыбызнын 4нче бите.Бүгенге көндә вакытлы матбугат.**

Татар вакытлы матбугаты XX гасырның 90 елларыннан башлап яңадан туу чоры кичерде. Бүгенгесе көндә Татарстанда 680ләп газета һәм журнал нәшер ителә. Татар телендә 84 газета һәм журнал чыга. Татарстаннан читтә чыгып килүче газеталарның саны 30га җитә.

Бүгенге көндә укучылар арасында яратып укыла торган, киң таралыш тапкан газета-журналларның исемнәрен барлыйк.

| ***газета*** | ***журнал*** |
|---|---|
| «Мәдәни җомга» | «Казан утлары» |
| «Ватаным Татарстан» | «Сәхнә» |
| «Татарстан яшьләре» | «Идел» |
| «Минзәлә» | «Акчарлак» |
| «Мәйдан» | «Мәгариф» |
| «Кәеф ничек?» | «Мирас» |
| | «Сөембикә» |

**Укытучы:** Әлеге басмаларның тышлыкларына игътибар итегез.

-Бу газета-журналларның кайсылары белән сез кызыксынып, танышып барасыз?Сезгә нинди рубрикалар ошый? (Фикер алышу)

Кичәбезне тәмамлап, Тукаебызның рухын саклап, язучыларыбызның иҗатына мәдхия җырлап, инде хәзер барыбыз бергә "И туган тел" җыры белән кичәбезне тәмамлыйк.

Киләсе очрашуларга кадәр, сау булыгыз!

## ЭНДӘШ СҮЗЛӘР, АЛАР ЯНЫНДА ТЫНЫШ БИЛГЕЛӘРЕ

Фазлиева Гүзәл Дамир кызы,
Советлар Союзы Герое А.А.Казаков исемендәге Александровка төп гомуми белем бирү мәктәбе,Сарман районы

**Максат.**Укучыларның тема буенча белем бирү, күнекмәләр формалаштыру; үзлегеннән танып белү активлыгын үстерү; белемнәрне практикада куллана белергә өйрәтү; туган телгә мәхәббәт тәрбияләү.

Уңай психологик халәт тудыру. “Туган тел” шигыре яңгырый.

Дәрес барышы.

*Укытучы.* Исәнмесез, балалар! Дәресебезне Бөек шагыйребез Г.Тукайның татар халкының гимнына әйләнгән “Туган тел” шигыре белән башлап җибәрдек. Туган телебез искиткеч бай, матур, аһәңле тел.Телебезнең без белмәгән серләре күп әле, әйдәгез, бүген шуларның тагын берсен яхшылап өйрәник. Башладык.

Укытучы. Укучылар, без бүген сезнең белән “Белем иле”нә сәяхәткә чыгарбыз. Сәяхәткә чыгар өчен биремне дөрес үтәргә кирәк булыр.

Ә хәзер слайдта язылган шигырьне сәнгатьле итеп укыгыз. Калын хәрефләр белән язылган сүзләргә игътибар итегез әле. Алар нинди сүзләр икән?

Атым минем үргә менгән саен,
Шатлыгым да арткannан артты;
Ватанымның якты бер почмагы син,
Казан арты, әй Казан арты!
Кыр җилләре иркәләде килеп,
Тукай моңы ерактан тартты;
Әкиятләрең белән ачылды телем,
Казан арты, әй Казан арты!(С.Хәким).

Калын хәрефләр белән бирелгән сүзләр ни өчен кирәк? Кайсы якларга эндәшә? (Казан арты якларына) Бу як кемнең туган ягы?(Тукай туган якка эндәшә)

Җансыз предметларга эндәшү, җанландыру күренеше ничек атала?Автор аларга ничек мөрәҗәгать итә? (Яратып, матур итеп эндәшеп мөрәҗәгать итә)

- Эндәшә, мөрәҗәгать итә торган бу сүзләрне ничек атарбыз? (Эндәш сүзләр)

- Әйе, димәк, дәресебезнең темасы ничек аталыр?

- Эндәш сүзләр җөмләнең нинди кисәге? (Модаль кисәге)

- Бүгенге дәрестә нәрсәләр эшләрбез? Нинди уку мәсьәләсен чишәрбез? (Эндәш сүзләрне таныйрга, кулланырга өйрәнербез).

Нәтиҗә: Эндәш сүзләрне танырга һәм дөрес интонация белән укырга, кулланырга өйрәнербез. Эндәш сүзләр янында нинди тыныш билгеләре куелу үзенчәлекләрен, сөйләмдәге әһәмиятен ачыкларбыз.

III. Яңа белем һәм төшенчәләр формалаштыру

Җөмлә кисәкләрен тану ысулына таянып, эндәш сүзләрне тану ысулын билгелик.Число, теманы язабыз: Эндәш сүзләр һәм алар янында тыныш билгеләре

III. Уку мәсьәләсен адымлап чишү. Беренче тукталыш – “Сорау-бирем”.

Ысул кулланып, эндәш сүзләрне табабыз. Ике төркемгә дә карточкалар бирелә.

Сөйләм нәрсәгә (затка яки предметка) мөрәҗәгать иткәнен (эндәшкәнен) билгеләү. Ягъни сүзне әйтүнәрсәне белдерә (Мөрәҗәгатьне, тыңлаучыга мөнәсәбәтне белдерә) Нәрсә белән белдерелә? (Баш килештәге исем белән белдерелә)

Шаулагыз, имәннәр, тыныч тормышның беренче кышына мәдхия җырлагыз! (М. Мәһдиев)

(Имәннәр, сөйләм предметка төбәлгән. Предметка мөрәҗәгатьне эндәшүне белдерә. Баш килештәге исем белән белдерелә).

- Предметларга төбәп эндәшү күренеше ничек атала? (Сынландыру).

Йа Раббым, рәхмәтең чиксез! (М.Маликова) (Йа Раббым! - мөрәҗәгатьне белдерә. Баш килештәге исем белән белдерелә)

Эндәш сүзләр ничә сүздән тора? Төзелешенә бәйле рәвештә нинди төрләре булыр икән? Әйтеп карагыз әле. (Төзелеше буенча җыйнак һәм җәенке э.с. була)

Эндәш сүзләрне укыганда интонация аерыламы? Нинди тыныш билгеләре? (Эндәш сүзләрне укыганда интонация үзгәрә. Өтерләр, өндәү)

И, ай, әй, о ымлыклары бер интонация белән әйтелсә, ике арада өтер куелмый. Үзбәя.

Икенче тукталыш – “Проект эше”.

Укучылар, төркемнәргә җөмләләр тәкъдим итәм. Эндәш сүзләр табарга, аларга сораулар нигезендә тикшерергә. Эндәш сүзләрнең кулланылышын тактада беркетә барырсыз.

Һәрберегезгә өләшенгән сорауларда түбәндәгеләр язылган: 1.Эндәш сүзләрнең кайда кулланылуын әйтергә. 2. Җөмләнең кайсы урынында килүен билгеләргә.3. Кайсы сүз төркеме белән белдерелгән булуын ачыкларга. 4. Алар янында куелган тыныш билгесенә аңлатма бирергә. 5.Җәенкеме, җыйнакмы икәнен әйтергә. 6. Сынландырылган яки сынландырылмаган булуын күрсәтергә. (Җаваплар тыңлана).

Ял итү (динамик пауза).Күзгә гимнастика ясау.

Өченче тукталыш – "Дөрес урнаштыр".

VI . Белем һәм күнекмәләрне ныгыту.

Г.Тукай шигырьләрендә төшеп калган эндәш сүзләрне һәм тыныш билгеләрен куярга, тыныш билгеләренең куелышын аңлатырга. Төркемнәрдә эшлибез. Һәр төркемгә 5 әр җөмлә. 5 балл – "5"ле 4 балл – "4"ле3 балл – "3" 2 балл – "2"ле 1 балл – "1"ле.

Балалар, без юлыбызны дәвам иттерәбез. Безнең алда - "Елга". Елганы үтми торып, без башкалага керә алмыйбыз. Елганы үтәр өчен, сезгә дәреслектәге 346 нчы күнегүне эшләргә кирәк. Дәфтәрләрдә эшләнә. Эндәш сүзләр төрле урынында булырлык итеп, җөмләләр уйлап языгыз. (Җөмлә кисәкләре ягыннан тикшереп, э.с. җөмлә кисәге була аламы, юкмы икәнен әйтергә.) Инде "Белем иле"нең башкаласына килеп җиттек. Ләкин без анда керә алмыйбыз. Капкаларны ачар өчен, безгә тагын бер бирем эшләргә кирәк. Әгәр дә сез дөрес эшләсәгез, ул ачылачак.Үзбәя

V. Бишенче тукталыш – "Модельләштерү".

Эндәш сүзләр: сөйләм төбәлгән зат яки предметны белдерәләр. Аерым интонация белән әйтеләләр. Баш килештәге исем белән белдереләләр. Җөмләнең теләсә кайсы урынында киләләр. Җыйнак һәм җәенке булалар. Җөмлә кисәге була алмыйлар. Алар янында өтерләр, ә көчле тойгы белән әйтелгәндә, өндәү билгесе куела.

Укытучы. Сөйләм нинди генә төрдә булмасын, ул һәрвакыт кемгә дә булса мөрәҗәгать ителгән була. Шуңа күрә эндәш сүзнең сөйләмдәге роле бик зур. Модельләрне тактага беркетәбез. Үзбәя.

-"Белем иле"нең башкаласына керү өчен ишекләр ачык. Авыр һәм катлаулы юлны барыгыз да яхшы үтте. Укучылар, дәресебез Г.Тукайның "Туган тел" шигыре белән башланып киткән иде. Бу шигырьдә нинди сүзләр булган? ( И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!)

- Ә хәзер белгәннәрегезне тагын бер тапкыр ныгыту һәм тикшерү өчен тест эшләп алырбыз.

VI. Рефлексив кабатлау. Белемнәрне бәяләү.

Өй эше: 1. 353 нче күнегү . 2. Иҗади бирем: Эндәш сүзләр кулланып иҗади эш башкарырга.

## ЗЫЯЛЫ ЯЗУЧЫ

Фахразиева Лилия Фәнүз кызы,
Әлмәт шәһәренең дүртенче санлы урта мәктәбе

**Максат.** Мәдинә Маликова иҗаты белә таныштыру. Аның иҗатына күзәтү ясау. Мәдинә Маликова иҗатына кызыксыну тәрбияләү.

Чара әдәби кафе формасында бара. Укучылар өстәл артында утыра. Ә берничәсе администратор, официант, пешекче ролендә.

**Барышы.**

Залда "Сарман" буйларында җыры яңгырый.(Сарман ягы шәхесе икәнен күзаллап)

**Администратор**. (Алып баручы) Хәерле кич! Без сезне әдәби кафеда күрүебезгә бик шатбыз. Безнең кафебыз бүген “Зыялы язучы“ исеме астында эшли. Иң беренче менюда салкын кабымлыклар бирәбез. Сезгә “Сугыш баласы” салатын тәкъдим итәбез.

**1нче официант**.(укучы М.Маликованың яшьлек фотоларын тарата-тарата сөйли) “Мин Сарман районының Мортыш Тамагы авылында гаиләдә беренче бала булып дөньяга килгәнмен. Сугышның иң кызган чагында – 1943 елда беренче класска укырга бардым, - дип сөйли Мәдинә апа үзенең сугыш чорында узган балачагын искә төшереп. - Кечкенәдән китап корты идем. Хәер, ул чакта китаплар аз иде. Нинди генә басма язма кыйпылчыгына юлыксам да, йотлыгып укый идем шуларны. Әнкәй миңа, тәпи йөри башлаганчы, телең ачылды, ди иде. Арттыргандыр, мөгаен. Мәктәпкә бик яратып йөрдем. Шигырьләр яздым, стена газетасы редакторы булдым. Концертларда катнашып, үз шигырьләремне сөйләп, сәхнәдән төшмәдем,”- дип дәвам итә ул сүзләрен, «Ялкын»журналына биргән интервьюсында.

**2 нче официант.** Мәдинә Габделхак кызы Маликова — күренекле татар язучысы, драматург.Ул 1935 елның 5 августында Сарман районының Мортыштамак авылында туа. Шушы авылда җидееллык мәктәпне тәмамлый.

1949-1959 елларда ул Минзәлә педагогика училищесында, Казан дәүләт педагогика институтында укый. Аннан соң «Чаян» журналында корректор, «Азат хатын» журналында әдәби хезмәткәр һәм шул ук журналның җаваплы сәркатибе булып эшли.

**1нче официант**. М. Маликованың әсәрләре аның 20 гә якын китабына тупланган. Алар арасында «Юлдашлар», «Казан каласы — таш кала», «Кар сулары», «Егетлеккә бер адым» исемле хикәя һәм повесть җыентыклары, «Шәфкать», «Басып сайрар талы бар», «Фидая» исемле роман китабы бар.

Соңгы елларда аның «Алтын ятьмә», «Оҗмах балалары», «Мендем биек тауларга» исемле роман, пьеса, повесть, хикәяләре, детектив жанрда язылган китаплары басылып чыкты.М. Маликова 1993 елдан Бөтентатар «Кызыл Хач» җәмгыяте президенты да.

**Администратор**. Сезгә кайнар ризыклар тәкъдим итәргә рөхсәт итегез. Беренчегә бирелүче кайнар ризыгыбыз **“Журналисттан язучыга”** дип атала.

**3 нче официант.** Казан педагогия институтында укыганда «Яшь сталинчы» газетасы, «Комсомолец Татарии» редакциясе коллективы һәм аның тирәсендә тупланган актив яшьләре белән аралашырга, эшләргә туры килә Мәдинә Маликовага. Соңгы курста укыганда, «Комсомолец Татарии» редакциясендә корректор ярдәмчесе булып эшли.

Укуы инде тәмамланыр алдыннан «Комсомолец Татарии»да буш урын булмаганлыктан, редактор аны «Чаян» журналына тәкъдим итә. Шулай итеп, 1959 елның март аенда «Чаян»да корректор булып эшли башлый. Җәйгә институтны да Кызыл дипломга тәмамлап чыга.

**4 нче официант.**«Яшь ленинчы» редакциясенең хикәяләргә ябык конкурс игълан ителә. Ә бәлки, миңа да катнашып карыргадыр, дип, М. Маликова да игезәк туганнары Хәмит белән Хәмдияне өлге итеп алып (исемнәрен үзгәртеп, әлбәттә), «Ташу вакытында» дигән хикәя яза. Матур рәсем белән бизәп, газетада бастырып чыгаралар. Призлы урын алмаса да, иҗат юлында хәлиткеч адым була ул хикәя.

**5 нче официант.** «Чаян»нан соң «Азат хатын»га килеп эләгүем һәм анда эшләгән 23 ел гомерем үзе бер алтын чор булды... «Азат хатын»дагы журналистлык тәҗрибәм булмаса, мин бүген М.Маликова дигән язучы була алмас идем. Уйлап карагыз, журналистның язу өчен конкрет темасы, ниндидер максаты бар, һәм ул, шуны өйрәнеп, тиешенчә язып чыга. Ә язучының эшен мин болганчык суда чуртан тотарга тырышуга тиңләр идем. Эләгәме әле ул, юкмы. Әнә шул журналистлык эшендә җыйган тормыш тәҗрибәм миңа әдәби әсәрләр язганда бик булышты,”- дип сөйли М.Маликова.

**1нче официант**. 1967 нче елда чыккан «Юлдашлар» исемле беренче хикәяләр җыентыгында ук ул укучы алдына тирән әхлакый мәсьәләләрне җитди итеп куярга омтылуы белән игътибарны җәлеп итә.

**2 нче официант.** Язучының «Казан каласы – таш кала» (1967), «Кояш күпере» (1973), «Янар таулар яктысында» (1977) повестьлары, «Шәфкать» (1985), «Басып сайрар

талы бар» (1987), «Фидая» (1990) романнары шәһәр һәм авыл зыялылары – инженерлар, архитекторлар, рәссамнар, табиблар, артистлар тормышына багышлап язылганнар.

**3 нче официант.** Халык язучысы Аяз Гыйләҗев үзенең бер чыгышында М.Маликованы “зыялы язучы” дип атаган. Чыннан да, зыялылык язучы иҗатының бөтен рухында чагыла.

**4 нче официант.** М. Маликова – иҗат эшчәнлегенең буеннан-буена каләмен детектив әсәрләр жанрында да чарлаган әдибә. М. Маликова сюжетны оста, мавыктыргыч итеп кора белә, вакыйгаларны йөрәк аша үткәреп, укучының күңел кылларын тибрәндерерлек итеп тасвирлый.

**5 нче официант.** М. Маликова драматургия өлкәсендә дә уңышлы гына эшли. Аның «Оҗмах балалары» исемле драмасы Г.Камал исемендәге академия театры сәхнәсендә куелды (1990), «Йөрәк ничек түзсен», «Моңнар төште башыма», «Синең өчен үзем үләрмен» исемле драма әсәрләре узган гасырның туксанынчы елларында Минзәлә һәм Әлмәт театры сәхнәләрендә уңыш белән Минзәлә һәм Әлмәт театры сәхнәләрендә зур уңыш белән барды. «Сөембикә» трагедиясе 2004 нче елда уздырылган “Яңа татар пьесасы конкурсы”нда бүләккә лаек булды. «Оҗмах балалары» (1989) исемле драмасы Г. Камал исемендәге Академия театры сәхнәсендә куелды.

**Администратор.** М. Маликова – Татарстанның (1976) һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре (1985), журналистларның Хөсәен Ямашев исемендәге республика премиясе лауреаты (1980), Гаяз Исхакый исемендәге, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты һәм иң мөһиме: татар телендә романнар иҗат иткән беренче хатын-кыз язучы.

Без сезгә **“Тормыштан кызыклы үрнәк”** дип аталучы икенче кайнар ризык тәкъдим итәбез.

**1нче официант**. Китап укучылар арасында геройлардан үзен танып алучылар бар икән... “Димәк, син, автор буларак, типик образ тудыра алгансың, дигән сүз бу. Дөньяда булмаганны уйлап чыгару мөмкин түгел, син аның өлгесен таныш кешеләрдән аласың. Монда төп таләп шул: әсәрдә аның кайгы-хәсрәтләре дә, куаныч-шатлыклары да күпләрнең башыннан узган кичерешләргә охшаш, тәңгәл булырга тиеш. Хисләрнең уртаклыгы мөһим,” - дип яза Мәдинә ханым.

**2 нче официант.** Тагын бер үзенчәлек шунда: әдип кеше психологиясен яхшы белә. Язучы өчен бу бик мөһим. Билгеле булганча, кешеләр бертөрле түгел, һәркем кабатланмас шәхес, индивидум. Галимнәр һәр адәми затта миллион кешенең каны бар, диләр. Хәтта кешеләрнең бармак эзләре дә бер-берсенә охшамый. Димәк, образ, характерлар тудырганда, гомуми шаблоннарга ябышып яту, кешеләрне тик кара яки ак төскә генә буяу һич тә дөрес булмас иде.

**3 нче официант.** М. Маликованың «Тылсым» романында гомумкешелек кыйммәтен чагылдыручы мәңгелек тема – мәхәббәт темасы иман төшенчәсе белән яңартылып сурәтләнә.

**4 нче официант.** Тәнкыйтьче М.Вәлиев язучының әлеге сыйфаты турында: “ ...язучы үз геройларының күңел дөньяларын тирәнтен тоеп, аларның бөтен хәрәкәт мотивларын аңлап, белеп яза. Геройларның эчке чынбарлыклары, аларның күзгә күренеп тормаган яклары нинди булуын без шактый ачык һәм реаль сизәбез. Бу бүгенге әдәбият өчен бик мөһим сыйфат”, - дип яза.

**5 нче официант.** Күптән түгел дөнья күргән «Сандугачның күз яше» романында хәзерге яшьләр, бүген бара торган вакыйгалар, проблемалар күтәрелә. Үзәктә – яшьләр.

**Администратор.** Менә десерт вакыты да җитте. Бүген безнең пешекчебез сезгә “Тугызның иң беренчесе” дип исемләнгән десерт тәкъдим итә.

**Пешекче.** Бүгенге көндә 9 роман авторы булганМ. Маликованың иң беренче романы – «Шәфкать». Инде күпләр оныта да башлаган роман медицина дөньясын реаль җирлектән чыгып яктырта. Романның геройлары табиблар да, башкалар кебек үк, җан ияләре. Аларга да мәхәббәт, хөсетлек, тар күңеллелек, коллегалардан көнләшү кебек сыйфатлар хас.

**1 нче официант.** Роман әле генә вуз тәмамлаучыларның Гиппократ антын бирү тантанасын тасвирлау белән башлана. Президиумда абруйлы профессор Җәмилә Закировна Ильясова утыра. Ул яшь коллегаларының олы тормыш юлына атлауларына шатлана. Аларга ак юллар тели. Яшьләрне доцент Изаил Харисович Дәүләтшин да котлый. Телгә оста, нәрсә әйтергә икәнен белә. Карап торуга нормаль бер кеше. Әмма ул мәкерле, кара эчле. Үзенең фән өлкәсендә үсә алмавын профессор Ильясовадан күрә, ул булмаса, мине кафедра мөдире итеп куялар иде, дип уйлый. Шул фикерен Мәскәүдәге дусларына да җиткерә...

**2 нче официант**. Менә яшь табибә Лариса. Ул авыл кешеләренә көлеп карый, аларга нинди дару бирсәң дә ярый, дип кенә җибәрә, хәтта шул хакта ачыктан-ачык әйтә. Табиб Хөсәенгә кияүгә чыгып, еракка китә. Әмма анда озак яшәми, ирен ташлап Казанга кайта, кеше тормышын боза.

**3 нче официант.** Кешенең әхлакый сыйфатлары аның шәхси тормышында, мәхәббәт-гыйшык өлкәсендә генә түгел, хезмәтен башкаруында, андагы кешеләр белән аралашуында да күренә. «Шәфкать» романы уңыш казанган икән, моның сере барыннан да элек әсәрдә кеше образларының әхлакый йөзләрен яшәешебезнең әнә шул ике катламын тыгыз үреп сурәтләвендә дияргә була.

**Пешекче.** “Ә шәһәр өстендә тыныч төннең зәңгәрсу-кара канаты җәелгән. Урманнарда, юлларда, тәрәзәләрдә кешеләрнең иминлеген саклап утлар яна, Җирдә безгә кадәрле яшәгәннәрнең изге мирасы – күңел җылысы һәм яктысы булып яналар алар”, - дип тәмамлый М.Маликова әсәрен. Әйтерсең, ничек кенә булмасын, тормыш дәвам итә.

**4 нче официант.** М. Маликова әсәрләрендә яшәешнең төп мәгънәсе һәм максаты турында укучысы белән җитди әңгәмә алып бара. Мәхмүт Әхмәтҗанов бу хакта: “Әхлак тәрбияләүдә М. Маликова әсәрләренең роле әйтеп бетергесез зур. Моның сәбәбе шунда: әдәби әсәр берьюлы аңга да, хисләргә дә тәэсир итә. Бу исә тәрбиянең – инанулар формалаштыруның иң нәтиҗәле ысулы”,- дип яза. Зиннур Хөсникяр да аның язучы каләменә хас үзенчәлекне билгели: “М. Маликова үзе тасвирлаган кешеләр җанының иң матур, гүзәл сыйфатларын тотып ала белә. Язучы реаль тормыш белән шигърияtне бергә куша, синтезлый. Шигърилек күп кенә әсәрләренең эчке тукымасына салынган”.

**Администратор.** Яшьләрне яратучы, интернет, копьютерны да үзләштергән, үз әсәрләрен үзе тәрҗемә итүче, үз китапларын үзе сатучы Мәдинә Маликова болай ди: “Җәмгыять әдәби әсәр кебек. Аны гел үзгәртеп, яхшыртып торырга кирәк. Гариф Ахунов, әсәр яхшыртудан туймый, дип әйтә иде. Язучы буларак, мәдәнияткә, сәнгатькә игътибарның күбрәк булуын теләр идем. Чөнки бер генә җәмгыять тә мәдәниятсез яши алмый. Мәдәният өлкәсе, рухи хезмәт матди яктан да күбрәк бәяләнсен иде.” Безнең әдәби кафе менюы сезгә ошагандыр дип өметләнәбез. Чөнки ул бик эчтәлекле-туклыклы булды дип уйлыйбыз. Сез бу кунакчыл, кызыклы кафега тагын керерсез, дип ышанып калабыз.

## МӘДИНӘ МАЛИКОВАНЫҢ ЮБИЛЕЕ УҢАЕННАН ОЕШТЫРЫЛГАН КИЧӘ

Фәйзрахманова Миләүшә Изаил кызы, Аглиева Раушания Изаил кызы,
Зиннәт Хәсәнов исемендәге Иске Кәшер урта гомуми белем бирү мәктәбе,
Сарман районы

Татардан күп асыл затлар җиһанда,
Горурланам тарих битен ачам да.
Дөрес икән: ничек кенә бутама –
Алтын алтынлыгын саклый кайчан да.

Талгын гына “Сарман”көе яңгырый. Кичә буласы зал бәйрәмчә бизәлгән, сәхнә түренә: “Мин дөньяга ачык тәрәзәдән ачык күңел белән карадым...” сүзләре язылган, Мәдинә Маликованың төрле елларда басылып чыккан китапларыннан күргәзмә оештырылган.

1а.б. Күпме асыл зат Сарманнан,
Валлаһи менә, икмәк.
Бар бугай Сарман суында
Я дару, я бер хикмәт.
Сарман затларын санарга
Бармаклар җитми күптән.
Җырчы, галим, язучылар
Явамы әллә күктән?

1а.б. Чыннан да, Сарман ягы талантларга бик бай. Бүгенге көндә районыбызда егермедән артык шагыйрь һәм прозаик үсеп чыкты. Шулар арасында мәгънәле, бүгенге көн кадагына суга торган, матур әдәби әсәр үрнәкләре биргән Мәдинә Маликова исемен горурланып атый алабыз.

2 а.б. Бүген сез мәктәбебездә Мәдинә Маликованың 85 яшьлек юбилее уңаеннан оештырылган кичә кунаклары.

1а.б. Сүзне Мәдинә Маликованың тормыш юлы белән таныштыру өчен туган тел укытучысы Фәйзрахманова Миләүшә Изаил кызына бирәбез. (*Тормыш юлын сөйләү барышында презентация күрсәтелеп барыла).*

1 а.б. Тормыш никадәр генә авыр булса да, кыенлыклар күпме генә очраса да, түбәнлеккә тәгәрәмә. Кеше булып кал! Тормыш әлифбасын гомер буе өйрәнергә тырыш!

2 а.б. Ф.Яруллинның шигъри юллары нәкъ менә Мәдинә Маликова турында

Тауларга карап,
Тау булмасаң да,
Таңнарга карап,
Таң булмасаң да,
Кешегә карап
Кеше була бел –
Олы җанлының
Ише була бел!

***Мәдинә Маликованың «Чәчкә балы»*** *повесте буенча китапнамә күрсәтелә.*

Биология укытучысы Аглиева Раушания Изаиловна «Чәчкә балы» повесте буенча сөйли: Төп герой Гамил һәм аның гаиләсе үрнәгендә кешенең рухи дөньясы, кешеләр арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләр сурәтләнә. Автор яшәешнең мәгънәсен яхшылыкка, матурлыкка хезмәт итүдә күрә. Гамил нык ихтыяр көче булган кеше буларак күз алдына килеп баса. Аның өчен гаиләсе, уллары беренче урында тора. Әсәрнең үзәгендә җәмгыятебездә булган төп проблема – наркомания, эчкечелек. Җәмилнең авыру бала булып туының сәбәбе дә шунда.

1 а.б. Мәдинә Маликова бу проблемаларны күреп, бик борчыла. Һәм, аныңча, проблемаларны чишү өчен, гаиләләрдә терәк булырлык, ышанычлы ирләр кирәк. Ирләрен яратучы, хөрмәт итүче, сөйкемле һәм акыллы хатын-кызларыбыз кирәк. Шундый гаиләләрдә тәрбияләнгән балалар гына сау-сәламәт, үз-үзенә ышанучан һәм нәселне яхшы дәвам итүчеләр булачак. Ә инде андый гаиләләребез күбрәк булса, җәмгыятебез дә сау-сәламәт булачак.

<u>Җыр “Балаларга фатыйха”</u>

2 а.б. - Кечкенәдән китап корты идем. Хәер, ул чакта китаплар аз иде. Нинди генә басма язма кыйпылчыгына юлыксам да, йотлыгып укый идем шуларны. Әнкәй миңа, тәпи йөри башлаганчы, телең ачылды, диде. Арттыргандыр, мөгаен. Ә бәлки, соңрак тәпи киткәнмендер. Әнкәй үзе бик шигъри җанлы кеше, авызыннан шигырьләр коелып кына тора иде. Мәктәпкә бик яратып йөрдем. Шигырьләр яздым, стена газетасы редакторы булдым. Концертларда катнашып, үз шигырьләремне сөйләп, сәхнәдән төшмәдем. Күптән түгел Сарманда бер иҗади очрашуда катнашкан идем. Инде сирәк калган классташларымның берсе – Нәкыйп – яныма килеп, балачак вакыйгаларын искә төшерде,- дип язган Мәдинә Маликова үзенең бер истәлегендә.

1 а.б. Шушы истәлектә искә алган Хафизов Нәкыйп абыйны без бүген кунакка чакырдык. Рәхим итеп, безгә дә Мәдинә Маликова турында сөйләгез әле.

Җыр “Тик туган җирдә генә”

2 а.б. Мәдинә Маликова комедия, драмалар язучы да. Сезгә «Ал, Сәкинә, Американы!» комедиясеннән өзек тәкъдим итәбез.

5-7 класс укучылары чыгышы.

1 а.б. Хезмәт җимешләрегез сезгә
Китерсен бетмәс шатлык.
Телибез Сезгә, Мәдинә апа,
Ихластан тыныч картлык.

2 а.б.Сез барчабызга кирәкле
Аяклы тарихыбыз.
Картлардан калган мирасны
Саклаучы варисыбыз,
Онытылмас язучыбыз.

1 а.б.Үзебезнең кичәбезне Д. Гарифуллинның “Шигъри күчтәнәче” белән тәмамлыйсы килә.

Сиксәнбишем ишек төбендә,
Тоткан ул ипи-тозын.
Артында 90, 100ләрем,
Ә кая соң утызым?..

## САРМАННЫҢ ЗЫЯЛЫ ЯЗУЧЫ

Фәрхетдинова Тәслимә Флер кызы, Бариева Фәнүсә Фоат кызы,
икенче санлы Җәлил урта мәктәбененңбашлангыч сыйныф укытучылары,
Сарман районы

**Максат:** Мәдинә Маликова иҗаты белән таныштыру. Күренекле шәхесләр белән горурлану, аларны ихтирам итү хисе тәрбияләү.

**Җиһазлау:** Мәдинә Маликованың китапларыннан күргәзмә, тест үткәрү өчен карточкалар

**Класс сәгатенең барышы**

***1.Кереш әңгәмә.***

Җырларда җырланган Сарман ягы, Сарман төбәге... Без шушы яктан үскән, тирән хөрмәткә ия булган, күренекле татар язучысы, драматург,Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Мәдинә Габделхак кызы Маликовага багышланган класс сәгатен багышлыйбыз.

Мәдинә Маликова – балаларның гына түгел, ә өлкән буынның да яраткан язучыларның берсе. Татар әдәбияты тарихында хатын-кыз язучылардан беренче булып роман язды. Һәрвакыт тел, әдәбият сагында булды. 23 ел «Азат хатын» журналында эшләде. Ул елларда бу журнал 480 мең тираж белән таралды һәм бөтен татар халкын берләштерүче абруйлы, мәртәбәле басма иде. Шуның өстенә Мәдинә апа – 9 роман авторы, 24 китап бастырып чыгарды, 4се Мәскәүдә рус телендә басылды. Аны сыйфатлый торган иң күркәм сыйфатларның тагын берсе – горурлык, зыялылык.Ул – горур татар кызы, татар язучысы. Шундый язучы бүләк иткән өчен Сарман халкына рәхмәт.

***2.Мәдинә Маликова иҗаты белән таныштыру.***

**3.Тест чишү.**

*1. Мәдинә Маликованың әтисенең исемен күрсәтегез?*

а)Габделхак ә) Мирсәет б) Гариф

*2. Язучының мәктәп еллары кайда уза?*

а) Балык Бистәсе районында Котлы Бөкәш авылында; ә) Сарман районында Мортыш Тамак авылында; б) Минзәлә районында Бикбау авылында

*3. Минзәлә педагогия училищесында һәм Казан дәүләт педагогия институтында кайсы елларда укый?*

а) 1942-1952 ә) 1949-1959 б) 1945-1955

*4. Ул ничә роман авторы?*а) 5 ә) 10 б) 9

*5.Мәдинә Маликова ничәнче елларда «Чаян» журналында корректорвазыйфаларын башкара?*

а) 1949 – 1955 нчы елларда ә) 1964-1978 нче елларда б) 1959-1963 нче елларда

*6. Ничә китабы рус телендә басыла?*

а) 3 ә) 8 б) 4

*7.Ничәнче елдан Язучылар берлеге әгъзасы?*

а) 1969 ә) 1972 б) 1064

*8.Ничәнче елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе бирелә?*

а) 1989 ә) 2011 б) 2017

*9. Бүгенге көндә кайда яши?*

а) Сарманда ә) Мортыш Тамак авылында б) Казанда

***4.Йомгаклау*** Мәдинә Маликова иҗаты белән горурланабыз. Аның иҗатына колачлылык хас. Иҗаты белән эзлекле төстә танышып барган кеше аның әсәрләренең кешегә, җирдә яшәүгә мәхәббәт һәм гуманизм идеяләреннән аерылгысыз булуын, бүгенге көндә актуаль булган темаларны күтәргәнен күрә. Аңа тема ят түгел. Аның кайсы гына әсәрен алсаң да, укучыны ятьмә кебек корылган сюжеты белән мавыктыра, уйландыра, алда ни булыр икән дип кызыксындыра. Безгә калса, халык арасында тәвәккәллеге, кыюлыгы, күп сүзгә урын калдырмыйча өздереп әйтә белүе белән дә танылган язучының әсәрләре башка телдә дә бик яңгыраш таба.Мәдинә Маликова иҗаты татар әдәбиятында үзенең лаеклы урынын алды. Аңа Республикабызның зур бүләге –Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелү дә шуны раслый. Күренекле әдибебез киләчәктә дә яңадан-яңа әсәрләре белән укучыларны куандырыр, дип чын күңелдән ышанасы килә. Иң әһәмиятлесе шул: мөхтәрәм язучыбызның басып сайрар талы бар. Ул — аны яраткан, хөрмәт иткән халкы.

**Кулланылган әдәбият:**

1. Мәдинә Маликова «Югалган якутлар».- Казан, «Рухият» нәшрияты, 2004.
2. Мәдинә Маликова «Шәфкать».- Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1990.
3. Хантимерова Г. Төсләр балкышы. -Казан утлары. -1981. № 8.

## ПЕДАГОГИЧЕСКИЙ ПРОЕКТ «ИЗВЕСТНЫЕ ПИСАТЕЛИ РОДНОГО КРАЯ

Халитова Наиля Амирзановна,Хакимова Гелюся Габдулловна,
Горшенина Марина Александровна,
воспитателиДжалильского детского сада №3 «Аленушка»,
Сармановский район

### Введение

В сердце каждого человека живет любовь к родной стране, к Родине. Чтобы сохранить, развить, укрепить эту любовь, нужно с детства правильно воспитывать детей. Воспитание – это сложный педагогический процесс. Его основой является создание нравственных качеств. Любовь к Родине, наверное, начиналась с того, что ребенок близок к своим близким –

родителям, бабушкам, родному дому. Любовь к Родине проявляется в умении чувствовать красоту родного края, гордиться людьми, которые сделали многое для процветания родного края. Каждый самый маленький уголок Республики Татарстан имеет свои особенности, своих земляков, которыми гордится. Память о них мы можем и должны сохранить для будущих поколений. В нашем Сармановском районе, тоже есть много знаменитых людей. Одной из них является известная татарская писательница, драматург, публицист, общественный деятель, заслуженный работник культуры Татарстана и РСФСР, Лауреат Государственной премии Республики Татарстан имени Габдуллы Тукая–Мадина Габдулхаковна Маликова. Ее первые шаги на пути к литературному творчеству начинаются с журналистских публикаций – ежедневных новостей для печати, документальных очерков, статей.

В основе нашего проекта лежит познавательно-творческая деятельность. Нам хотелось, чтобы наши воспитанники знали своих великих земляков, любили и гордились местом, в котором они живут, чтобы выросли достойными гражданами нашей Родины.

**Цель проекта:** изучить жизнь и творчество писательницы Мадины Маликовой, вызвать интерес у детей к творческому наследию писательницы-землячки, прививать любовь к родному краю.

Участники проекта: дети подготовительной к школе группы, воспитатели, музыкальный руководитель, воспитатель по обучению детей татарскому языку, родители воспитанников.

Ожидаемые результаты: Организация и планирование проектной деятельности ведется по 3 направлениям:работа с детьми, работа с воспитателями, работа с родителями.

Этапы реализации проекта:1 этап подготовительный.

2 этап основной: совершенствование предметно-развивающей среды в ДОУ (книжные уголки, информационные стенды).

3 этап заключительный: презентация опыта для сотрудников детского сада; оформление проектной деятельности; подведение итогов и выводов по теме проектной деятельности, оформление альбома: «Наши земляки».

План проектной деятельности

| Участники | Форма работы | Сроки |
|---|---|---|
| Работа с детьми | Проведение занятия с детьми по ознакомлению с жизнью и творчеством Мадины Маликовой;беседа «С любовью о наших земляках;<br>Вечерние чтения: «Путешествие по произведениям наших земляков» (Д.Гарифуллин, А. Минхажева, М. Джалиль);<br>посещение читального зала детской поселковой библиотеки;<br>посещение музея;презентация “История моего поселка", посвященная улицам, достопримечательностям поселка;<br>проведение вечера загадок о растительном мире, птицах, животных родного края: "Путешествие в страну загадок”;<br>чтение, изучение татарских народных пальчиковых игр;<br>знакомство с произведениями разных авторов о родном крае: З. Туфайлова “Туган ил”, Р. Валиева «Туган илем», Р. Файзуллин “Наша страна”, г. Рахим “Наша гора” Н.Арсланов “Республика“, Г. Тукай «Туган авылым»;<br>Развлечение: “Моңлы минем туган ягым” с родителями и детьми;<br>Рисование: «Мой дом», «Край родной!»; «Праздник урожая в нашем поселке»; «Милли киемнәр»<br>Аппликация: “Дома на нашей улице”<br>Дидактические игры, знакомящие с природой родного края: «Из какого дерева», «Найди животных, живущих в нашем | 0ктябрь |

| | | |
|---|---|---|
| | лесу», «Когда это произойдет» Игры для национально-культурного воспитания детей, ознакомления их с национальной одеждой татарского народа, их оформлением: «Читекне бизә»; «Алъяпкычны бизә», «Курчакларны киендер»;<br>Татарские народные игры: “Миңлебай”, “Парлашу”, “Әтәчле”, “Буяу сатыш, “Кап та коп”, “Кем җитезрәк” | |
| Работа с воспитателями | Обсуждение цели и задачи проекта; формировать интерес по созданию условий для реализации проекта;разработка и накопление методических материалов, рекомендаций по приобщению детей к творчеству писательницы, к творчеству родного края;подбор книг по творчеству наших земляков;<br>консультация для воспитателей: «Как знакомить детей с жизнью и творчеством наших земляков» | |
| Работа с родителями | Анкетирование родителей по изучению чтения книг.<br>Папка-передвижка: «Советуем прочитать». Макет улицы поселка (совместно с детьми). Пошив одежды для национальных кукол | |

**Заключение**

На основании этого проекта и полученных результатов можно сделать выводы: цель, поставленная нами, достигнута, мы расширили кругозор детей и познакомили с творчеством нашего земляка, стали больше любить и ценить нашу малую Родину.

Перспективы дальнейшей работы:

1. Продолжить изучение творческого наследия поэтов нашей малой Родины.
2. Организовать литературную встречу с участием наших земляков.

**Список литературы**


1.Аниса Минхажева: «Сезгә кайтам бүлеп гомерне» (чәчмә әсәрләр), г. Альметьевск, 2011.

2. Дамир Гарифуллин: “Кикринур”, Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1985.

3. Т. С. Комарова “Занятия по изобразительной деятельности в подготовительной к школе группе детского сада. Конспекты занятий”; «МОЗАИКА СИНТЕЗ», 2011


## ТУГАН ЯГЫ КИРӘК КЕШЕГӘ

(ата-аналар җыелышы өчен чыгыш)


Харисова Илзирә Алмас кызы,
Иске Кәшер урта гомуми белем бирүмәктәбе, Сарман районы


Күренекле татар язучысы Гариф Ахуновның якташ язучыбыз Мәдинә Маликова хакында мондый сүзләре бар: “Сарман” дип әйтү белән, безнең хәтердә Илһам Шакиров яңара. Илһамы булган Сарман – бәхетле район. Әмма Сарман Илһамы белән генә түгел, Мәдинәсе белән дә атаклы бит әле ул”.

Районыбызның 90 еллыгын билгеләп үткән 2020 нче елда булган очрашуда әти-әниләребездән шушы сорауга җавап аласым килә: без үзебезнең якташларыбызны беләбезме? Алар белән балаларыбызны таныштырабызмы? Әдәбият белән кызыксынуыбыз ни дәрәҗәдә?

Сораулар күп, тик минә җавапларның куандырачагына шигем зур. Безнең район, чыннан да, бай, бәхетле район ул! Әдәбият дөньясында якты йолдыз булып яна торган язучыларыбыз да, шагыйрьләребез никадәр безнең. Сандугачлы Сарман данын еракларга

тараткан җырчыларыбыз да күп. Галимнәр, рәссамнар, журналистлар, артистлар да шактый. Тик сан артыннан куу түгел, аларның хезмәте турында балалар белүе мөһим бүген.

Монда инде безгә, укытучыларга, сезнең ярдәм кирәк. Мәктәптәге дәреснең вакыты чикле, мөмкинлекләре дә. Ә менә сез таулар күчерә аласыз. Балагыз белән бик аз гына вакыт китап алып укысагыз, газета-журнал битендәге материал белән бергә танышсагыз, рәсемнәрен карасагыз, сөйләп алсагыз, моның файдасы искиткеч булачак бит. Ышаныгыз. Дәрестә шулай теге яки бу язучы яки җырчы турында сүз барганда, баланың кул күтәреп: “Әйе, апа, минем әти дә шулай дип әйтә” яки “Апа, бу җырчыны мин беләм, әни белән әти аның җырларын тыңларга яраталар. Ул бит безнең районныкы”, - дип горурланып сөйләп киткән вакытлары күп була.

Бала күңеле – ул губка кебек. Барысын да күрә, барысын да сеңдерә. Соңга калмаска, ул күңелгә яхшылык, изгелек кебек сыйфатлар белән бергә үз ягыңның патриоты булырга омтылыш, кызыксынучанлык, милли горурлык хисләре дә салырга иде.

Сәнгатьнең тагын бер төре зур тәрбияви әһәмияткә ия. Ул да булса театр сәнгате. Театрның көче турында Г.Тукайдан да дөрес итеп әйтеп булмас: “Театр яктылыкка, нурга илтә, бер дә сулга җибәрми, уңга илтә”. Шуңа да балалар белән бергә театрга барып спектакль карау – алыштыргысыз тәрбия сәгате булачак. Гыйбрәтле кеше язмышлары, үрнәк алырлык хәлләр турында күпме сәхнә әсәре бар бүген! Көчле театрларыбыз гөрләп эшли. Бары безнең кызыксынучанлык күрсәтүебез, үрнәк булырга теләвебез генә җитми.

Бүген без бөтен нәрсәне “Вакыт юк” дигән сылтауга аударып калырга тырышабыз. Ләкин бу юкка. Бүгенге көн ул иртәгә тарихка күчә, ә балага үрнәк бүген кирәк, эшчәнлек тә.

Бала күңеленә кечкенәдән нәселеңнең, туган ягыңның лаеклы дәвамчысы булырга кирәклекне сеңдерү мөһим. Моның өчен менә шушы атаклы якташларыбыз мисалы зур көч. “Иске Кәшер егете Зиннәт Хәсәнов турында бөтен дөнья белә”,- дип сөйлим мин. Ерак Германия төрмәләре рәсемнәрен, немецча язылган документларны күрсәтәм, Казандагы Муса Җәлил һәйкәле янындагы стелла белән таныштырам, китаплардан рәсемнәр карауны оештырам. Балалар күңелендә “Батырлык күрсәтсәң, илгә хезмәт итсәң, талантыңны үстерсәң, син хөрмәтле шәхескә әйләнәсең икән” дигән фикер тусын дип тырышам.

Музейларда булу, тарихи һәйкәлләрне барлау да нәтиҗәсез узмый. Анда бит никадәр байлык, хәтер хәзинәсе тупланган. Сезнең белән караган әйберләр бигрәк тә хәтердә калачак, онытылмаячаклар.

Бу юнәлештә нәтиҗәле эшләп килгән мәктәпләр бар. Минем икенче санлы Җәлил урта мәктәбе коллективына, “Шушы яктан, шушы туфрактан без” проектына рәхмәт сүзләрен җиткерәсем килә. Бу проект буенча ел саен без бер якташ язучыбыз иҗаты яктыртыла анда. Эзләнү-тикшеренүгә, фантазиягә, иҗатка юл ачыла. Быел менә фәнни бәйге якташыбыз Мәдинә Маликова иҗатына багышланды. Балалар белән бергәләп һөнәр ияләре турында макетлар ясап, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалаучы плакатлар, рәсемнәр төшереп була, фәнни-эзләнү эшләре алап барырга да мөмкин. Эшкә бер керешергә генә кирәк бит ул. Җиң сызганып тотынган эш, күмәк хезмәт һәврвакыт яхшы нәтиҗәләргә китерә.

Балалар белән көндәлек матбугатны да күзәтеп баруны гадәтләндерү яхшы. Бүген эчтәлекле язмалары белән куандырган газета-журналлар мул бит.

(Китап киштәсе) Менә бу күргәзмәгә мин якташыбыз Мәдинә апа эшләгән «Сөембикә» журналы номерларын урнаштырдым. Бик эчтәлекне, зәвыклы журнал ул бүген.

Бала тәрбияләүдә ваклыклар булмауны аңлап бетермәсәгез, язучының «Егетлеккә бер адым»,«Оҗмах балалары» әсәрләрен алып укыгыз. Кеше ялгышын төзәтүнең авырлыгын аңлау, сак булу өчен «Чәчкә балы» повесте ярдәм итә. Ул бердәмлеккә өйрәтә, авырлыкларның бердәмлек алдында бирешәчәген күрсәтә.

Кешегә үрләргә менүен сөйләр өчен, кыенлыкларны җиңәр өчен туган ягы кирәк. Ә безнең туган җиребез Сарман җырлы да, әдәбиятлы да, тырыш хезмәтле дә. Шул сыйфатларны җуймый торган буынның язмышы безнең һәм сезнең кулда.

## ФИГЫЛЬ ҺӘМ АНЫҢ НИГЕЗЕ

Хафизова Айсылу Дамир кызы,
Советлар Союзы Герое А.А.Казаков исемендәге Александровка төп гомуми белем бирү мәктәбе,Сарман районы

**Максат:** фигыль турында белемнәрне актуальләштерү һәм тирәнәйтү, укучыларның танып-белү эшчәнлекләрен активлаштыру, мөстәкыйль фикер йөртүгә юнәлтү.

**Бурычлар:** укучыларны актив аралашуга, иҗади сөйләшүгә тарту, эзлекле итеп уйларга һәм сөйләшергә өйрәтү, сүзлек запасын баету.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

**Предмет нәтиҗәләре:** фигыльләрне эшне,хәрәкәтне,хәлнебелдерүче фигыльләргә бүлү, фигыль нигезе турында төшенчәне, нигезнең тамыр һәм ясалма булуын белү, фигыль нигезен дөрес билгели белү

**Шәхси нәтиҗәләр:** туган телебезгә карата кызыксыну уяту, укуга җаваплы карау.

**Танып-белү УУГ:** уку проблемасын билгели һәм аны чишү юлларын төзи алу, рәсемнәр ярдәмендә сорауларга җавап таба белү.

**Коммуникатив УУГ:** үз фикереңне әйтә һәм дәлилли белү, төркемнәрдә килешеп эшли белү.

**Регулятив УУГ:** максат куя һәм уку бурычларны билгели алу, уку эшчәнлеген оештыра белү, үзбәя кую күнекмәләренә ия булу.

**Дәрес барышы:**

| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге | Универ саль уку гамәлләре |
|---|---|---|---|
| **Оештыру. Мотивлаштыру** (2-3 минут) | Исәнләшү. Уңай психологик халәт тудыру, дәреснең эпиграфы белән таныштыру. Эпиграф итеп шигырь бирелә.<br>Мәрхәмәтле бул син туган телгә,<br>Ихтирамлы бул син сүзләргә,<br>Сүзне кирәк мәңге яңартырга,<br>Сүзне кирәк мәңге эзләргә.<br>Әңгәмә оештырыла. | Исәнләшәләр. Дәрескә әзерлекне күрсәтәләр, эпиграф белән танышалар, сорауларга җавап бирәләр. | **ШУУГ**: туган телебезгә карата кызыксыну уяту<br>**КУУГ**: тыңлый һәм җавап бирә алу |
| **Актуальләштерү** | Укучыларга сүзләр бирә. Шул сүзләрне сүз төркемнәренә аерып язарга кирәк. **Сыйфат исем .....**<br>(өй - өй, тырыш - тырыш, җиң - җиң, кыр - кыр, ал- ал)<br>Ни өчен бу сүзне әлеге баганага яздыгыз?<br>Сез бу сүз төркемнәренең кайсысын өйрәндегез?<br>Нинди сүз төркеме ул исем, сыйфат? | Сүзләрне сүз төркемнәренә аералар.<br><br>Кайберләрен аерганда авырсыналар.<br><br>Укучылар сорауларга җавап бирәләр. Исем, сыйфат сүз төркемнәре турында белгәннәрен әйтәләр. | **ШУУГ:**татар теленең бай тел икәнлеген аңлау<br>**ТБУУГ**: гомумиләштерүләр ясау, нәтиҗә чыгару<br>**КУУГ:** фикерләрне төгәл һәм тулы итеп әйтеп бирә белү<br>**РУУГ**: эшчәнлекне оештыру |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Уку мәсьәләсен кую** | Күпнокталар куелган урында нинди сүз төркеме булыр?<br><br>Димәк, без бүген нинди сүз төркемен үтәчәкбез?<br><br>Ни өчен сез бу сүзләрне фигыль сүз төркеменә карый дип уйлыйсыз?<br><br>Нинди сүз төркеме ул фигыль?<br><br>Сез аның турында нәрсәләр беләсез?<br><br>Укучылар, һәр эшне башлар алдыннан без үзебезгә максат куябыз. Әйдәгез, без дә үзебезнең эшебезне башлар алдыннан дәрескә максат куйыйк әле. Сезнең алдыгызда кәгазьләр ята. Шуларны тутырыйк әле. (Кушымта №1)<br><br>Укучылар, экрандагы рәсемнәргә игътибар итик әле. Биредә балалар нишли? | Укучылар күпнокталар урынында фигыль сүзе торырга тиешлеген әйтәләр.<br><br>Чөнки бу сүзләр эшне белдерә тоган сүзләр<br><br>Эшне белдерә торган сүз төркеме, нишли? нишләде соравына җавап бирә.<br><br>Укучылар таблицаны тутыралар. Максатларны билгелиләр.<br><br>Укучылар җавап бирә: агач утырта (эшли), йөгерә (хәрәкәт итә), йоклый (хәлне белдерә).<br>Фигыль – эшне, хәрәкәтне, хәлне белдерә, нишли? соравына җавап бирә | **ШУУГ:** үз алдыңа максат кую, аңа ирешү юлларын эзләү<br>**ТБУУГ:** уку мәсьәләсен аңлау, нәтиҗә чыгару<br>**КУУГ:** сорауларга җавап бирә белү<br>**РУУГ:** уку мәсьәләсен куя белү, планлаштыру |
| **Уку мәсьәләсен адымлап чишү.** | Фигыльгә билгеләмә бирик.<br><br>Рәсемдәге фигыльләрне кертеп, җөмләләр төзегез. Баш кисәкләрен билгеләгез. Нәтиҗә ясагыз<br>Дәрес башында бирелгән фигыльләргә яңадан әйләнеп кайтабыз. Бу сүзләрне тагын да ваграк кисәкләргә таркатып буламы? Кушымчалар өстәп буламы?<br>Ничек уйлыйсыз, фигыльнең әлеге өлеше нәрсә дип аталыр? Укучылар нигез сүзен әйтә алмасалар, алдан әзерләнгән фигуралардан өй рәсеме ясатыла. Иң түбәнге өлешнең нәрсә дип аталуы әйттерелә. Өй нигезенә аска таба берни дә өстәп булмый, | Җөмләләр төзиләр. Ия һәм хәбәрен билгелиләр. Нәтиҗә ясыйлар: фигыль җөмләдә хәбәр булып килә.<br><br>Юк, булмый. Кушымчалар өстәп була.<br>Нигез турында төшенчәне китаплардан уку. Фигыльнең нигезе төп мәгънәне белдерүен, аны нишлә? соравы куеп табып булуын ачыклыйлар. Фигыль нигезенең ике төрле – тамыр һәм ясалма булын әйтәләр. Кагыйдәне укыганнан соң модуль төзиләр. | **ШУУГ:** максатка ирешү юлларын эзләү, мөстәкыйль фикер йөртү<br>**ТБУУГ:** өйрәнелә торган материалны аңлау, рәсемнәрдән чыгып, кагыйдәне әйтә белү, нәтиҗә ясау<br>**КУУГ:** әңгәмәдә катнашу, үз фикерләрен дәлилли алу<br>**РУУГ:** җавапларны контрольдә тотып, бәяли белү |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | ә өскә таба өеп була (стена, түбә һ.б.). Фигыльдә дә шулай. Нигезгә төрле кушымчалар ялгап була. | | |
| **Яңа теманы ныгыту. Беренчел ныгыту.** | Текст өстендә эшлибез. Текстны укыйбыз. Калын хәрефләр белән бирелгән фигыльләрнең нигезен билгелибез. Аңлашылмаган сүзләрне сүзлектән карыйбыз. (Кушымта № 2)<br><br>Экранда төрле фигыльләр язылган. Шуларны икегә - тамыр һәм ясалма нигезгә дөрес итеп бүләргә кирәк (тышла, тор, эшлә, буя, зурай, бәхәсләш, күр, чибәрлән, бел, дуслаш, тозла, уйла, җый, бизә, ал, чык) | Укучылар эшне индивидуаль башкаралар. Фигыльләрнең нигезен билгелиләр.<br><br>1 нче төркем – тамыр нигезле фигыльләрне, 2 нче төркем ясалма нигезле фигыльләрне генә язып ала. Бу фигыльләр белән җөмләләр төзиләр. | **ШУУГ:** төрле мәгълүмат чараларын куллану<br>**ТБУУГ:** үз эшчәнлекләрен мөстәкыйль рәвештә оештыру<br>**КУУГ:** коллектив фикер алуда катнашу<br>**РУУГ:** үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәле булуына ирешү |
| **Икенчел ныгыту.** | Экранда тест сораулары бирү. | Алдагы белемнәрне гомумиләштереп, үзтикшерү оештыру. Экранда бирелгән тест сорауларына җавап бирү. Укытучы күрсәткән критерийлар нигезендә дәрестә үз эшчәнлеген бәяли, билгеләр куя. | **ШУУГ:** алган белемнәрне куллана белү<br>**ТБУУГ:** үз эшчәнлеген мөстәкыйль рәвештә оештыру |
| **Өй эше.** | 196 нчы күнегүне эшләгез.<br>196 нчы күнегүдәге сүзләр белән 5 җөмлә төзегез.<br>Тамыр һәм ясалма нигезле фигыльләр кертеп, “Минем буш вакытым” темасына хикәя төзегез. | Өй эшенең аңлашылып бетмәгән урыннарын ачыклыйлар. | **ТБУУГ**: биремнәрне аңлау<br>**РУУГ**: эшчәнлекне оештыра белү, планлаштыру |
| **Рефлексия.** | Дәрес башында бирелгән кәгазьләрне алабыз. Без үзебезгә нинди максат куйган идек? Максатыбызга ирештекме? Сез фигыль турында нәрсәләр белә идегез? Бүген дәрестә үткәннәрне сез кайда куллана аласыз?<br>Дәрес тәмам, сау булыгыз! | Укучылар сорауларга җавап бирә. | **ТБУУГ**: нәтиҗә ясый белү<br>**КУУГ**: үз фикерләрен дәлилле итеп җиткерә белү<br>**РУУГ**: үзбәя бирү |

**Кушымта №1.**

| Мин нәрсәләр белергә телим | Максат | Мин нәрсәләр белдем |
|---|---|---|
| | Фигыльнең нинди сорауларга җавап бирүен искә | |

| | | |
|---|---|---|
| | төшерергә | |
| | Эштән кала, фигыльнең нәрсәләрне белдерүен ачыкларга | |
| | Фигыльнең нинди җөмлә кисәге булуын белергә | |
| | Фигыль нигезен таба белергә | |

**Кушымта №2**

Гамил исә, Таллыга баруга, хастаханәгә юнәлде. Андый чакта, ятлар каршына барып басканчы, якын кешеңне тыңларга, нәрсәнең ничек булганын аннан ишетергә кирәк.

...Аның соргылт-ак күлмәге аркылы очлаеп беленеп торган калак сөякләрен күргәч, күңелне кызгану хисе көйдереп узды. (Мәдинә Маликова)

## МӘДИНӘ МАЛИКОВАНЫҢ ИҖАТЫН МӘКТӘПТӘ УКЫТУ ТӘҖРИБӘСЕ ҺӘМ ӘСӘРЛӘРНЕҢ ТӘРБИЯБИ ӘҺӘМИЯТЕ

Хафизова Румия Әбүзәр кызы,
Бөгелмә шәһәренең 6 нчы урта мәктәбе

Мәдинә Маликова – күпкырлы шәхес. Аның тормышы һәм иҗат юлы сокландыргыч. Ул, заман тормышының төрле өлкәләренә мөрәҗәгать итеп, геройларның рухи дөньясын бөтен тирәнлеге белән яктыртырга, кешеләр арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрнең нечкәлекләрен ачарга омтыла, яшәешнең мәгънәсен яхшылыкка, матурлыкка хезмәт итүдә күрә. Шулай ук әдипнең әхлак темаларына багышланган әсәрләре киң яңгыраш таба. Бу тема бүгенге көндә дә актуаль, чөнки тәрбия темасы язучыларны генә түгел, һәр ата-ананы, җәмгыятьне дә уйландыра, борчый торган мәсьәлә. Безнең киләчәгебез кем кулында? Ул өметлеме? Гаиләдән килгән тәрбия бүгенге көндә ныклымы? Яшьләр бу болгавыр заманда үз урыннарын таба алырлармы? Татар телендә балаларыбыз сөйләшерме, татарча әсәрләр укырлармы? Менә шушы сораулар кешеләрне, шул исәптән мине дә, борчый.

Мәдинә Маликованың тормыш һәм иҗат юлы белән кызыксыну мине фәнни-гамәли эшенә этәрде. Ул татар әдәбиятында зур урын алып торган әдипләрнең берсе. Фәнни эзләнү эшемнең объекты – Мәдинә Маликова. Предметы – Мәдинә Маликованың әсәрләре.

Эшемнең **максаты** – Мәдинә Маликованың тормышы һәм иҗаты белән танышып чыгу һәм аның тәрбияви әһәмиятен билгеләү. Максаттан чыгып, түбәндәге **бурычлар** куелды: Мәдинә Маликованың тормыш юлына һәм иҗатына караган материалны барлау, туплау, системалаштыру; әдипнең каләмдәшләре язган истәлекләр, хатирәләр белән таныштыру, Мәдинә Маликованың әхлак темасына язган әсәрләрен укучыларга җиткерү.

Хикәяче, романчы, драматург, публицист Мәдинә Маликованың тормышын өйрәнү, яшь буынга җиткерү бүгенге көндә **актуаль** дип саныйм.

Эшемнең **структурасына** килгәндә, фәнни эзләнү эше кереш тән, төп бүлектән, йомгак һәм файдаланылган әдәбият исемлегеннән тора.

## БИК БӘХЕТЛЕ ЯЗУЧЫ

Хәертдинова Гөләмзә Әхмәтҗан кызы, Җәлил беренче урта гомуми белем бирү мәктәбе
Хәертдинова Аида Альберт кызы, Җәлил гимназиясенең тарих укытучысы,
Сарман районы

Мәдинә Маликованың тормышы һәм иҗат юлы сокландыргыч. Ул гомере буе җәмгыять эшләрендә, иҗади эзләнүләрдә, төрле иҗтимагый хәрәкәтләрдә актив катнаша. Ул гомуми бер сәяси тормышта үзенең иҗади юлын башлап җибәрә. Аннан үзгәртеп кору чорының иҗтимагый-сәяси һәм милли проблемалар белән кызыксына, ә соңгы елларда аның

күп кенә романнары барлыкка килә. 1990 нчы елларда ул, Кызыл Ай җәмгыятен оештырып, дистәдән артык ел буена аның президенты булып эшләп килә.

Мәдинә Маликова беренче әсәрен 6 нчы сыйныфта укыганда язып, укытучысына күрсәтә. Бу әсәр сугыш вакытында бер пионерның отряд флагын фашистлардан яшереп алып калуы турында була. Сәхнәдән үзе чыгарган шигырьләрне дә укый торган була.

Мәдинә Маликова – Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, журналистларның Хөсәен Ямашев исемендәге республика премиясе лауреаты

«Оҗмах балалары» трагикомедиясе күпләрнең күңелен яулап ала. Әсәрдә күтәрелгән проблемалар бөтенебезне дә борчый. Бүген без киләчәгебезне төзибез, тик без дөрес юлдан барабызмы? Балаларыбызга тиешле игътибар бирәбезме? Аларны укытучылар кулларына, мәктәпкә, җәмгыятькә тапшырып бетермәдекме? Безнең балаларыбыз бәхетлеме? Алар ялгыз түгелме?

Без бүген дә нәкъ шушы сорауларга җавап эзлибез.Әйе, пьесада космос та бар, хыял да бар. Ләкин төп проблемалар җирдәге, бүгенге көндә ата-ана һәм бала мөнәсәбәте, гаилә һәм тәрбия нигезләре турындагы социаль әчтәлек алган мәсьәләләр.

Без бөтенебез дә балалар – тормыш чәчәкләребез – гаиләдә, әти-әнисе,туганнары белән бергә үсәргә тиеш дип уйлыйбыз.Ә ник соң балалар йортында балаларның саны артканнан-арта һәм аларның бик сирәге генә чын ятим, күбесенең әти-әнисе исән-сау. Моңа кем яисә нәрсә гаепле? Әсәр шул турыда уйландыра.

Мәдинә Маликова иҗаты татар әдәбиятында үзенең лаеклы урынын алды. Күренекле әдибебез киләчәктә дә яңадан-яңа әсәрләре белән укучыларны куандырыр дип, чын күңелдән ышанасы килә. Иң әһәмиятлесе шул: мөхтәрәм язучыбызның басып сайрар талы бар. Ул — аны яраткан, хөрмәт иткән халкыбыз.

## МӘДИНӘ МАЛИКОВА ТОРМЫШЫ ҺӘМ ИҖАТЫНА БАГЫШЛАНГАН КВН

(Педагоглар арасында)

Хәлиуллина Рузилә Рубирт кызы,
Җәлил бистәсенең 6 нчы номерлы балалар бакчасы тәрбиячесе, Сарман районы

**Максатлар:** Мәдинә Маликова тормышы һәм иҗаты буенча белемнәрне ныгыту, язучының әсәрләренә кызыксыну уяту. Якташ язучылар иҗатын өйрәнүне дәвам итү. Туган ягыбызга карата горурлык хисе тәрбияләү, аны ярату, туган җиребезгә мәхәббәт тәрбияләү.

**Кирәкле җиһазлар:** Мәдинә Маликова портреты, китаплар күргәзмәсе.

**Алдан эшләнгән эш:** Мәдинә Маликова тормышы, иҗаты һәм әсәрләре белән танышу, педагоглар өчен “Мәдинә Маликова тормышы һәм иҗатына” дигән консультация әзерләү, китаплар күргәзмәсе оештыру.

**Уен барышы:**

**1 нче алып баручы:** (Дамир Гарифуллинның “Күкрәп яшә, Сарманым” шигыреннән өзек уку). Сарман районы үзенең мәшһүр җырчылары, бию осталары, язучылары, шагыйрьләре, театрда уйнаучы артистлары белән данлыклы. Шуларның берсе - хикәяче, романчы, драматург, публицист Мәдинә Маликова. Аяз Гыйләҗев билгеләгәнчә, М. Маликованы “зыялы язучы” дияргә була.

**2 нче алып баручы:** Язучы каләме, заман тормышының төрле өлкәләренә мөрәҗәгать итеп, әсәр каһарманнарының рухи дөньясын бөтен тирәнлеге, каршылыклары белән яктыртырга, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең катлаулы нечкәлекләрен, нокталарын ачарга омтыла, яшәешнең төп мәгънәсе һәм максаты турында укучы белән җитди әңгәмә алып бара.

**1 нче алып баручы:** Хөрмәтле педагоглар, килгән кунаклар, без сезнең белән шушы мәшһүр язучыбыз турында белемнәрне тагын да тулыландырырга - КВН үткәрергә җыелдык.

**2 нче алып баручы:** Бүген була КВН

Гаҗәп, күңелле уен.

Педагоглар көч сынаша,

Менә була тамаша!

**1 нче алып баручы:** Бу уенда үзебезнең педагогларыбыз көч сынаячаклар. Әйдәгез әле, алкышлар белән уенчыларыбызны бирегә чакырыйк. "Юлдашлар" һәм "Оҗмах балалары" командалары бирегә рәхим итегез. (Һәр командада 3 әр педагог катнаша).

**2 нче алып баручы:** Безнең командаларны бәяләп баручы жюриларыбыз да бар. (Жюри составы белән таныштырыла)

**1 нче алып баручы:** Уеныбызны өй эше тикшерүдүн башлап җибәрәбез. (Өй эше итеп М. Мадикова эсәреннэн өзекне сүхнәләштерү бирелә).

**2 нче алып баручы:** Булдырдыгыз, афәрин! Жюри 1нче турга үзенең бәясен куяр. Без 2нче турга күчәбез. 2нче тур - "Сорау бездән, җавап сездән" дип атала. Сезгә Мәдинә Маликова тормышы һәм иҗаты буенча сораулар бирелә. Сез шул сорауларга җавап бирергә тиеш буласыз (һәр командага 4 әр сорау бирелә).

<u>"Юлдашлар" командасына сораулар:</u>

1.М. Маликова кайчан һәм кайда туа?.

2.Институтны тәмамлагач, ул нинди журналларда эшли? .

3.М. Маликова укудан тыш нинди түгәрәкләргә йөргән?

4. М. Маликова гаиләдә кем?

<u>"Оҗмах балалары" командасына сораулар:</u>

1.М. Маликова нинди гаиләдә дөньяга килә?

2.Язучының беренче хикәяләр җыентыгы ничек атала?

3.Язучының беренче гонорары ничә сум булган?

4. М. Маликованың яраткан шөгыле тагын нәрсә?

**1 нче алып баручы:** Безнең уенчыларыбыз бик күп беләләр. Афәрин, Афәрин! Уеныбызның 3нче туры "Бер-бер артлы сана" дип атала. Командалар бер-бер артлы язучыбызның әсәрләрен әйтешәләр, чират кемдә кала – шул команда җиңелә. Уеныбызны "Юлдашлар" командасы башлап җибәрсен әле.( «Өермә», «Көмеш билбау», «Берәгәйле бәрәңге», «Арыш тәме», «Юлдашлар», «Хөкем», «Адашканга юл кайда?», «Янартаулар яктысында», «Язгы такыялар» , «Кар сулары», «Сары тюльпаннар», «Көндәшләр», «Ай сүрелгән чак иде», һ.б.)

**2 нче алып баручы:** Безнең хөрмәтле жюри әгъзалары бу ярыш өчен үзләренең бәяләрен куяр. Э без әзрәк ял итеп алыйк. "Музыкаль тукталыш"("Сарман"җырын тыңлау).

**1 нче алып баручы:** 4нче турга күчәбез. Хөрмәтде педагогларыбыз, бу тур "Дөрес әйт" дип атала. Сезнең бурычыгыз – укылган шигырь юлларының кайсы әсәрдән икәнен билгеләү.

Нурга төренгән фәрештә –

Аһ, сөю, әллә синме?

Бер кулыңда – баллы касә,

Берсендә – утлы сөңге... ("Тылсым" романыннан)

**2 нче алып баручы:** Һаваларда очкан аккошларның

Каурыйлары коела җилләргә, лә;

Туфрагына алтын чәчсәләр дә,

Җитми икән туган илләргә.( "Оҗмах балалары" әсәреннән)

Бу җырны кем җырлый? (Гөлнур җырлый).

**1 нче алып баручы:** Һәм соңгы сорау: Мәдинә Маликова тагын нинди һөнәр иясе булырга тели? (-Бизнесмен булыр идем, - ди язучы. -Өлешчә шуның белән шөгыльләнәм дә. Китапларымны сатам. Укытучы итеп тә, табиб буларак та үземне күз алдыма китермим. Ә

бизнесмен итеп китерәм. Ялгышсаң да, зыяны үзеңә генә. Ә менә укытучы, табиб һөнәре кеше тормышын, язмышын хәл итә бит).

**2 нче алып баручы:** Уен турлары тәмам. Нәтиҗәне чыгарыр өчен сүз жюрига бирелә.

**1 нче алып баручы:** Татар халкының чишмә башы аның борынгыдан килгән халык авыз иҗатында, җырларында, шигырьләрендә, әкиятләрендә, әсәрләрендә чагыла. Чишмәләрне карап, сафландырып тормасаң, алар матурлыкларын, муллыкларын югалталар, агуларыннан туктыйлар.

**2 нче алып баручы:** Шуның кебек үк чишмә башы булган әсәрләребезне дә сакламасак, яңаларын өстәмәсәк, телебез, милләтебез дә алга баруыннан туктар иде кебек, - дип язып киткән Бөтендөнья татар конгрессы кысаларында эшләп килүче «Ак калфак» җәмгыятенең Алексеевскидагы җирле җитәкчесе Алсу Нәҗметдинова үзенең Мәдинә Маликова белән очрашу турындагы язмасында.

**1 нче алып баручы:** Хөрмәтле педагогларыбыз, килгән кунаклар, якташ язучыларыбызны онытмыйк, аларның иҗаты белән танышып торыйк. Якташ язучыларыбыз белән горурланыйк!

**Кулланылган әдәбият:**

1. Ахунов Г. Сарман кызы Мәдинә // Шәһри Казан. – 1995. – 12 авг.

2.Журналның Мәдинә Маликова иҗатына багышланган махсус саны // Мәйдан. – 2004. – № 7. – 4–188 б.

3. Хисмәтова Л., Ханнанов Р. Һәр әсәре – тәрбия дәресе // Мәгърифәт. – 2007. – 14 апр.

## ТӨСЛЕ СҮЗЛӘР

(укытучылар өчен мастер-класс)

Һадиуллина Гөлнара Әкмәлетдин кызы,
Сарман гимназиясенең башлангыч сыйныфлар укытучысы

**Максат** : тәэсир итү көче буенча сүзләрне төркемнәргә булеп карау

**Бурычлар:** М.Маликова иҗатында төрле төркемгә кергән сүзләрне табу, су малекуласының төрле сүзләргә мөнәсәбәтен карап үтү, сөйләм теле, сүз турында татар халык мәкальләрен искә төшерү.

**Җиһазлау:** М.Маликованың «Язгы такыялар» повесте (3-4 данә), синонимнар, антонимнар язу өчен таблицалар (15 данә), презентация

**Эшчәнлек барышы**

**Оештыру өлеше.** Хәерле көн, исәнмесез, хөрмәтле коллегалар! Бүгенге эшчәнлегебезне күренекле татар шагыйре ГамилАфзалның түбәндәге шигыре белән башлар идем:


Хак сүз, нык сүз тамырларга үтә,
Тимер иман кебек була сүз.
Күп сөйләгән сүзнең кадере китә,
Иске чүпрәк кебек уңа сүз.


**Эшчәнлек темасын билгеләү**

Димәк,сөйләшүебез СҮЗ турында барачак. Сүз әйтеп бетергесез көчкә ия икәнлеген барыбыз да беләбез. Бигрәк тә укытучы сүзе ул - дару да, чәчәк букеты да, җылы түшәк тә, шул ук вакытта пычак та була ала. Дөньякүләм танылган галимнәр сүзнең хәтта су малекуласына да тәэсире барлыгын ачыклаганнар. Шундыйларның берсе-профессор Константин Коротков.

**Эшчәнлек темасы буенча сөйләшү**. К.Коротков фикеренчә, нинди сүз ишетүенә карап, су малекуласы билгеле бер форма ала.

Түбәндәге рәсемнәрне карап үтик:


 “Яратам”  “Рәхмәт”  ”Әйбәт”

 “Син җүләр”  “Син мине туйдырдың”

Бу фактлардан күренгәнчә, сүзнең көче гаять зур.

Галимнәр фикеренчә, кеше көне буена 4 мең ярым сүз әйтә икән, ә хатын-кызлар – күбрәк тә. Ләкин күп сөйләү сөйләмнең матурлыгын, сыйфатын күрсәтми. Безнең телебез бай, матур, аңлаешлы булырга тиеш. Без, укытучылар, балаларны да шуңа өйрәтергә бурычлы.

**Практик өлеш**. Сүзләрнең мәгънәләре булган кебек, төсләре дә булырга мөмкин икән. Кызык бит, әйеме? Сүзләрне, төсләренә карап, шартлы рәвештә төркемнәргә бүлеп була. Сүз остасы, якташыбыз, күренекле язучы, Г.Тукай исемендәге премия лауреаты Мәдинә Маликова иҗатында элеге төркемнәрне карап үтәрбез. Беренче төркемсүзләрне табу өчен рәсемнәргә карагыз әле:

Нинди сүзләр турында сөйләшербез һәм алар нинди төстә булыр? (Фикерләр тыңлана) Ана елаган баласын юату өчен нинди сүзләр әйтә? Теш табибы авыруны ничек тынычландыра?

**Җылы сүзләр**

Аларны без сары төсләр диярбез. Ни өчен икән? (Сары, чөнки кояш нурларының җылысы белән чагыштырып була)

Туган төбәгебез язучысы Мәдинә апа Маликованың иҗаты безгә таныш. Бүген без «Язгы такыялар» повестеның “Нигә ул җыр искә төшә икән” исемле кисәген искә төшерербез. Өзектән җылы (сары ) сүзләрне эзләү (төркемнәрдә эш)

Игелекле бул, балакаем
Рәнҗеп китмә инде
Укырга ярдәм итәрбез
Мең-мең рәхмәт әйтеп яшә:

Исәнмесез

Нәтиҗә: язучы Мәдинә апа җылы сүзләргә бик еш мөрәҗәгать иткән. Чынлап та, матур сүзләрне кызганмыйк, адәм баласының күңеле җылылык эзли, юату көтә.

Икенче төркем сүзләрне шулай ук рәсем аша табарга кирәк булачак. Нинди сүзләр турында сөйләшербез? Алар нинди төстә булыр? (Фикерләр тыңлана)

Әйе, борынгы әби-бабаларыбыз әйтеп калдырган канатлы сүзләр – мәкальләр турында сөйләшербез. Мин аларны **кызыл сүзләр** дип атар идем. Чөнки кан түгеп җыйган тәҗрибәләре аша әйтелгән сүзләр бит алар! Гасырлар үтсә дә, бу сүзләрнең дөреслеге кабат-кабат исбатлана. Шул кадерле фикерләрнең сүз турында барганнарын искә төшереп үтәрбез.

*“Ахырын тап”уены – фронталь оештыру*

Ашның мае бар, сүзнең җае бар

Авызың кыек булса да, сүзең туры булсын.

Сүзең кыска булсын, кулың оста булсын.


Әйдәгез әле, Мәдинә апа иҗатына тагын мөрәҗәгать итик. Бу әсәрендә ул нинди мәкаль һәм әйтемнәр кулланды икән? (төркемнәрдә эш)

Үги бозау асрасаң, авызың-борының май булыр, үги бала асрасаң, авызың-борының кан булыр.

Ятимнең авызы ашка тисә, борыны каный.

Ятимнең догасы изге була.

Нәтиҗә: кечкенә генә бер әсәрдә күпме мәкаль кулланылган. Шуңа күрә дә Мәдинә апа Маликованың әсәрләре яратып укыла торгандыр. Алар халыкчан, гади һәм ,аңлаешлы, барыбызга да якын тел белән язылган.



Өченче төркем сүзләрне мин **кара сүзләр** дип атар идем .

-Ничек уйлыйсыз, телебездәге нинди сүзләр кара төстә булыр? (Фикерләр тыңлана- ямьсез, начар, сүгенү сүзләре һ.б.)

*Алдан таратылган таблицалар белән парларда эш*

| **Кара сүз** | |
|---|---|
| синонимнар | антонимнар |
| | |

Тормыш булгач, менә шундый кара сүзләр кулланган очраклар да була шул. Алар телебездә күп булмасын иде! Кара сүзләрне мин авыру таратучы вирус белән тиңләр идем. Вирус кергән организм сәламәт булмаган кебек, кара сүзләр булган сөйләм дә авыру була.

Текст белән эшләвебезне дәвам итәбез. Автор кара сүзләрне кулланганмы? (Төркемнәрдә эш: тексттан кара сүзләрне табу: томана, надан)

Ни өчен автор Мәдинә апа Маликова бу сүзләрне кулланды икән?(Фикерләр тыңлана: Рәйсәнең үзен өстенрәк, акыллырак итеп күрсәтәсе килә)

Кара, ягъни начар сүзне халык элек-электән сөймәгән. Әйдәгез, аларның әйткән сүзләрен, мәкальләрне искә төшерик әле. *(“Ахырын әйт “уены - фронталь)*

Теле пычракның- күңеле пычрак

Тозсыз сүздән тозлы ботка тәмлерәк

Яхшыны ишетәсең килсә, яман сөйләмә

Нәтиҗә: телебезне кара сүзләр белән бозмыйк! Болай да кыска гомерне начар сүзләр әйтешеп ямьсезләмик. Кеше рәнҗетүләрдән сак булыйк.

**Йомгаклау өлеше.** Эшчәнлегебез ахырында Г.Шәрипова шигырен укып үтәсем килә. «Рәнҗетмәгез усал сүзләр әйтеп...»

Хөрмәтле коллегалар! Кара сүзләрдән арынасыгыз килсә, шундый кагыйдә буенча яшәргә кирәк: **Нәрсә әйткәнеңне, кемгә әйткәнеңне, кайчан әйткәнеңне, кайда**

**әйткәнеңне, нинди сүз әйткәнеңне уйлап әйт.** Сүзнең чыпчык түгеллеген дә онытма! Хезмәттәшлегегез өчен рәхмәт!

## ГАРӘП-ФАРСЫ АЛЫНМАЛАРЫН КАБАТЛАУ

Шайхулова Гөлназ Фаяз кызы,
Яңа Кәшер санатор интернат-мәктәбе, Әлмәт районы

**Максат**: Телебездәге гарәп-фарсы алынмалары турында өйрәнгәннәрне гомумиләштереп кабатлау.Иҗади фикерләргә, белемне башкалар белән уртаклашырга өйрәтү, күзәтү, хәтерләү, игътибар итү сәләтен үстерү; М. Маликованың «Чәчкә балы» әсәрен укып, биремнәрне үтәү. Татар әдәбиятына карата кызыксыну уяту.

**Көтелгән нәтиҗә:** Метапредмет. Тексттан фактик мәгълүматны аерып алу; төркемнәрдә эшләү; үз фикереңне төгәл һәм ирекле җиткерә белү.

<u>Предмет</u>. Гарәп-фарсы алынмалары турында белү, гәрап-фарсы алынмаларына караган билгеләрне аерып чыгару.

<u>Шәхескә кагылышлы</u>. Эстетик зәвык булдыру, матур әдәбиятка кызыксыну уяту.

**Дәрес тибы:** гомумиләштереп кабатлау, проеклар яклау.

**Җиһазлау:** компьютер презентациясе ”Гарәп-фарсы алынмалары”.

**Дәрес барышы:**

**I Оештыру моменты.** Укучыларда уңай психологик халәт булдыру, эшләргә теләк уяту.

<u>Укытучы:</u> Исәнмесез, укучылар. Татар теле дәресебезне башлыйбыз. Безнең бүген гарәп-фарсы алынмалары буенча семинар дәрес – проектлар яклау дәресе. Сез үзегез әзерләгән проектларны яклаучы, ә мин сезнең фәнни җитәкчегез булырмын.

**II. Белемнәрне актуальләштерү.**Укучылар, сезгә өй эшенә нинди бирем бирелгән иде?

М. Маликованың «Чәчкә балы» әсәре буенча гарәп-фарсы алынмаларына карата проектлар әзерләргә.

Әйе, 5 төркемгә 5 тема бирелгән иде. Һәр төркем үзенә бирелгән теманы атап чыксын әле.

1 нче төркем: М. Маликованың «Чәчкә балы» әсәре турында.2 - 3нче төркемнәр: Әлеге әсәрдә кулланылган гарәп-фарсы алынмаларыннан сүзлек төзү. 4 нче төркем: үзебез тапкан гарәп-фарсы сүзләренең сингармонизм законына буйсыну һәм буйсынмавын ачыклау.

5 нче төркем гарәп-фарсы сүзләрен аеру үзенчәлекләре.

Менә без якланачак проектларның исемнәрен атап үттек.

**III. Дәреснең темасын, максатын җиткерү.**

– «Чәчкә балы» повестеның эчтәлеген искә төшерик әле. Ике-өч сүз белән әсәрнең нәрсә турында икәнен билгелик. (Укучылар фикере тыңлана): мәхәббәт турында, хыянәт турында, күңел сафлыгы,җан пакълыгы турында, гаилә бәхете һәм бәхетсезлеге турында, бала язмышы турында, ата-ана һәм бала мөнәсәбәте турында, рухи кыйммәтләр һ.б

Хәзер һәр төркем үзенең эше белән башкаларны таныштырырга тиеш. Уңышлар сезгә, укучылар.

1 **нче төркем** М. Маликованың «Чәчкә балы» әсәре турында сөйли.

Ә бүгенге дәрестә безнең алга куелган бурыч, әлеге әсәрдә кулланылган гәрап-фарсы алынмаларын аерып алып, аларны туплап, сүзлек төзү. Әгәр дә сораулар булмаса, беренче төркемнең эшен тәмамлап, сүзне 2 нче төркемгә бирик. (2-3нче төркемнәр экранда үзләре төзегән сүзлекне тәкъдим итәләр).

2-3 нче төркемнәрнең эшләре бик уңышлы чыккан. Хәзер инде сүзне 4нче төркемгә бирик.

4 нче төркемнәр үз эшләрен уңышлы гына башкарып чыкканнар. Әгәр дә сораулар булмаса, сүзне 5 нче төркемгә бирик.

**5 нче төркем** гарәп-фарсы сүзләрен аеру үзенчәлекләре.

Гарәп һәм фарсы телләреннән кергән сүзләр

Бу телләрдән кергән сүзләр сөйләмебездә зур урын алып торалар. Идел Болгар дәүләте 922 елда Ислам динен кабул иткәннән соң, гарәп җиреннән бик күп укымышлылар, сәүдәгәрләр, сәяхәтчеләр кучеп килгәннәр. Болгарда күпләп мәдрәсә-мәктәпләр, мәчетләр салынган. Халыкны гарәп язуына һәм теленә өйрәткәннәр. 13-14 нче гасырларда Алтын Урда һәм гарәп илләре арасындагы сәүдә мөнәсәбәтләре тагын да көчлерәк үскән бер чорда галимнәр, шагыйрьләр әсәрләре аша гарәп һәм фарсы сүзләре тагын да күбрәк кергән һәм шактый иркен кулланыла башлаган. Алынма сүзләр телебездә шулкадәр киң кулланылган, тора-бара аларның читтән кергән сүзләр икәнлеге беленми дә башлаган. Мәсәлән, **гарәп** теленнән кергән *рәсем, нокта, кер, тәртип; магазин, алгебра, химия* (автор искәрмәсе: бу сүзләрне күпләр рус сүзләре дип уйлыйлар*), хат* сүзләре һәм **фарсы** теленнән кергән *шәһәр, бәхет, начар, рәвеш* һ.б.

Сүзләрнең гарәп һәм фарсыныкымы икәнне аеру да шактый кыен, бигрәк тә укучылар өчен. Шулай да гарәп һәм фарсы сүзләрен кайбер билгеләре буенча бер-берсеннән аерырга мөмкин.

**Физминут**

**Төркемнәрдә иҗади эш.** «Чәчкә балы» әсәре турында...

**Гарәп-фарсы алынмаларын кулланып, кечкенә генә хикәя язарга**.

**IV.Йомгаклау.**

- Укучылар, дәресебез ахырына якынлаша. Безнең бүгенге дәресебез сезнең өчен нәрсә белән әһәмиятле? Хәзер үзегезнең дәрестәге эшчәнлегегезгә бәя бирегез. (Һәр укучыга үзбәя карточкасы таратыла) Үзбәя.

**V. Өй эше.**

М. Маликованың «Чәчкә балы» әсәренә рецензия язарга. Матур әдәбиятка реклама ясарга. Барыгызга да катнашуыгыз өчен рәхмәт. Сау-сәламәт булыгыз.

## БӘХЕТ КАЛАСЫ

Шакирова Эльмира Финус кызы, Зиннатуллина Лилия Ринат кызы
Җәлил гимназиясенеңтатар теле һәм әдәбияты укытучылары,
Сарман районы

**Максат һәм бурычлар:** Якташыбыз Мәдинә Маликованың тормышы һәм иҗаты белән танышу. Сарман ягы төбәге әдипләренең иҗади мирасын өйрәнүне дәвам итү. «Казан каласы – таш кала» повеténнан өзекне өйрәнү. Аңлап уку, орфоэпия нормаларын төгәл саклау, архитекторлар эшчәнлеге белән танышу. Укучыларның иҗади фикерләү, парларда һәм төркемнәрдә эшләү сәләтен үстерү. Укучыларыбызда районыбыздан чыккан күренекле шәхесләребезнең иҗатына хөрмәт тәрбияләүгә шартлар тудыру; балаларда хезмәт кешеләренә, аларның эшенә хөрмәт тәрбияләү.

**Дәрес барышы.**

Уңай психологик халәт тудыру.

Актуальләштерү.

Өй эшен тикшерү.

Уку мәсьәләсен кую.

-Әйдәгез әле, укучылар, дәресебезне җыр белән башлап җибәрик. (Татар халык җыры “Сарман”ны тыңлау)

-Укучылар, сез әле генә нинди җыр ишеттегез? Бу җыр турында нәрсәләр әйтә аласыз? Дәреснең темасы ничек булыр? (Җаваплар тыңлана)

- Әйе, бу “Сарман” җыры. Ул – гади җыр гына түгел, ә безнең туган ягыбызның гимны булырлык иң матур җырларның берсе. Әйе, без бүгенге дәрестә сезнең белән туган ягыбыз һәм туган ягыбызның күренекле шәхесләре турында сөйләшербез.

- Сезнеңчә нәрсә соң ул туган җир? Анда кемнәр яши? Сез гел туган җирегездә генә яшәргә телисезме? Әгәр чит илгә китәргә туры килсә, сез гомер буе анда яши алыр идегезме? Туган җиреннән киткән кешеләрнең аны сагынып яшәве турында кайсы язучыларның, шагыйрьләрнең нинди әсәрләрен беләсез? (Парларда эш)

- “Шушы яктан, шушы туфрактан без”, - дип аталган телдән журнал чыгарырбыз. Дәреснең максаты да журнал битләре буенча туган ягыбызның күренекле шәхесләрен - рухи байлыгын тудыручыларын искә төшерү, аларның иҗатлары белән танышуны дәвам итү.

Уку мәсьәләсен чишү.

Журналыбызның 1 нче битен ачабыз: Туган ягыбызның рухи байлыгын тудыручылар кемнәр алар?

-Хәзер туган төбәгебез, аның талантлы кешеләре турында белемнәребезне барлап алыйк. Безнең Сарман ягы нинди байлыклар белән данлыклы?

Кара алтын табучылар

Төзеделәр ак кала.

Эшчән, уңган Җәлил халкы

Һәрбер җирдә мактала, – дип язган күренекле бистәдәшебез, шагыйрь Индус Мәрданшин кара алтын табучылар турында.

- Хәзинә - тирән мәгънәгә ия сүз. Беренчедән, ул – җир мае, байлык. Икенчедән, шушы байлыкны табучылар, хезмәт кешеләре үзләре дә хәзинә. Ә болардан башка тагын нинди байлык бар? (Рухи байлык.)

- Нәрсә соң ул рухи байлык? (Яхшы сүз, әдәби әсәрләр, җыр, китап, уй-фикер, рәсем, шигырьләр...)

- Рухи байлыкны кемнәр тудыра? (Язучылар, рәссамнар, шагыйрьләр, композиторлар, артистлар, җырчылар...)

-Безнең Сарман ягы кара алтыны белән генә түгел, шушы рухи байлык тудыручыларның күп булуы белән дә горурлана ала. Әйе, Сарман ягының алыштыргысыз байлыгы – аның бөек һәм күренекле шәхесләре! Кемнәр соң алар – безнең бөек шәхесләребез?! (Слайдларда күренә)

Хәзер белемнәребезне ныгытып, журналыбызның бу сәхифәсенә нәтиҗә ясыйбыз.

Тәкъдим ителгән электрон тренажер сораулары:

1. Сарман тарихын язучы - өйрәнүче галим, танылган журналист кем?

Дамир ГарифуллинЗөһрә СәхәбиеваКлара Булатова

2. Районыбызда туып – үскән җырчы-композитор, “Чыгарсыңмы каршы алырга” җырының авторы.

Валерий ӘхмәтшинЗөһрә ШәрифуллинаАяз Гыйләҗев

3. Җәлил бистәсендә бик күпләргә иҗат канатын ныгытырга ярдәм иткән әдәби иҗат берләшмәсе.

“Татар теле”“Нурлы як”“Җәлил чаткылары”

4. Якташ язучыбыз Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе, Хөсәен Ямашев исемендәге республика бүләге лауреатлары, хикәяче, романчы, драматург, публицист, җәмәгать эшлеклесе, татар телендә романнар иҗат иткән беренче хатын-кыз, «Казан каласы– таш кала» повестеның авторы.

Дамир ГарифуллинМәдинә МаликоваРәфкать Кәрами

Укытучы. Тренажерның 4 нче соравына җавапны кычкырып әйтик әле.

Әйе, әлбәттә, ул – Мәдинә Маликова. (Парларда тикшерү, билгеләр кую)

Журналыбызның 2 нче сәхифәсен ачабыз.

-Укучылар, без журналыбызның бу сәхифәсендә якташ язучыбыз Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе, Хөсәен Ямашев исемендәге республика бүләге лауреатлары, хикәяче, романчы, драматург,

публицист, җәмәгать эшлеклесе Мәдинә Маликованың тормышы һәм иҗаты турында сөйләшербез (Укучылар чыгышы).

- Әйдәгез әле, укучылар бу бүлегебезгә нәтиҗә ясап, сорауларга җавап бирәбез, эшләрне парларда алышып тикшерәбез һәм билгеләр куябыз.

1. Мәдинә Маликова кайчан һәм кайда туган?

2.М.Маликованың беренче повесте ничек атала? Ул ничәнче елда басылып чыга?

3. Аның беренче романының исемен атагыз.

4. Аңа ничәнче елда Русия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исем бирелә?

5. Кайсы әсәре өчен һәм ничәнче елда <u>Г. Тукай исемендәге Татарстан Дәүләт премиясе</u>нә лаек була? Ял минуты.

Журналыбызның 3 нче сәхифәсе - “Бәхет каласы”

Бу сәхифәдә без М.Маликованың «Казан каласы–таш кала» (повестьтан өзек) күзәтү ясарбыз.

Татарстандагы шәһәрләр һәм аларның төзелеше турында әңгәмә.

-Татарстанда ничә шәһәр бар? Казан шәһәре турында нәрсәләр беләсез? Атамасы каян алынган? Урамнары ничек урнашкан?

“Калалар һәм кешеләр” өзеге өстендә эш.

а) сүзлек эшеә) әсәрне уку, төзүчеләрнең һәм архитекторларның һөнәри лексикасындагы сүзләрне табуб) йортлар язмышы һәм кеше язмышы турында сөйләшү.

в) төркемнәрдә эш

1 нче төркем. Мәрьям тәкъдим итә торган “Бәхет каласы” нинди булыр? Ул күпме кешене бәхетле итәчәк?

2 нче төркем. Сез архитектор эшен ничек күз алдына китерәсез? Мәрьям ни өчен үзенең проектын башкаларга күрсәтеп киңәшләшә?

3 нче төркем. Проект сызу эше нәрсәләргә таянып башкарыла? Мәрьямнең нинди җитешсезлекләре күренә? Шәүкәт аңа нинди киңәшләр бирә?

- Әйдәгез әле, укучылар, бу бүлеккә нәтиҗә ясап, өзекнең эчтәлеген сөйләп карыйбыз.

Рефлексив кабатлау. Без бүгенге дәрестә нәрсәләр белдек? Ничек белдек? Кемнәр турында сөйләштек? Үзебезгә нинди яңалык алдык? Сез үзегезгә нинди билгеләр куясыз?

Йомгаклау. Өй эше бирү.

М.Маликованың тормыш һәм иҗат юлы турында сөйләргә.

Әсәргә таянып, Татарстан төбәгеннән чыккан танылган архитекторлар, төзүчеләр турында мәгълүмат тупларга. Җәлил бистәсендәге урамнарның эскизын ясарга яки Җәлил бистәсен ничек үзгәртер идегез? (минипроект эше). Алдагы дәрескә проблема кую.

## МӘДИНӘ МАЛИКОВАНЫҢ ИҖАТЫНДА ХАТЫН-КЫЗ ОБРАЗЛАРЫНЫҢ БИРЕЛЕШЕ

Шафикова Гүзәлия Рәхимша кызы,
Россия Федерациясе Герое А.Н. Епанешников исемендәге 3нче урта гомуми белем мәктәбе,
Алабуга районы

**Проблеманың куелышы:** Укучыларга М.Маликованың «Казан каласы– таш кала» повесте аша хатын-кыз образларының бирелешен күрсәтү, хатын-кызның тормышта, җәмгыятьтә тоткан урынын ачыклау.

**Проект концепциясе:**

Татар әдәбиятына алып кергән тема, идеяләрнең, хатын-кызларның бүгенге томышта тоткан урыннан ачыклау максатыннан, мин проект эшенең темасын “**Мәдинә Маликованың иҗатында хатын-кыз образларының бирелеше”** дип атадым.

Хатын-кызның тормышта урынын билгеләү темасы татар әдәбияты өчен традицион да, актуаль дә булып тора. Традиционлыгын исбат итү өчен Г. Исхакыйның «Теләнче кыз», М. Гафуриның «Кара йөзләр», Г. Ибраһимов «Татар хатыны ниләр күрми», Ф.Кәримнең «Хәят» әсәрен искә алу да җитә. Бүгенге көн яшьләрен, әдипләрен хатын-кызның томышта тоткан урыны темасы борчый икән, димәк, ул – актуаль.

Хатын-кызның язмышын, көчен һәм максатына ирешү юлындагы батырлыгын күрсәтү өчен иҗат эше аеруча кулай өлкә. Повестьтагы төп образ Мәрьямга иҗат эшендә үз-үзен күрсәтү юлында бик күп каршылыклар аша үтәргә туры килә. Әле бит ул гаиләдә хатын-кыз һәм бала тәрбияләүче ана кеше дә.

**Проектның максаты:** М. Маликованың «Казан каласы – таш кала» повестенда хатын-кыз образларының бирелешен ачыклау.

**Проектның бурычлары:** Мәдинә Маликованың тәрҗемәи хәле, иҗаты белән танышу. Иҗатында хатын-кыз образлары бирелешен күзәтү. «Казан каласы – таш кала» повестенда Мәрьям, Саҗидә апа, Камәрия, Ирина Сергеевна образларын өйрәнү.

**Проектта катнашучылар:** 9 сыйныф укучылары, туган тел һәм әдәбияты укытучысы.

**Проектның реализация вакыты** 2019-2020 нче уку елы

**Проектның тормышка ашыру этаплары:**

**1. Әзерлек этабы:** тема буенча материал туплау (Сентябрь- декабрь)

**2. Төп этап (январь-март):** Фәнни хезмәтләрне уку, анализлау

**3. Йомгаклау этабы (апрель):** фәнни эш язу, презентация эшләү.

**Мотивацияләү: у**кучыларда китап укуга кызыксыну уяту, татар әдәбиятын тирәнрәк үзләштерү, әсәр нигезендә хатын-кызга, әниләргә хөрмәт хисе тәрбияләү.

**Оештыру:** әдәби әсәрләр өйрәнү, презентация ясау.

**Йомгаклау:** М. Маликова иҗатына колачлылык, киң планлылык хас. Ул үзенең иҗатында хатын-кыз образларына киң урын бирә. Тормышта хатын-кызның теләсә нинди каршылыклар алдында да җебеп төшмәгән, көчле рухлы булуын ачыклап күрсәтә. М.Маликова әсәрләрен укып, укучыларда хатын-кызга, әниләргә карата мәхәббәт хисе тәрбияләнә.

**Кулланылган әдәбият:**

Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге.- Казан: Мәгариф, 2007.

Заһидуллина, Д.Ф., Әдәби әсәргә анализ ясау/ Д.Ф. Заһидуллина, М.И.Ибраһимов.- Казан, Мәгариф, 2005.

Заһидуллина Д.Ф., Яңа дулкында (1980-2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңалык) /Д.Ф. Заһидуллина.- Казан: Мәгариф, 2006.

Маликова М.Г. Бер күрүдә яраттым. - Казан: Тат.кит. нәшр., 1985

## ЯКТАШЫБЫЗ

## М. МАЛИКОВАНЫҢ «ЧӘЧКӘ БАЛЫ» ПОВЕСТЕ БУЕНЧА КЛАССТАН ТЫШ УКУ ДӘРЕСЕ

(8 нче сыйныф)

Шаһгалиева Гөлназ Нәҗип кызы,
Актүбә 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Азнакай районы

**Максат:** әсәрнең идея-эстетик әһәмиятен аңлау, логик фикер йөртү сәләтен һәм сөйләм телен үстерү, яшәеш өчен кирәкле уңай сыйфатлар тәрбияләү, яшьләрне тормышка әзерләү.

**Җиһазлау:** М.Маликова портреты, китап күргәзмәсе, «Чәчкә балы»на китапнамә (буктрейллер), компьютер, мультимедиа проекторы, штрих-кодлар, телефоннар.

**Дәрес төре:** эзләнү – тикшеренү дәресе.

**Метод һәм алымнар:** әңгәмә, өлешчә эзләнү, тест.

**Дәрес тибы:** белемнәрне гомумиләштерү һәм системалаштыру.

**Дәрес барышы.**

**Укытучы.** Исәнмесез, хөрмәтле укучылар! Хәзерге көндә илһамланып иҗат итүче, Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, Хөсәен Ямашев, Г.Тукай исемендәге республика бүләге лауреаты, хикәяче, романчы, драматург, публицист, җәмәгать эшлеклесе Мәдинә Маликова белән таныштык. Әйдәгез, Мәдинә апаның биографиясен искә төшереп китик әле. Моның өчен, телефоннарны алып, штрих-кодларны укырга һәм сорауларга җавап бирергә әзерләнәбез.

***Укучы җавабы:*** Мәдинә Габделхак кызы Маликова 1935 елның 5 августында Татарстанның Сарман районы Мортыш Тамагы авылында игенче гаиләсендә туа.

***Укучы җавабы:*** Казан дәүләт педагогия институтының тарих-филология факультетында укый

***Укучы җавабы:***«Чаян», «Сөембикә» журналларында эшли.

Ук***учы җавабы:*** Матбугат һәм мәдәният өлкәсендәге хезмәтләре өчен аңа 1976 елда Татарстанның, ә 1985 елда «Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелә, ул шулай ук Татарстан журналистларының Х.Ямашев исемендәге бүләге лауреаты.

**Укытучы**. Бүген без Мәдинә Маликованың «Чәчкә балы» исемле повесте буенча фикер алышырбыз, хәзерге заман яшьләре күзлегеннән – сезнең күзлектән чыгып бәяләрбез. Әйдәгез, «Чәчкә балы» әсәре буенча ясаган китапнамәне карап китик. (Китапнамәнең адресы https://youtu.be/7EUgnQddelY )

**Укытучы**. Повесть Гамилнең фаҗигасе белән башланып китә. Беренче сорауны белер өчен тагын штрих-кодны укырга кирәк.

***Укучы җавабы:***Төп герой Гамил һәм аның гаиләсе үрнәгендә кешенең рухи дөньясы, кешеләр арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләр сурәтләнә. Автор яшәешнең мәгънәсен яхшылыкка, матурлыкка хезмәт итүдә күрә. Гамил нык ихтыяр көче булган кеше буларак күз алдына килеп баса. Аның өчен гаиләсе, уллары беренче урында тора. Сәгъдиясе белән үзенә ошамаган баланы, шикләнсәләр дә, “менә дигән итеп” тәрбиялиләр. “Зөфәр кебек кызыл чәчле булса да, чирләшкә булса да” яраталар, аякка бастыру өчен бик күп көч куялар. Кешеләр сүзен дә күтәрәләр. Инде урамда, үзенә һөҗүм иткән яшьләр арасында, үзенең Газименә охшаган малайны күргәч, ул бөтенесен дә аңлап ала. Бәби табу йортында алышынган бала бит бу. Милициягә дә, хатынының сеңлесенә дә дөресен әйтмичә малайны яклый, өенә алып кайта, тәрбияли башлый. Наркоман икәнен белгәч тә, ташламый. Әйткән сүзендә тора. Көчен дә, акчасын да кызганмый. Әкренләп малайның күңеленә ышаныч кайта. Үз гомерендә эчү, сугышу, җәберләү, шакшылыкны гына күргән малай, монда икенче тормыш барлыгын күрә һәм терелә дә. Моңа бал кортлары, бер-береңә ышаныч, хөрмәт һәм мәхәббәт ярдәм итә.

***Укучы җавабы:*** Сәгъдия уйнап-көлеп, җырлап-биеп кенә яшәгән кыз. Авыл мәктәбен тәмамлап, Тәтешкә бухгалтерлар курсына укырга керә. Төскә-биткә матур, буй-сын зифа. Иңнәренә төшкән куе кара чәчләр, тулы иреннәр арасыннан балкып торган энҗе тешләр. Хәзер гап-гади авыл хатыны. Гамилне чын күңеленнән яратып, хөрмәт итеп яши. Балаларына яхшы әни.


***Укучы җавабы:*** Эльза – эчә торган ир белән үзе эчә торган хатынга әйләнгән, үзендә җирәнү хисен тудырган кеше белән күп еллар яшәгән, шушы тормыштан чыгу юлын тапмаган һәм табарга тырышмаган да 4 яшьлек «чирләшкә» кыз һәм бозыклык юлына баскан 13-14 яшьлек малай Макарның әнисе.

***Укучы җавабы:*** Җәмил – эчә торган Эльза белән Геннадий Харитоновлардан туган “чирләшкә” малай. Ул хәмергә иярләшкән ата-анадан туганга, каш-керфеге бөтенләй булмый, әле температурасы төшми, әле имә алмый. Бала сәламәт гаиләдә туарга тиеш.

***Укучы җавабы:*** Бу – Макар.

**Укытучы**. Макарның җинаять юлына этәрүче сәбәпләрне санагыз:

малайга ихтирам җитмәү; кирәгенчә кадерләмәү; ата-ананың әхлакый яктан үрнәк булмавы; гаилә әгъзаларының бер-берсен аңламаулары; баланы мәхәббәт, шәфкать, эчкерсез һәм самими аралашудан мәхрүм итү.




***Укучы җавабы:*** Әйе, Макар терелә, начар гадәтләрен дә ташлый. Моңа бал кортлары, бер-береңә ышаныч, хөрмәт һәм мәхәббәт ярдәм итә.

***Укучы җавабы:***

- Бу әсәрдә актуаль проблемаларның берсе – ул тату гаилә.
- Мәхәббәткә тугрылык;
- Күңел сафлыгы – рухи гариплек
- Гаилә бәхете - бәхетсезлеге;
- Бала язмышы – ата-ана язмышы;
- Ата-ана һәм бала мөнәсәбәте;
- Рухи кыйммәтләр – әхлаксызлык;
- Тәрбия - тирәлек йогынтысы
- Минемчә, җәмгыятебездә булган төп проблема - наркомания, эчкечелек.

**Укытучы**. Дөрес, автор бу проблемаларны күреп, бик борчыла. Һәм, анынча, проблемаларны чишү өчен, гаиләләрдә терәк булырлык, ышанычлы ирләр кирәк. Ирләрен яратучы, хөрмәт итүче, сөйкемле һәм акыллы хатын-кызларыбыз кирәк. Шундый гаиләләрдә тәрбияләнгән балалар гына сау-сәламәт, үз-үзенә ышанучан һәм нәселне яхшы дәвам итүчеләр булачак. Ә инде андый гаиләләребез күбрәк булса, җәмгыятебез дә сау-сәламәт булачак.

Укучылар, без Мәдинә Маликованың «Чәчкә балы» әсәре турында фикер алыштык. Хәзер телефоннардан «Kahoot» уенын табыгыз. Өйрәнгәннәр буенча белемнәрне тикшерүне дәвам итик.

«Kahoot» — яңа сүзләрне үзләштерергә, укучыларның белемнәрен тикшерергә ярдәм итә торган уен. Моның өчен интернет тоташкан телефоннар кирәк. Телефоннан интернетка кахут дип язып керегез. PИН дигән язуга басыгыз. Экрандагы саннарны PИН дип язылган шакмакка языгыз һәм интерга басыгыз. Алдагы шакмакка исемегезне яки команда исемен языгыз. Димәк, безнең экранда катнашучылар чыкты. Уенны башлыйбыз. Сорауны игътибар белән укыйбыз. Уйларга 2 – 3 секунд бирелә. Яңадан экранда күрсәтелгән вакыт эчендә телефоннарда дөрес дип уйлаган җавапка басасыз. Сезнең телефоннарда үзегезнең баллыгыз күренә. Ә бөтен кеше җавап биргәч, баллар экранга чыга. Иң өлгер кеше иң югары балл җыя. Дәрес азагында балларны яхшы билгегә алмаштырырга була. Без, укытучылар, ул балларны үзебезгә Game Results күчереп ала алабыз. (Шулай ук дискка да).

1. М.Маликова кайда туган?

А) Сарман районы ЯңаБүләк авылында

Б) Сарман районы Мортыш Тамагы авылында

В) Сарман районы Яхшыбай авылында

2. Кайсы әсәр Мәдинә Маликованыкы түгел?

А) Чәчкә балыБ) ШәфкатьВ) Агыла да болыт агыла.

3) “Чәчкә балы” әсәре кайчан язылган?

А) 2003-2004 нче елларБ) 2018 нче елВ) 1935 нче ел

4) Аланлык авылында яшәүче оста хуҗабикә, тормыш иптәшен яратып, хөрмәт итеп яшәгән хатын

<u>А) Сәгъдия</u> б) Эльза в) Сәрия

4. Буйга калку, кыска, куе керфекле, кара күзле, киселмәгән тырнак асларына кап-кара кер утырган. Бу кем?

А) Газим Б) Гамил <u>В) Макар</u>

5. “Ташлама мине, әни.... Читкә җибәрмә мине...” Бу сүзләрне кем әйтә?

А) Макар <u>Б) Җәмил</u> В) Газим

6) Макарга әти-әнисе ничек эндәшә?

<u>А) Мохтар</u> Б) Марсель В) Мәҗит

7) Җәмилнең яраткан шөгыле:

А) кош-корт <u>Б) умарта</u> В) терлек

8) Җәмил кинәт кенә борылды да, селтәнеп, кәрәзле рамны ... башына сылады.

А) Газим <u>Б) Мохтар</u> В) Гамил

9) Нәрсә агуы наркотикларга омтылышны, тартылуны бетерә икән?

А) елан агуы <u>Б) бал корты</u> В) шөпшә

10) Сәгъдия наркоманга нинди дару тапкан?

<u>А) чәчкә балы</u> Б) укол В) елан агуы

Укытучы. Димәк, безнең уенда 1 нче урын кемдә? Ничә балл? Әсәрнең бүгенге көн өчен дә актуаль булуы белән килешәсезме?

**Укытучы**.Тормыш никадәр генә авыр булса да, кыенлыклар күпме генә очраса да, түбәнлеккә тәгәрәмә. Кеше булып кал! Тормыш әлифбасын гомер буе өйрәнергә тырыш! Дәрес тәмам.

## ТУГАН ЯК БУЛА БЕР ГЕНӘ

(Осталык-дәресе)

Шәйдуллина Гөлнара Индүс кызы,
Ләшәү-Тамак төп гомуми белем бирүмәктәбе тәрбиячесе,
Сарман районы

**Максат:** Туган як темасын өйрәнү дәресләрендә укучыларда ватанпәрвәрлек сыйфаты тәрбияләү. Тормышны яратырга, аның матурлыгын күрә, тоя белергә өйрәнү.

**Җиһазлау:** презентация, Г.Тукайның “Шүрәле” әкиятенең видеоязмасы, таратма материал, төсле карандашлар, язучылар иҗатын өйрәнү алымнары турында презентация.

Кулланылган эш формалары: төркемнәрдә эш, фронталь эш

Кулланылган методлар: сорау-җавап, әңгәмә

**Мастер-классның барышы:**

I. Оештыру моменты. Мастер-классның темасы, максаты, юнәлешләре белән таныштыру. Уңай психологик халәт тудыру

- Исәнмесез, хөрмәтле хезмәттәшләр. Өстәлдә үсемлек рәсемле карточкалар бар. Шуларның берсен сайлап алыгыз әле. Сайладыгызмы? Мәсәлән, менә сез нинди рәсемне сайладыгыз? Ә сез?

- Игътибар итегез әле, әлбәттә, без үзебезгә матуррак чәчәкне алып калырга тырышабыз, ә чүп үләннәре төшкән карточкалар өстәлдә калган. Ләкин табигатьтә бер генә артык әйбер дә юк. Һәрнәрсә үз урынында кирәк. Безгә дә тормышта кирәкле, кадерле булып, матур итеп яшәргә омтылырга кирәк. Шуңа да мин сезне тормышның яме, матурлыгы булган туган авыл, аның табигате турында сөйләшергә чакырам.

II. Төп өлеш. Экранда Г.Тукайның “Шүрәле” әсәре буенча төшерелгән мультфильм күрсәтелә.

- Мин бу өзек белән нәрсәгә ишарә ясадым (Кырлай авылы матур). Һәр як үзенчә матур. Сезнең туган авылыгыз нәрсә белән матур? (Фикерләр тыңлана)

- Безне нәрсә берләштерә? (Без - бер район кешеләре) Безнең Сарман нәрсә белән матур? (Төркемнәрдә эшләп алабыз)

- Әгәр без рәссамнар булсак, нинди төсләр кулланыр идек микән? Ни өчен? (Төсләр турында сөйләшү)

- Ә без кемнәр белән мактаулы? (Данлыклы кешеләрне барлау. Һәрберсенең уңышларын санау). Кабат рәссамнар булып алыйк әле. Безгә аларның портретларын төсләр белән бирәсе булса, нинди төсләр кулланыр идек микән? Ни өчен?

- Психологлар фикеренчә, зәңгәр төс – матур хыяллар төсе, ак төс – аклык, пакьлек, бәхеткә омтылыш, яшел – яшьлек, яшеллек, яшьнәп яшәү, ал төс – алга омтылыш, өмет. Хәзер язучылар булып алыйк та, якташ язучыларызның иҗатларына бәя биреп карыйк.

- Тагын никадәр яхшы сыйфатлар таба алдык. Һәр язучы үзенчә кызыклы, талантлы.Бары алар иҗатына кызыксыну уятырга гына кирәк. Моның өчен мөмкинлекләр күп.(Эш төрләре буенча презентация күрсәтелә). Игътибарыгыз өчен рәхмәт.

## ТАБИБ ҺӨНӘРЕ – БИК МӨҺИМ ҺӨНӘР

(Сыйныф сәгате)

Шәйхелисламова Лилия Фәрид кызы,
икенче санлы Җәлил урта мәктәбенең башлангыч сыйныф укытучысы,
Сарман районы

**Максат:**Табиб һөнәре турында белемнәрне гомумиләштерү һәм тирәнәйтү. Мәдинә Маликова, аның иҗаты белән таныштыру.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

**Шәхси нәтиҗәләр: Кешеләргә карата мәрхәмәтле һәм кайгыртучан мөнәсәбәт тәрбияләү.**

**Универсаль уку гамәлләре.**

**Танып-белү:** Тексттан кирәкле мәгълүматны аерып алу, сәбәп-нәтиҗә элемтәләре урнаштыру.

**Коммуникатив:** Башка кешеләрнең фикерен исәпкә алу, тыңлый, әңгәмәгә кушыла белү.

**Регулятив:** Куелган бурыч һәм аны тормышка ашыру шартлары нигезендә, үз гамәлен планлаштыру.

**Материал:** Мәдинә Маликова фотосы, китаплар күргәзмәсе.

**Җиһазлау:** ак халат,бакыр чыбык, бозык теш рәсеме һәм ак буяу, кисточка, бинтлар,

**Чара барышы.**

**I. Мотивлаштыру.**

**II. Белемнәрне актуальләштерү.**

- Бүген сыйныф сәгатенә мин ак халат киеп кердем. Ничек уйлыйсыз, ни өчен?

**III. Тема, максат.**

Маңгай кайнар булса, температура күтәрелсә, кемне чакырабыз?
Бик нык эчебез авыртса – кемне чакырабыз?
Ул эти белән әнине дә, сине дә дәвалый.
Яңгыр явып торсын, яшен яшьнәсен,
Ул, һичшиксез, киләчәк!

- Бу сүзләр нинди һөнәр кешесе турында?

- Дөрес, бу-табиб.

- Без бүген сыйныф сәгатендә нәрсә турында сөйләшербез икән?

**VI. Тема буенча эш.**

Колагың авырса,
Тамагың карлыкса,
Борчылма , елама –
Сиңа табиб ярдәмгә килер!

Борынгы заманнардан ук кешеләр авыруларны кисәтергә һәм дәваларга тырышканнар. Медицина шулай барлыкка килгән һәм үсә башлаган.Хәзерге медицина, әлбәттә, фән һәм техниканың иң соңгы казанышлары: приборлар һәм аппаратлар, инструментлар, дарулар белән җиһазландырылган. Әмма медицинаның барлык казанышларында да төп фигура булып табиб һәм аның ярдәмчеләре – шәфкать туташлары һәм санитаркалар кала. Академик Б.В. Петровский: “Табибның сизгер йөрәген, аның күңелен бернинди прибор да алмаштырмаячак", - дип язган.

**“Бу нинди табиб?” уены.**

-Хәзер мин сезгә табышмаклар әйтәм. Кем тизрәк җавап бирер?

1. Бу кабинетта бинт та, йод та юк.
Табиб сезгә бер күзегезне капларга кушар,
Эре һәм вак хәрефләр күрсәтер.
Бу нинди табиб? **(күз табибы, окулист)**

2. Ә хәзер кәнәфигә утырыгыз һәм авызыгызны киңрәк ачыгыз.
Сез нинди табибта? (**теш табибы, стоматолог**)

3. Бу табиб борыныгызны, колакларыгызны тикшерер, авызыгызны ачып тамагыгызны да карар.
Бу нинди табиб? (**оториноларинголог**)

4. Бу табиб курку белми,
Ару-талусыз эшли.
Кирәк булмаса кисеп ала,
Кирәк булса тегеп тә куя. **(хирург)**

5. Иң кечкенә бәбиләрне,
малайларны, кызларны - нинди табиб дәвалый? **(балалар табибы, педиатр)**

- Минем сорауларга җавап биреп без берникадәр табибларны гына исебезгә төшердек. Чынлыкта алар бик куп. Кайбер табиблар зур шәһәрләрдә, зур шифаханәләрдә генә була, шуның өчен авырулар шунда барып дәваланырга мәҗбүр булалар.

**V. Мәдина Маликова, аның иҗаты белән таныштыру.**

-Табиблар турында бик күп шигырьләр, хикәяләр, җырлар язылган.Рәссамнәр аларны үзләренең картиналарында сурәтли. Табиблар турында театрлар куялар, кинолар төшерәләр. (Мәдина Маликова фотосын күрсәтү)Безнең районыбызда туып үскән, быел үзенең 85 яшьлек юбилеен билгеләп үтәчәк язучыбыз Мәдинә Маликованың да табиблар турында «Шәфкать» дигән әсәре бар. Ул бу әсәрендә табибларның авыр һәм җаваплы хезмәтләре турында яза. (Мәдинә Маликованың китапларын күрсәтү)

**VI. “Ашыгыч ярдәм” уены.**

- Хәзер без төрле белгечлек табиблары арасында ярыш үткәрәчәкбез.

**1 бригада – окулистлар.** Чыбыктан күзлек ясау.

**2 бригада-стоматологлар.** Тешләре дәвалау ( бозык теш рәсеме һәм ак буяу)

**3 бригада-хирурглар.**Табиб-хирург – табиб һөнәрләренең иң батыры. Грек теленнән тәрҗемә иткәндә "хирургия” “кул эшләре" дигәнне аңлата.Хастаханәдә хирург көтелмәгән хәлләргә әзер булырга тиеш, ул тирән белемле, чыдам, «алтын» куллы була. Күп сәгатьләр буе хирург операция өстәле янында тора, аңа табиблар бригадасы һәм шәфкать туташлары – операция бригадасы булыша. Кыюлык, үҗәтлек, төгәллек – хирургның мөһим үзлекләре.(Бинт белән бармак, кул яки башны бәйләү)

**4 бригада-шәфкать туташлары һәм медбратлар.**10 метрлы медицина бинтын рулонга төрергә

**VII. Сыйныф сәгате нәтиҗәләре**

- Бүген без үзебезнең сыйныф сәгатен табиб һөнәренә багышладык. Ничек уйлыйсыз, табибка нинди сыйфатлар кирәк соң?

- Дөрес! Кешеләргә мәхәббәт, ярдәмчел йөрәк, тирән белем, оста куллар, яхшы хәтер, фидакарьлек һәм бурыч хисе.

- Сезнең, әти-әниләрегезнең нинди табибларда дәваланганы бар?

- Безнең язучы якташыбызнын исеме ничек?

- Ул нинди әсәрләр язган?

**VIII. Рефлексия.**

## МӘДИНӘ МАЛИКОВА - БӘХЕТЛЕ ЯЗУЧЫ

Шәмсетдинова Альбина Шәүкәт кызы,
Җәлил бистәсенең 5 нче «Әкият» балалар бакчасы тәрбиячесе, Сарман районы

Әлеге язма Мәдинә Маликова хакында. Иҗат эшчәнлеген журналистикада башлап, җиде роман, күп кенә хикәя, повестьлар иҗат итә ул.

Язучылар аның иҗатын югары бәяли. Язучы реаль тормыш белән шигъриятне бергә куша, синтезлый. Мәдинә Маликова каләменә бер үзенчәлек хас: язучы сурәтләргә теләгән панорамасын турыдан-туры күрсәтми, бәлки аны икенче герой карашыннан чыгып чагылдыра, бәяли. Моның сәбәбе нидә соң? Минемчә, автор иҗат иткән шул икенче образның тулылыгы һәм тирәнлегендә". Мансур Вәлиев исә, бөтен повестьларының игътибар үзәгендә ике төрле яшәү рәвеше тора, дигән бәя бирә.

Миңа аның«Кояш күпере» дигән повесте ошый. Ул мәхәббәт, кешеләрнең катлаулы тормыш коллизиясе, бәхет эзләп, бәхетсезлеккә төшүләре һ.б. турында. Шәһәрдәге бер район башлыгы Гадил Закирович Урманцев санаторийда яшь ханым – Октябрина-Тәбрия белән таныша. Яшь аермасы зур булса да, Тәбрия андый «вак-төяккә» әһәмият бирми, бөтен тәне-җаны белән Гадилгә бирелә. Урманцев хатынының бала тапмавын, нәселе өзелүеннән куркуын әйтә. Тәбрия аңа: “Малай табып бирәчәкмен сиңа”, - ди. “Ундүрт ел да өч ай да унбер көн көттем мин сине (мөгаен, беренче ире Рәистән аерылган вакыттан алып саныйдыр). Барыбер килүеңә ышандым. Сине – иремне. Син – ул”, - ди. Ә автор башкачарак уйлый: “Мәхәббәт мәңгелек була алмый. Мәхәббәт гөл кебек ул – була аның үскән, бөреләнгән чагы, чәчәк аткан вакыты, корыган, сулган чагы. Аның гомере кеше гомере белән тәңгәл дә килми”. Бу сүзләргә нәрсәдер өстәү, аңлатма бирү кирәкмидер, чөнки чынбарлык шуннан гыйбарәт. Алай гына түгел, повесть авторы, мәхәббәтнең бөек хисләр дөньясы икәнен тану белән бергә, кисәтү рәвешендә болай ди: “Тәбрияне гомеренең чәчәкле-баллы җәе, ә Гадилне кара көз көтә... Бергә яшәү – аларның икесенә дә газап әзерли иде”. Тәҗрибәле кеше буларак, моны Гадил аңлый һәм акрын-акрын гына Тәбрия белән араны өзә, ә ул моңа түзми. Тәбрияне җирләгәндә журналист Камилә Имашева Гадил хакында болай уйлый: “Тәбрияне бу ялгыш-хаталардан саклап калырга тиеш идең, ә син киресенчә эшләдең... Икегез бергә гөнаһ кылдыгыз, ә җәзасын ул берүзе алды”. Тәбрия ялгышыпмы, аңлы рәвештәме, газга агуланып үлә. Ә аның яңа гына туган улын Гадил һәм хатыны Суфия тәрбиягә алалар. Күренгәнчә, бу повестьның да тәрбия потенциалы зур. Шуңа күрә ул киләчәктә дә кат-кат дөнья күрер, диясе килә.

Мәдинә Маликова иҗаты татар әдәбиятында үзенең лаеклы урынын алды. Шундый якташыбыз белән горурланабыз без.

# ДӨНЬЯ ТЕРӘГЕ — ХАТЫН-КЫЗ

(Мәктәпкәчә әзерлек төркеме өчен кичә конспекты)

Якупова Гөлшат Шаһәдәт кызы,
«Дуслык» 59 нчы балалар бакчасы, Яр Чаллы шәһәре

**Максат:** мәктәпкәчә яшьтәге балаларда Мәдинә Маликова иҗаты аша әниләргә хөрмәт тәрбияләү.

**Җиһазлар:** Мәдинә Маликованың тормыш юлына бәйле сурәтләр, портрет, китаплары, ИКТ такта, татар кучагы (кыз), әниләргә багышлап ясалган рәсемнәр, проектор, компьютер.

**Эшчәнлек барышы:**

**1.Оештыру моменты.**

**Тәрбияче:**Исәнмесез, балалар! Бүген безнең шөгыль-кичә гадәти генә булмаячак, анда әниләр дә катнашачак. Без– әни, хатын-кыз язучы– Мәдинә Маликова белән танышырбыз.

**2. Кереш өлеш.**Тактага күз салыгыз әле.Кемне күрәсез? Татар хатын-кызы– Мәдинә Маликова. (Тыныч кына көй астында татар хатыны киемен кигән бер баланың әнисе керә)

**1 әни.** Хатын-кыз... Нечкә билле, сылу гәүдәле, кыйгач кашлы, кара күзле, озын толымлы татар хатын-кызлары... Кем генә сокланмый аларга! Матур булуларына карамастан, үтә тыйнак, җыйнак, сабыр, түземле, кунакчыл, сынмас рухлы, батыр йөрәкле. Борынгы заманнардан ук җырчылар хатын-кызларны мактап дан җырлаганнар, әкиятләр сөйләгәннәр, рәссамнар гүзәл сыннар ясаганнар, ә язучылар һәм шагыйрьләр, аларга атап, мәңгелек әсәрләр иҗат иткәннәр. Татар әдәбиятында хатын-кыз образын яктырткан әсәрләр бик күп. Һәрбер язучы үзенең күңелендәге идеаль хатын-кыз (әни) образын тудыра. (Рәсемнәр күрсәтелә)

**3.Төп өлеш.Танышу.**

**2 әни.** Балалар, таныш булыгыз безнең алда шуларның берсе–язучы Мәдинә Маликова. Ул Сарман районының Мортыш Тамагы авылында гаиләдә беренче бала булып дөньяга килгә. Сугышның иң кызган чагында – 1943 елда беренче класска укырга бара. Хәрефләр өйрәнеп, яза белә башлауга, фронтка әтисенә хатлар язарга керешә. Кечкенәдән китап укырга бик ярата. Ул чакта китаплар аз булган. Нинди генә кенә китап булса да, яратып укыган. Мәктәптә дә яхшы укыган. Кияүгә чыккан, әни булган.

**Тәрбияче:** Сез ничек уйлыйсыз, Мәдинә апаның балалары бар микән?Әйе, ике улы- Ильяс белән Искәндәр. Зур улы Канадада, кечесе Казанда яши.

**3 әни.** Мәдинә апа– бик яхшы әни. Аны балалары бик яраталар, хөрмәт итәләр. Ул бик күп әниләр турында әсәрләр язган. Яратып укыла торган хатын-кыз, әниләр турында язган әсәрләре: «Шәфкать», «Басып сайрар талы бар», «Фидая», «Кызыл гөл», «Юкә чәчәк аткан чак иде» романнары күңелгә килә. Һәм, әлбәттә, соңгы романы «Арыш тәме»! Бу әсәре өчен Мәдинә Маликова республикабызның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә тәкъдим ителде. Язучы бу мәртәбәле исемгә чыннан да лаек! (Китаплар күрсәтелә).

**Тәрбияче:**Балалар, әсәрдәге геройлар кемнәр?Мәдинә Маликова - хатын-кыз, язучы, әни. Аны тормыш иптәше, хезмәттәшләре (бергә эшләгән кешеләр), китап укучылар, балалары бик яраткан һәм хөрмәт иткән.

**Ял итеп алабыз.**

**Тәрбияче:**Ял иттек, эшебезне дәвам итик. Ә без үзебезнең әниләрне яратабызмы, хөрмәт итәбезме?

**Җыр: “Әнием”**

**Тәрбияче:** Әнисен ничек хөрмәт итүе турында кемнәр сөйләп китә? (Балалар сөйли)

**Тәрбияче:**Көнгә ничә тапкыр “әни” дибез. Рәхәт тә соң “әни” диюләр. Шигырьләр һәм җырлар бүләк итик. Бүләк итик матур биюләр. **Вальс.**

**Әниләр һәм балалар белән уен:** “Әниеңне таны”

4. **Ныгыту.**

**Тәрбияче:** Мәдинә апа Маликова да әни. Әниләр турында матур әсәрләр иҗат иткән. Ул да сезнең әниләрегез кебек үз балаларын ярата.Балалар, сезгә әниләр белән бергә күңелле булдымы, без бүген ниләр эшләдек, нәрсәләр белдек, моны кемнәргә сөйләр идегез. (Рәсемнәрне яңадан күрсәтү)

**5.Йомгаклау.**

**Тәрбияче:**Балалар, шуның белән безнең шөгыль-кичәбез тәмам.Өйдә әниләребенең портретларын(рәсем) ясап киләбез.

- Хөрмәтле әниләр, шөгыль-кичәдә катнашканыгыз өчен бик зур рәхмәт. Гаиләгездә тынычлык, тазалык, балаларыгызның игелеген күреп яшәргә язсын сезгә.

**Эчтәлек**

**Содержание**

**СЦЕНАРИЙ КВН, ПОСВЯЩЕННЫЙ ЖИЗНИ И ТВОРЧЕСТВУ МАДИНЫ МАЛИКОВОЙ**
Абдрахимова Рушания Шакирзяновна, учитель родного языка и литературы СОШ №3, г.Бугульма ........ 3
**МӘДИНӘ МАЛИКОВАНЫҢ «ОҖМАХ БАЛАЛАРЫ» ФАНТАСТИК ТРАГИКОМЕДИЯСЕ БУЕНЧА ТЕСТ**
Адлер Эльвира Демьян кызы, Заһитова Ләйлә Әзһәр кызы,беренче санлы Актүбә урта гомумбелем бирү мәктәбе,Азнакай районы ........ 4
**НАРКОМАНИЯ АФӘТЕНӘ КАРШЫ – ЯҢА ТЕХНОЛОГИЯЛӘР**(Осталык дәресе)
Афзалова Луиза Әкрам кызы, Шәйдуллина Ландыш Камил кызы,икенче санлы Җәлил урта мәктәбе укытучылары, Сарман районы ........ 5
**ОХРАНА ОКРУЖАЮЩЕЙ СРЕДЫ НА ПРИМЕРЕ ПРОИЗВЕДЕНИЯ М. МАЛИКОВОЙ «ТАЛЫЕ ВОДЫ»**
Ахметгалеева Ландыш Зиннуровна. учитель Джалильской СОШ №2,Замаева Луиза Назировна., учитель Джалильской гимназии, Сармановский район ........ 6
**МӘДИНӘ МАЛИКОВА ТОРМЫШЫ ҺӘМ ИҖАТЫ**(Мәктәпкәчә әзерлек төкремеөчен шөгыль конспекты)
Әндәрҗанова Эльмира Рифгат кызы,«Фиалка» 116 нчы балалар бакчасы, Яр Чаллы шәһәре ........ 8
**МӘДИНӘ МАЛИКОВА ИҖАТЫ**
Әсәдуллина Әлфия Мансур кызы, Муртазина Альбина Николай кызы,Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче Җәлил беренче урта гомуми белем бирү мәктәбе,Сарман районы ........ 10
**БӘХЕТЛЕ ОЧРАК**( интеллектуаль уен)
Бәдриева Фәридә Рәис кызы,икенче санлы Җәлил урта мәктәбенең башлангыч сыйныф укытучысы,Сарман районы ........ 11
**ЯКТАШЛАР ИҖАТЫН ӨЙРӘНӘБЕЗ**
Вафина Рузилә Мөдәрис кызы, Төхбатуллина Роза Марат кызы, 5нче санлы "Әкият" балалар бакчасы, Җәлил бистәсе ........ 12
**МӘДИНӘ МАЛИКОВА ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ҺӨНӘРЧЕЛЕК СҮЗЛӘРЕ**
Вилданова Лилия Равил кызы,Мусабай-Завод уртагомуми белем мәктәбе,Тукай районы .. 13
**МӘДИНӘ МАЛИКОВАНЫҢ ИҖАТЫНДА ӘХЛАК ПРОБЛЕМАЛАРЫНЫҢ ЧАГЫЛЫШЫ**
Габдулхакова Инсия Зөфәр кызы, 25 нче санлы Әлмәт урта мәктәбе,Җәмилова Гөлнур Рәис кызы, икенче санлы Җәлил урта мәктәбе,Сарман районы ........ 15
**ҺӘР ӘСӘРЕ – ТӘРБИЯ ДӘРЕСЕ**
Газизова Рәмзия Асфан кызы, Әсәдуллина Әлфия Мансур кызы,Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче Җәлил беренче урта гомуми белем бирү мәктәбе,Сарман районы ........ 16
**М. МАЛИКОВАНЫҢ «ЕГЕТЛЕККӘ БЕР АДЫМ» ПОВЕСТЕН ӨЙРӘНҮ**
Галиева Ләйсән Әнвәр кызы, Җәмилова Гөлнур Рәис кызы,икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирүмәктәбе, Сарман районы ........ 17
**БАЛАЛАРГА ӘХЛАК ТӘРБИЯСЕ БИРҮДӘ М.МАЛИКОВА ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ РОЛЕ**

Галиева Ләйсән Әнвәр кызы, Садыйкова Илмира Зөфәр кызы,икенче санлы Җәлил урта мәктәбе, Сарман районы ....................................................................................................18
**МӘДИНӘ МАЛИКОВАНЫҢ ӘСӘРЛӘРЕ БУЕНЧА ПРОЕКТ ЭШЕ**
Галимова Разиля Ринат кызы, 3 нче санлы гомуми урта белем бирү мәктәбе,Бөгелмә шәһәре ........................................................................................................................19
**ЛИТЕРАТУРНАЯ ГОСТИНАЯ С МАДИНОЙ МАЛИКОВОЙ**
Галияхметова Гульнара Илшатовна, Гиниятуллина Танзиля Язкаровна, Юшкова Ирина Николаевна, учителя Джалильской СОШ №2, Сармановский район..................................20
**НАШИ ПИСАТЕЛИ-ЗЕМЛЯКИ НА КАРТЕ САРМАНОВСКОГО РАЙОНА**(проект)
Гатин Рафис Исмагилович, Нуртдинова Гульнар Салихзяновна,Салихова Айгуль Робертовна, учителя Джалильской СОШ №2,Сармановский район ..................................22
**М.МАЛИКОВА ИҖАТЫНА БАГЫШЛАНГАН БЕНЕФИС ДӘРЕС**(Осталык дәресе)
Гыйльфанова Фәнүсә Мәгъсүмҗан кызы,А.Тимергалин исемендәге Иске Минзәләбаш төп гомуми белем бирү мәктәбе,Сарман районы .................................................................23
**М. МАЛИКОВАНЫҢ «ТЫЛСЫМ» РОМАНЫНДА ГАИЛӘ БӘХЕТЕНЕҢ БИРЕЛЕШЕ**
Даутова Роза Мөгайяр кызы,Кәүҗияк төп гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы ...25
**ИЛҺАМЛАНЫП ИҖАТ ИТҮЧЕ ЯЗУЧЫ**
Җиһангиров Айдар Фаиз улы, А. Тимергалин исемендәгеИске Минзәләбаш төп гомуми белем бирү мәктәбе,Якупова Гүзәлия Фаиз кызы, икенче санлы Җәлил урта мәктәбе,Сарман районы.....................................................................................................28
**“СҮЗ ТӨРКЕМНӘРЕН ГОМУМИЛӘШТЕРЕП КАБАТЛАУ” ТЕМАСЫ БУЕНЧА КОНТРОЛЬ ЭШ**
Җиһангирова Гөлшат Таһир кызы,А.Тимергалин исемендәге Иске Минзәләбаш төп гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы .................................................................29
**ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА ӘНИ ОБРАЗЫ**(Иҗади проект)
Загирова Гөлчәчәк Гаяз кызы, Хабирова Гөлшат Салимҗан кызы, «Дуслык» 59 нчы балалар бакчасы, Яр Чаллы шәһәре ..............................................................................31
**МӘДИНӘ МАЛИКОВАНЫҢ "АРЫШ ТӘМЕ" РОМАНЫНА КЫСКАЧА КҮЗӘТҮ**
Закирова Әлфия Ринат кызы, Нуретдинова Айгөл Гамирҗан кызы,икенче санлы Җәлил урта мәктәбенең инглиз теле укытучылары,Сарман районы ..........................................33
**КИЛЕР БУЫННАРГА МИРАС БУЛЫП, ЭЗЕҢ КАЛГАН САРМАН ЯГЫНДА...**
Закирова Фәридә Марат кызы, Заһитова Зинфера Ильяс кызы,Беренче номерлы Актүбә мәктәбенең Әлкәй филиалы укытучылары, Азнакай районы ..........................................34
**ОБРАЗ ЖЕНЩИН В ПРОЗАХ МАДИНЫ МАЛИКОВОЙ**
Залилова Аида Ренатовна, Джалильская СОШ №1, Сармановский район ..........................35
**«ЧӘЧКӘ БАЛЫ» ПОВЕСТЕ БУЕНЧА СЫЙНЫФТАН ТЫШ УКУ ДӘРЕСЕ**
Зарипова Зөлфия Флер кызы,Зур Нөркәй урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы ..........................................................................................................................................37
**МӘДИНӘ МАЛИКОВА ИҖАТЫНДА ӨЛКӘННӘР ХЕЗМӘТЕ**
Иксанова Рәмзия Мөдәрис кызы,5 нче «Әкият» балалар бакчасы тәрбиячесе, Җәлил бистәсе, Сарман районы ...................................................................................................37
**МӘДИНӘ МАЛИКОВА– КҮПКЫРЛЫ ШӘХЕС**
Исмәгыйлева Минзирә Рәсим кызы, Садыйкова Гөлсинә Солтан кызы,Казан шәһәре Киров районытатар телендә белем бирүче өченче гимназия ..................................................41

**КЕШЕ ӨЧЕН ТОРМЫШ КАДЕРЛЕ**(Сыйныф сәгате эшкәртмәсе)
Ихсанова Римма Ильяс кызы, Шәйдуллина Чулпан Камил кызы,икенче санлы Җәлил урта мәктәбе укытучылары, Сарман районы ........................................................................................42
**«МИН –БӘХЕТЛЕ ЯЗУЧЫ» (М. МАЛИКОВА)**
Корычбаева Гүзәл Сәлим кызы,29 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе, Түбән Кама шәһәре ........................................................................................................................43
**МӘДИНӘ МАЛИКОВА-ЯРАТКАН ЯЗУЧЫБЫЗ ҺӘМ ЯКТАШЫБЫЗ**(Иҗади проект)
Кәримова Зөлфия Франыс кызы, Җәлил гимназиясе укытучысы,Хәйруллина Зөлфирә Франыс кызы, "Әкият" балалар бакчасының өлкән тәрбиячесе,Сарман районы ................44
**МӘДИНӘ МАЛИКОВА ИҖАТЫ БУЕНЧА "ҮЗ УЕНЫМ" БӘЙГЕСЕ**
Миназова Равия Җәмигънур кызы,Чуракай төп гомуми белем бирү мәктәбе, Актаныш районы ........................................................................................................................45
**БАЛА-ГАИЛӘНЕҢ КӨЗГЕСЕ**(Мәдинә Маликованың «Чәчкә балы» повесте буенча ата-аналар җыелышы)
Мияссарова Ләйлә Кәбир кызы, Шангараева Нәзифә Наил кызы,икенче санлы Җәлил урта мәктәбенең башлангыч сыйныф укытучылары,Сармайн районы ........................................47
**МӘДИНӘ МАЛИКОВА ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ХАТЫН-КЫЗ ОБРАЗЫ ЧАГЫЛЫШЫ**
Муллашова Эльмира Рәис кызы,Яр Чаллы шәһәренең "Бизәкләр" 112 нче балалар бакчасы ........................................................................................................................49
**МАТЕРИАЛ ДЛЯ ПОДГОТОВКИ К ОГЭ ПО АНГЛИЙСКОМУ ЯЗЫКУ**
Мусина Гузель Фаритовна, Юнусова Резеда Фадитовна,учителя английского языка, Джалильская средняя школа №2, Сармановский район........................................................50
**«ЕГЕТЛЕККӘ БЕР АДЫМ » ИҖАДИ ПРОЕКТЫ**
Нәҗметдинова Чулпан Мөнир кызы, Сарман аграр көллияте укытучысы ..........................53
**ГАИЛӘ ТӘРБИЯСЕ АЛЫШТЫРГЫСЫЗ**(Методик берләшмә утырышы өчен чыгыш)
Нуриева Миләүшә Вәгыйз кызы,Җәлил бистәсенең 5нче "Әкият" балалар бакчасы тәрбиячесе,Сарман районы........................................................................................................54
**МӘДИНӘ МАЛИКОВАНЫҢ "ЧӘЧКӘ БАЛЫ" ПОВЕСТЕНДА ТЕМА, ИДЕЯЛӘР ДӨНЬЯСЫ, ПСИХОЛОГИЗМ БИРЕЛЕШЕ: ТРАДИЦИЯЛӘР ҺӘМ ЯҢАЧАЛЫК**
Нуртдинова Раушания Равил кызы, Калимуллина Әлфия Нәҗиб кызы,А.Тимергалин исемендәге Иске Минзәләбаш төп гомуми белем бирү мәктәбе,Сарман районы................55
**КӨНДӘШЛӘР**(сәхнәләштерелгән хикәя)
Рахимова Гөлүзә Әзһәм кызы,Саклау-Баш урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы ........................................................................................................................57
**СҮЗ ЭЧЕНДӘ ЭНҖЕ БАР**
Рәшитова Нәзифә Мөхлисулла кызы, филология фәннәре кандидаты20 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Әлмәт шәһәре ........................................................................63
**ТУГАН ЯК БУЙЛАП ВИРТУАЛЬ ЭКСКУРСИЯ**
Ризатдинова Эльвира Хәниф кызы, Вахитова Люция Мансур кызы,икенче санлы Җәлил урта мәктәбенең башлангыч сыйныфлар укытучылары,Сарман районы............................64
**ТАТАРСКАЯ ЛИТЕРАТУРА И РУССКИЙ ЯЗЫК**(Методические рекомендации для подготовки учащихся к устному итоговому собеседованию по русскому языку в 9-ых классах)
Садыкова Ильмира Зуфаровна, Гарифуллина Альфинур Флеровна,учителя русского языка и литературы Джалильской СОШ№2,Сармановский район................................................65

**МАДИНА МАЛИКОВА – СЧАСТЛИВАЯ ЖЕНЩИНА…**
Салимгараева Альфия Мидхатовна, Гордюшина Лилия Зульфаровна,Джалильская СОШ №2, Сармановский район ........................................................................................................67
**ПАТРИОТИЧЕСКОЕ ВОСПИТАНИЕ НА ОСНОВЕ ПЬЕСЫМ.МАЛИКОВОЙ «ПОСЛЕДНЯЯ ЛЕГЕНДА»**
Салихова Айгуль Робертовна,учитель истории и обществознания,Нуртдинова Гульнар Салихзяновна, учитель татарского языка,Джалильская СОШ № 2 Сармановский район....70
**МӘДИНӘ МАЛИКОВАНЫҢ «КАР СУЛАРЫ», «САРЫ ТЮЛЬПАННАР», «КЫЗЫЛ ГӨЛ» ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ХАТЫН-КЫЗ ОБРАЗЛАРЫНЫҢ БИРЕЛЕШЕ**
Соловьева Фәнүзә Фәнис кызы, Хәбибуллина Миляуша Хәмит кызы.,Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче Җәлил беренче гомуми урта белем бирү мәктәбе,Сарман районы .......71
ТАТАР ВАКЫТЛЫ МӘТБУГАТЫ:ҮТКӘНЕ, БҮГЕНГЕСЕ (Әдәби-телдән журнал)
Тихонова Резедә Рәфәт кызы, Гайфуллина Зөлфия Нуриман кызы, Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче Җәлил беренче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы .......74
ЭНДӘШ СҮЗЛӘР, АЛАР ЯНЫНДА ТЫНЫШ БИЛГЕЛӘРЕ
Фазлиева Гузәл Дамир кызы,Советлар Союзы Герое А.А.Казаков исемендәге Александровка төп гомуми белем бирү мәктәбе,Сарман районы .......................................74
**ЗЫЯЛЫ ЯЗУЧЫ**
Фахразиева Лилия Фәнүз кызы,Әлмәт шәһәренең дүртенче санлы урта мәктәбе ................76
**МӘДИНӘ МАЛИКОВАНЫҢ ЮБИЛЕЕ УҢАЕННАН ОЕШТЫРЫЛГАН КИЧӘ**
Фәйзрахманова Миләүшә Изаил кызы, Аглиева Раушания Изаил кызы,Зиннәт Хәсәнов исемендәге Иске Кәшер урта гомуми белем бирү мәктәбе,Сарман районы ........................79
**САРМАННЫҢ ЗЫЯЛЫ ЯЗУЧЫ**
Фәрхетдинова Тәслимә Флер кызы, Бариева Фәнүсә Фоат кызы,икенче санлы Җәлил урта мәктәбененңбашлангыч сыйныф укытучылары,Сарман районы ............................................81
**ПЕДАГОГИЧЕСКИЙ ПРОЕКТ «ИЗВЕСТНЫЕ ПИСАТЕЛИ РОДНОГО КРАЯ**
Халитова Наиля Амирзановна, Хакимова Гелюся Габдулловна,Горшенина Марина Александровна,Воспитатели Джалильского детского сада №3 «Аленушка»,Сармановский район.............................................................................................................................82
**ТУГАН ЯГЫ КИРӘК КЕШЕГӘ**(ата-аналар җыелышы өчен чыгыш)..............................84
Харисова Илзирә Алмас кызы,Иске Кәшер урта гомуми белем бирүмәктәбе, Сарман районы ...........................................................................................................................84
**ФИГЫЛЬ ҺӘМ АНЫҢ НИГЕЗЕ**
Хафизова Айсылу Дамир кызы,Советлар Союзы Герое А.А.Казаков исемендәге Александровка төп гомуми белем бирү мәктәбе,Сарман районы .......................................86
**МӘДИНӘ МАЛИКОВАНЫҢ ИҖАТЫН МӘКТӘПТӘ УКЫТУ ТӘҖРИБӘСЕ ҺӘМ ӘСӘРЛӘРНЕҢ ТӘРБИЯБИ ӘҺӘМИЯТЕ**
Хафизова Румия Әбүзәр кызы,Бөгелмә шәһәренең 6 нчы урта мәктәбе ..............................89
**БИК БӘХЕТЛЕ ЯЗУЧЫ**
Хәертдинова Гөләмзә Әхмәтҗан кызы, Җәлил беренче урта гомуми белем бирү мәктәбе Хәертдинова Аида Альберт кызы, Җәлил гимназиясенең тарих укытучысы,Сарман районы ...........................................................................................................................89
**МӘДИНӘ МАЛИКОВА ТОРМЫШЫ ҺӘМ ИҖАТЫНА БАГЫШЛАНГАН КВН**(Педагоглар арасында)

Хәлиуллина Рузилә Рубирт кызы,Җәлил бистәсенең 6 нчы номерлы балалар бакчасы тәрбиячесе, Сарман районы
**ТӨСЛЕ СҮЗЛӘР**(укытучылар өчен мастер-класс)
Һадиуллина Гөлнара Әкмәлетдин кызы,Сарман гимназиясенең башлангыч сыйныфлар укытучысы........92
**ГАРӘП-ФАРСЫ АЛЫНМАЛАРЫН КАБАТЛАУ**
Шайхулова Гөлназ Фаяз кызы,Яңа Кәшер санатор интернат-мәктәбе, Әлмәт районы......95
**БӘХЕТ КАЛАСЫ**
Шакирова Эльмира Финус кызы, Зиннатуллина Лилия Ринат кызы,Җәлил гимназиясенеңтатар теле һәм әдәбияты укытучылары,Сарман районы........96
**МӘДИНӘ МАЛИКОВАНЫҢ ИҖАТЫНДА ХАТЫН-КЫЗ ОБРАЗЛАРЫНЫҢ БИРЕЛЕШЕ**
Шафикова Гүзәлия Рәхимша кызы,Россия Федерациясе Герое А.Н. Епанешников исемендәге 3нче урта гомуми белем мәктәбе,Алабуга районы........98
**ЯКТАШЫБЫЗМ. МАЛИКОВАНЫҢ «ЧӘЧКӘ БАЛЫ» ПОВЕСТЕ БУЕНЧА КЛАССТАН ТЫШ УКУ ДӘРЕСЕ**(8 нче сыйныф)
Шаһгалиева Гөлназ Нәҗип кызы,Актүбә 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Азнакай районы........99
**ТУГАН ЯК БУЛА БЕР ГЕНӘ**(Осталык-дәресе)
Шәйдуллина Гөлнара Индүс кызы,Ләшәү-Тамак төп гомуми белем бирүмәктәбе тәрбиясесе,Сарман районы........102
**ТАБИБ ҺӨНӘРЕ – БИК МӨҺИМ ҺӨНӘР**(Сыйныф сәгате)
Шәйхелисламова Лилия Фәрид кызы,икенче санлы Җәлил урта мәктәбенең башлангыч сыйныф укытучысы,Сарман районы........103
**МӘДИНӘ МАЛИКОВА - БӘХЕТЛЕ ЯЗУЧЫ**
Шәмсетдинова Альбина Шәүкәт кызы,Җәлил бистәсенең 5 нче «Әкият» балалар бакчасы тәрбиячесе, Сарман районы........105
**ДӨНЬЯ ТЕРӘГЕ — ХАТЫН-КЫЗ**(Мәктәпкәчә әзерлек төркеме өчен кичә конспекты)
Якупова Гөлшат Шаһәдәт кызы,«Дуслык» 59 нчы балалар бакчасы, Яр Чаллы шәһәре...106